www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 35 (1451) 8 сентябрь 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



5

Актаныш районында, Башкортстан белән Татарстан чигендә урнашкан Иске Байсар авылына 450 ел!



8-9

Бар гомерен татар милләтен азат итүгә багышлаган бөек Гаяз Исхакый мирасын яңа буыннарга өйрәтү таләп ителә.

12-13

Драматург Илгиз Зәйниев иҗат иткән «Ситса туй» әсәрен иң әүвәл Минзәлә театры күтәреп алган иде, хәзер камаллылар да аны үз итте.



Кальбебезне һәрчак уяу тотсын Исхакыйның оран-набаты!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- 1 сентябрь көнне Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов – Казанда, Татарстан хөкүмәтенең рәис урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев – Курган өлкәсенең Эчкен-Йолдыз авылында, «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви бәйләнешләр агентлыгының генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев Актаныш мәктәпләрендә булды һәм укучыларны яңа уку елы, гыйлем бәйрәме белән котлады.

- Халык язучысы Гәрәй Рәхимнең каберенә таш куелды һәм аны искә алу мәрәсиме булып узды.

- 5 сентябрьдә Ттарстан Милли музее һәм аның филиаллары сәнгать сөюче тамашачыларны бушлай кабул итте.

- Теләче районының Иске Җөри авылында «Китап» радиосы татар җырын башкаручылар арасында Таһир Якупов исемендәге I Республика фестивале үткәрде.

- Чечняда туйларда этик нормаларга туры килмәгән фото һәм видео төшүләрне тыю турында канун, ә республика мөфтияте туй нормаларын аңлаткан кагыйдәләрне кабул иткән.

- Төркиянең Денизли шәһәрендә юл һәлакәтендә 6 кеше үлгән, 43 кеше яраланган.

- Башкортстанның Чакмагыш районындагы Яңа Балтач авылында печәнгә капкан ут каралты-курага күчкән һәм мунчага керсп качкан 3 яшьлек сабый янгында һәлак булган.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

8 сентябрь – тарихчы, нумизмат, археолог, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе,Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Татарстан дәүләт бүләге иясе Әзһәр Гатаулла улы Мөхәммәдиевнең тууына 90 ел (1933–2018).

9 сентябрь – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Вера Егор кызы Минкинаның тууына 105 ел (1918-2011).

14 сентябрь – тел галиме, филология фәннәре докторы, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт бүләге иясе Рүзәл Габдуллаҗан улы Юсуповка 85 яшь (1938);

– филология фәннәре докторы Рамил Фәнәви улы Исламовка 65 яшь (1958).

СЫНАМЫШЛАР

●Сентябрьдә яшенле яңгырлар еш яуса, көз җылы килә ●Симән көнне (искечә 1 сентябрь – яңача 14 е) җылы булса, бөтен көз җылы була ●Симән көнне күк күкрәсә, көз озакка сузыла, киләсе елда ашлык уңа ●Симән көнне яңгыр яуса, көз пычрак килә ●Көзен каен агачлары астан саргаеп, яфракларын астан коя башласа – кыш җылы килә, ә өстән саргаеп, өстән яфрак коя башласа – кыш салкын килә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 01 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 23 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **13 сәгать 22 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **15 сентябрьдә 12 сәгать 50 мину**т тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 14 сентябрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(7-15 сентябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

**Бүген сәфәр аеның
23 нче көне**

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

ИСХАКЫЙ ЯДКӘРЕ

Быел бөек Гаяз әфәнде Исхакыйның тууына 145 ел тулды. Мәмләкәтле булу хыялы белән янган зыялылар әлеге тарихи дата Татарстан күләмендә шаулап-гөрләп үтәр, дип өметләнгән иде. Чөнки татарның соңгы ике гасырлык тарихында милләтне мәмләкәтле итү, татарны кабаттан бөтендөнья мәйданына чыгару өчен Гаяз Исхакыйдан да битәррәк җан атучы, бар гомерен фәкать шушы максатка гына багышлаган шәхес барыбер табылмады.

Милләт күренекле шәхесләргә, билгеле, ярлы түгел. Ләкин XX гасыр башында Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек әйдәманнарыбыз милләтне парламент юлы белән һәм анда да әле әүвәл милли-мәдәни мөхтәрияте итү уе белән генә янса, бөек Исхакый көрәш юлының тәүге адымында ук татарны мөстәкыйль мәмләкәтле итү, баскыннар тырнагыннан азат, хөр җөмһүрият төзү юлына басты. Хәтта инде большевиклар капкыныннан котылып, 1919 елда чит илләргә чыгып качканнан соң да Г.Исхакый азат Татарстан төзү ниятеннән кире чигенмәде, хыялындагы «Идел-Урал дәүләте»нә багышланган китапларын берничә телдә нәшер итеп, аларны бөтендөнья халыкларына ирештерде һәм үзенең соңгы сулышына – 1954 ел июленә тикле фәкать шушы шигарьне генә туктамый тәкрарлады.

Ни кызганыч, югары кәнәфиләрне биләп утырган кичәге коммунистлар, үз кесәләрен саклап калу һәм үзәккә ярау хакына, бөек Исхакыйның 140 еллык юбилеен да, 145 еллыгын да билгеләп үтү өчен бармакка-бармак та сугып карамады. Казан каласында әлеге юбилейлар бәрабәренә бер төрле тантана үткәрергә дә җөрьәт итмәделәр. Киң җәмәгатьчелек һәм зыялылар Исхакыйга багышланган һәйкәл кую, исемен тимерьюл вокзалы буендагы өч йортлы мескен тыкрыктан алып, зуррак, лаек проспектка бирдерү турында үтенеч-мөрәҗәгатьләр юллау да игътибарсыз калды. Исхакыйның Чистай районының туган авылы Яушырмәдәге бердәнбер, әмма инде бүрәнәләре яртылаш черегән музеен, аның тирә-юнен, Казый чишмәсенә илтүче басмаларын яңарту нияте белән матбугатта күтәрелгән шау-шуның да нәтиҗәсе барыбер күренмәде. Хөкүмәт 39 миллион сум акча бүлеп бирде, дигән юаткыч хәбәр ишетелсә дә, Яушырмәдәге музейны яңарту буенча биш ел буена һичбер төрле хәрәкәт башланмады.

Хөкүмәттәге кәнәфи ияләренең оясына кереп качкан йомран шикелле тын гына ятуы аңлашыла да сыман. Вертикаль хакимият гайкаларны гына түгел, сулышны да кыса. Әнә, меңнәрчә имзалы хат рәвешендә үзәккә юлланган үтенечләргә төкереп тә бирмичә, Дәүләт Думасы, шуның составында Татарстанның 16 депутаты, туган тел сәгатьләрен киметү һәм ошбу илдә фәкать «алтындай» урыс телен генә күккә чөюне хуплаган канун кабул итте. 1906 елда шушы ук Думага сайланган Садри Максуди 100 мәртәбә мөнбәргә чыгып һәм чигенмичә көрәшеп, Рәсәйнең «Мәгариф турындагы канун»ына «Рус булмаган балалар башлангыч мәктәпләрдә рус теленнән кала барча фәннәрне дә фәкать үзләренең туган телендә генә өйрәнергә тиеш», дигән төзәтмәне кертүгә ирешкән булса, Татарстанның 16 яки Башкортстан, Чуашстан, Мари-Эль, Удмуртия, Якутия-Саха, Мордовия, Чечня, Ингушетия һ.б. милли өлкә юллаган депутатларның сыңары гына да үзенең икмәк ашап һәм башка мәнфәгать күреп яшәгән төбәк халкын яклап, сыңар гына булса да сүз әйтмәде. Бөтенләй дә аңлашылсын өчен, тагын бер мәгълүмат өстәсәк тә артык булмас: илдә соңгы 20 елда ябылган мәктәпләрнең саны 14 меңгә җитсә, калкып чыккан яңа чиркәүләрнең саны 38 мең чиген дә узды инде...

Соңгы биш елда бөек Исхакыйга мөнәсәбәтле бердәнбер яңалык шул: «Азатлык» оешмасы яшьләре аның «Зөләйха» драмасын өр-яңадан, аерым китап рәвешендә нәшер итте. Кемнәрдер «Бу әсәр Исхакыйның 15 томлы сайланма әсәрләрендә урын алды, аның буенча хәтта нәфис фильм да төшерделәр», дип авыз капларга маташыр. Берникадәр аңлатма өстәү дә комачау итмәс сыман. Бердән, ул 15 томлык әсәрләрне дөньяга чыгару өчен галимнәр арасыннан Лена Гайнанова, Ибраһим Нуруллин, Хатыйп Миңнегулов... кебекләр генә боздай каткан күңелле җитәкчеләрнең бүлмәләрен-җанын бозваткыч шикелле җимереп-ярып йөрде. Исхакыйның Яушырмәдәге бердәнбер музеен төзетү өчен дә, иң беренче чиратта, Лена Гайнанова көрәште. Бәлки, галимәбез әнә шулай ялгыз булгангадыр, бөек Исхакыйның чит илләр буенча таралган мирасының бер өлеше генә мең киртәләр аша туган җиребезгә әйләнеп кайта алды, дөрес, кайтканын да җиде йозак астына бикләделәр. Шул сәбәпле, 15 томлы сайланма әсәрләрне дөньяга чыгару да 15 елга сузылды. Һәм татарлар арасында миллион гына түгел, миллиард тәңкәләр туплаган байлар дистәләп булса да, аларның берсе генә дә «Зөләйха» драмасы буенча нәфис фильм төшергән чакта ярдәмгә килмәде. Рамил Төхфәтуллин ул фильмны хөкүмәттән тезләнеп ялварган «бакыр тиеннәр» хакына гына «ерып чыгарга» мәҗбүр булды һәм, билгеле ки, иҗат җимеше киң экран да, зур мәйдан да яулый алмады (гәрчә, хәтта уңышлы чыкса да, үзәк аңа мөнбәр бирмәс иде). Ә шул ук вакытта махсус заказ буенча язылган һәм татар милләтен чукынуга, балаларын урыс дип язылган паспорт алыштыруга чакырган «Зөләйха күзләрен ача» романы офыкта пәйда булып та өлгермәде, аны шундук Казан хакиме дә миллион тәңкәлек бүләк белән олылады, әсәр күңелләренә үтә дә хуш килгән Мәскәү вә керәшен байлары да миллионнарны койды. Нәкъ шул карагруһчылар акчасына татар милләтен мыскыл иткән роман Европа телләренә тәрҗемә ителде. Илдә фәкать бер тел һәм бер милләт калдырырга ният иткән кара көчләр шушы сатлык роман буенча нәфис фильм төшерү өчен дә дистә һәм йөз миллионнар ыргытты. Анда төп сатлыкҗан ролен үзенең мәктәптәге татар теле укытучысын Гитлер белән чагыштырган Чулпан Хамматова башкарачагы да һич тә гаҗәп түгел иде инде... Илдә көрәш, барча милләтләрне йомып бетерү һәм колга әверелдерү өчен кансыз көрәш бара...

Исхакый үзенең «Зөләйха» драмасын моннан нәкъ бер гасыр элек, 1918 елда язган һәм шуннан бирле әлеге әсәр аерым китап булып чыгу бәхетенә ирешмәгән. Үзәктә – милләтнең бәгыренә үткән, аны көчләп чукындыру афәтләре. Һаман да бер кансыз гамәл – татарны милләтеннән, дененнән, теленнән, ата-аналарыннан, газиз тарихыннан аеру, нәселеннән өзү өчен, ул көчләп чукындыру сәясәте Казан дәүләтен юкка чыгарган 1552 елдан соң ук тамыр җәйгән. Казан кирмәне эчендәге хан сарае янына Явыз Иванның үз куллары белән чиркәү нигезен салдыртып та, мәркәз эчендәге татарларны шәһәр читендәге сазлыкларга, ә якын-тирәдәге татар авылларын башкаладан – 50, елга буйларыннан унбиш чакрымга күчереп утыртып та, Казан каласына әүвәл епископ Гурийны китереп, 1731 елда шул ук мәркәзебездә «Яңа чукындыру конторасы» ачып, ун ел үткәннән соң, атасы шикелле үк кансыз патшабикә Езизавета фәрманы буенча өяздәге 536 мәчетнең 418 ен юкка чыгарып та, һаман бер коточкыч гамәл – Идел буендагы халыкларны көчләп чукындыру сәясәтен тормышка ашырганнар. Кулына «изге» тәре һәм «изге» Иисус иконасын тоткан атакайлар белән бергә илбасар гаскәрләре авыллардан-авылларга йөргән, үз йортыннан урманнарга качып китәргә өлгермәгән татар балаларын мәҗбүриләп елгага чумдырганнар, «изге» атакай «изге» су бөркегәннән соң, бичара коллар муенына «тавык тәпие» көчләп тагылган. Авылда 3-4 чукынган кеше пәйда булуга ук, татарларны шулар өчен чиркәү төзеп бирергә, алар өчен салым түләргә мәҗбүр иткәннәр. Чукынучылар саны аз гына күбәюгә, татарларны яңа җирләргә, урман-сазлык арасына куып чыгарганнар. Алар төзеп калдырган йорт-хуҗалыкларга килмешәк баскын гаиләләре, үз ихтыяры белән күчеп утыручылар табылмаса, угрылык яки кеше үтергән өчен үлемгә хөкем ителгән «бөек» милләт вәкилләрен булса да табып китергәннәр. Шулай итеп, кичә Акай Күле атын йөрткән татар авылы Рус Шуганы дигән яңа ямау алган, яки әле былтыр гына Ногай бәге дип танылган морза яшәгән сала, чукынгач, «Нагайбәк кирмәне»нә әверелгән...

Татарлар дәүләтләр төзү, ярты җиһанны дер селкетеп тоту дигән бәхет-шанны белмәүче ар, чирмеш, мукшы халыклары түгел бит. 1731 елда ачылган «Яңа чукындыру конторасы»ның кабәхәт атаманы Аксак Каратун – Лука Конашевич әнә шул ар-мукшы-чирмешкә тоташтан «тәвык тәпие» тагуга ирешсә дә, көчләп чукындыручы поплар алдында тез чүккән татарларның саны 7-8 меңнән дә артмаган. Ләкин әле шул көчләп чукындырылган татарлар да үз диненнән танмаган.

(Дәвамы 4 нчы биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Белеме бар меңне егар

Беләге бар берне егар, белеме бар меңне егар, ди мәкаль. Кызганычка, «беләге» белән бөтен дөньяны «акылга» утыртырга омтылган илдә яшибез. Мондый тайпылыш, күрәсең, аңа йөкләнгән геосәяси вазифа белән дә билгеләнә, чөнки ул башта ук, империя буларак – дөнья тотучыларның «геосәясәт коралы», ә анда яшәүчеләр – «туп азыгы» итеп формалаштырылган (бу аның тарихы белән дә раслана). Ә инде ирексездән туган әлеге «геосәяси» уйлануларга килгәндә, аңлашыла булыр, аңа этәргән сәбәпләр узган җомгада ил күләмендә һәм зурдан кубып билгеләп үтелгән «Белем көне» белән бәйле. Күрүебезчә, ул быел да үзенчәлекле шартларда һәм ура-патриотизм рухында үтте. Әйе, тыштан караганда, әлеге тәрбия вә белем бирү системасы эзлекле, тигез һәм хәтта заман төсмерләре белән ялтырый да кебек. Шул ук вакытта үзенең асылы вә реаль максатлары ягыннан ул, бүгенге чынбарлык белән генә түгел, ә илдә яшәүче төп халыкларның рухи, иҗтимагый һәм хәтта милли-мәдәни ихтыяҗлары белән дә кискен каршылыкка керә. Хокукый вә сәяси яктан аның асылын аңлау өчен, якын үткәнебезгә кыскача экскурс ясап, ул чорда кыйбла итеп алынган төп юнәлешләрне бүгенге аяныч чынбарлыкка һәм шомлы киләчәгебезгә нисбәттә гөман итеп карау да урынлы булыр.

Зурдан алганда, мәгариф өлкәсендә тоташ реформалар Россиядә инде узган гасырның 90 нчы елларыннан бирле бара һәм ул бүген дә дәвам итә. Хактыр ки, мондый хәл мәгариф системасының, халык ихтыяҗларына түгел, ә тулысынча сәясәткә буйсындырылуы белән бәйле. Геосәяси вазифа сакланса да, агымдагы сәясәт гел үзгәреп тора. СССР таркатылгач, анда формалашкан башка яшь дәүләтләр белән бергә, империянең төп фрагменты саналган һәм үзен аның варисы дип тә игълан иткән Россиядә дә яшәешнең барлык өлкәләрендә (шул исәптән мәгарифтә дә) ул чакта өметле күренгән Көнбатыш кыйммәтләренә күчү башланды. Чын имтихан урынына БДИ кертү, мәгарифтә Көнбатыш стандартларына күчү һ.б. – шул чор җимешләре. Россиягә тулы карт-бланш бирелеп, Чечня фонында анда хакимият вертикале дә урнаштырылгач, яңа лидер инде кызып китеп, хәтта НАТОга керү теләген дә белдергән иде. Шуңа, яңа дөньяви тәртип урнаштыруда Россиянең геосәяси ролен (Көнбатыш белән капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итү икәнлеген) аңа төрле яктан аңлаттылар кебек. Бары тик шуннан соң гына геосәяси аренада В.Путинның Мюнхен чыгышы яңгырады һәм илдә эчке сәясәтне бөтен өлкәләрдә (шул исәптән мәгарифтә дә) капма-каршы якка үзгәртү башланды. Ә 2012 елда Россиянең 2025 елга кадәрге чорга исәпләнгән Дәүләт милли сәясәте стратегиясе кабул ителде. Нәтиҗәдә, халыкара хокук нормаларына һәм РФ Конституциясенә дә каршы килеп, Россия составындагы төп халыкларның милли мәгариф системалары тәмам җимерелде, туган телләре мәктәпләрдән куылды һәм аларның статусы чит телләрнекеннән дә түбән төшерелде. Шулай итеп, Россиядә «мәгариф» дигән тармакның «җаны» алынды.

Бүгенге хәлләргә килсәк, бер караганда, быел анда уңай якка да үзгәрешләр (әйтик, яңа уку елына Россиядә 160 яңа мәктәп ачылган) бар кебек. Әмма системалы үзгәрешләрнең асылы конкрет фактларда күренә. Аларның кайберләренә генә багыйк. Әйтик, 2022 елның мартында (мәгълүм вакыйгалардан соң) Россиядән киткән Coursera платформасына алмашка, Skillbox компаниясенең «Академика» атлы EdTech-платформасы булдырылган. Максаты – IT-тармакта дөнья лидерлары тәҗрибәсенә йөз тоткан онлайн-белем үсешенә ярдәм күрсәтү. Янә бер мисал. Элегрәк матбугатта урыс әдәбияты буенча 2024 елга БДИ сорауларыннан А.Пушкин, М.Лермонтов, Н.Гоголь әсәрләре алыначагы турында сүз булган иде. Дөрес, РФ мәгариф министрлыгы соңрак моны кире каккан. Ә «Синергия» университетының аналитик үзәге үткәргән сораштыру нәтиҗәләренә караганда, җавап бирүчеләрнең 63 проценты ул әсәрләрнең БДИ сорауларыннан алынуын хуплаган, каршы булучылар 13% тәшкил иткән. Бу, әлбәттә, күп нәрсә турында сөйли. Тарих дәреслекләре белән һаман «шаяру»лар да – шул җөмләдән. Күренә ки, мәгариф әле һаман да халык ихтыяҗларына түгел, ә сәясәткә хезмәт итә. Максаты – дөнья тотучылар тәгаенләгән шомлы киләчәк өчен «эшче материал» әзерләү.

Бу хәтта Белем көне уңаеннан узган җыелыш чараларда да күренде. Әйтик, Россиядә яшәүче халыклар өчен иң мөһим һәм хәтта фаҗигале дә проблема – туган телләрдә белем алу мөмкинлеге бетерелүе һәм, гомумән, туган телләрнең язмышы. Ә 1 сентябрьдә РФ президенты үткәргән «Разговор о важном» ачык дәресендә бу мәсьәлә күтәрелдеме икән? Татарстанда да шундый ук хәл. Әйе, Россиядә ачылган 160 яңа мәктәпнең 11е аңа туры килә. Тик аларның ничәсендә, милли традицияләргә таянып, туган телдә тирән белем һәм тәрбия алу мөмкинлеге булдырылды икән? Инде яңа тарих дәреслекләрен дә Мединскийлар яза башлагач, андый мәгарифтән нинди инабәт булсын? Әйе, укытучыларга ноутбуклар бүләк итү, уртакул түрәләргә машина ачкычлары тапшыру, бәлки, кирәктер дә. Әмма укучыларга чын мәгънәсендә тирән белем ачкычлары да тапшырылса, хактан да, алар «меңне егар» иде.

Фоат УРАЗАЙ.

Көрәш кыза

Россия узган атнада БМО Куркынычсызлык шурасында Малига каршы санкцияләрне бер елга озайту турында Франция һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре әзерләгән резолюция проектына каршы вето хокукын кулланган. Кытай – битараф, ә шураның башка әгъзалары ул проектны хуплап тавыш биргән. Бу инде «Глобаль Көньяк»-Көнбатыш каршылыгы Африка илләрендә дә һаман ныграк чагылыш таба баруы турында сөйли. Хәлбуки, 30 августта хәрби түнтәреш Габонда да булган. Анда хәрбиләр төркеме илдә инде 14 ел хакимлек иткән һәм шимбә көнне үткән сайлауда өченче срокка калдырылган президент Али Бонго Ондимбаның хакимияттән читләштерелүе турында игълан иткән. Африка берлеге исә әлеге түнтәрешне кискен гаепләп чыккан. Фетнә җәһәтеннән борчылуын Россия дә белдерде. Искәртеп үтик, Габондагы түнтәреш Көнбатыш һәм Үзәк Африка илләрендә, 2020 елдан алып санаганда, инде сигезенче фетнә була. Нигер, Мали һәм Буркина-Фасодан аермалы буларак, Габонда юкса ислам радикаллары да катнашмаган кебек. Ә бу инде әлеге илләрнең шул ук глобаль көчләр арасында Африка өчен барган көрәштә «сәясәт коралы» итеп кулланылуын күрсәтә.

Узган атнада хәлләр Нигерда да катлаулана төшкән: фетнәчеләр иминлек турында Франция белән килешүдән чыккан һәм илдән Франция гаскәрләренең чыгарылуын таләп иткән; алар Нигерда халыкара оешмалар эшчәнлеген дә туктаткан; ЕС илләренең саклану министрлары исә ECOWAS (Көнбатыш Африка илләренең икътисади җәмгыяте) көчләрен яклап чыккан.

Инде сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да билгеләп үтик. РФ тышкы эшләр министрлыгы ашлык сәүдәсен Россиядән башка гына гамәлгә ашырып булмаячагы турында белдерде. АКШ Украинага хәрби ярдәмнең 250 миллион доллар күләмендәге яңа пакетын бүлеп биргән. Россия ЧВК «Вагнер» җитәкчелеген фаҗигагә китергән Бразилия очкычы Embraer һәлакәте буенча тикшерү (ә моны халыкара кагыйдәләр буенча Бразилия сораган) үткәрмәячәге турында белдергән. Кремльнең матбугат хезмәте башлыгы Д.Песков, Украина «дрон»нарының Орлов, Рязань, Брянск, Калуга, Псков өлкәләренә, шулай ук Севастополь һәм Мәскәү яны объектларына һөҗүмен «террористическая активность Киевского режима» дип бәяләгән һәм: «Мы продолжаем и будем продолжать СВО с тем, чтобы искоренить подобную угрозу для нас», – дип белдергән. ЕС дипломатиясе башлыгы Жозеп Боррель ел ахырына кадәр Украинага 5 миллиард евро бүлеп бирү мәсьәләсен җайга салырга теләвен әйткән. Ул шулай ук 2024-2027 елларда Украинага хәрби ярдәм күрсәтү өчен махсус фонд булдырырга тәкъдим иткән. АКШ Украина көчләренең Россия территориясенә ясаган һөҗүмнәрен хупламавы турында белдергән. РФ президенты ярдәмчесе В.Мединский 5-9 класслар өчен яңа тарих дәреслекләре әзерләнә башлавы һәм 2024 елның 1 сентябренә алар әзер булырга тиешлеге турында әйткән.

1 нче биттә – Гаяз Исхакый портреты.

Россиядә Африка авыллары төзиләр

Август аенда Тверь өлкәсенең Бологовский районындагы Поречье авылы янында Африка кешеләре авылына нигез ташы салдылар. Чарада Тверь өлкәсе депутатлары, төбәк хакимияте башкарма органнары хезмәткәрләре, Россиядәге Африка халыкара конгрессы вәкилләре килгән. Шулай ук Африка дипломатлары, Африка якташлыгы лидерлары, «Инвестиционная Россия» оешмасы вәкилләре дә катнашкан. Тантанада Африка халыкара конгрессы флагын күтәргәннәр.

«Без Африкадан Россиягә эмиграцияләнергә теләгән африканерларга (европейц-бурлар) Россиядә 30 колония булдырырга ниятлибез. Болар – күп еллар элек Африка континентына килеп төпләнгән Европа фермерлары», – дип сөйләгән Африка авылы ачылышында Евразия халыкара университеты ректоры, Россиядәге Африка халыкара конгрессы генераль вәкиле Константин Клименко.

«Күп кенә африканерлар хәзер православие динен кабул итте һәм Россиягә күченеп килә – аларны безнең ил югары әхлакый-рухи тәртибе, традицион гаилә кыйммәтләре булган дәүләт буларак җәеп итә», – дигән ул.

Кирәкле барлык инженерия инфраструктурасы белән җиһазландырылган җирдә Африка континентыннан чыккан кешеләр өчен авыл барлыкка киләчәк. Алар авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнәчәк – бәрәңге үстерәчәк яки сыер үрчетәчәк.

Үстерелгән уңышны һәм сөтне фермер һәм проектта катнашучы Алексей Трофимов кабул итәргә әзер. Аның предприятиесе Афроавыл проекты өчен база булачак, авылга килгән яңа кешеләргә оештыру һәм технология ярдәме күрсәтәчәк, аларны орлыклардан башлап, техникага кадәр барлык ресурслар белән дә тәэмин итәчәк. Инде планнарны тормышка ашыруның беренче адымы ясалган – «Милкбург» сыр ясау оешмасы ачылган.

Хәзер Афроавыл проекты пилот форматында Мәскәү һәм Тверь өлкәләрендә гамәлгә ашырыла. Соңыннан АМК һәм аның партнерлары ярдәмендә ул Россиянең башка субъектларында да булдырылачак, хакимият күченеп килүчеләргә кызыклы шартлар тәкъдим итә алачак.

Программа 5 елга исәпләнгән. Россиягә 3000гә якын африканерны күчерү планлаштырыла. Сентябрьдә Евразия халыкара университеты рус теле буенча укыту программасын башлый, университетның

онлайн курсларында 200гә якын кеше тел өйрәнәчәк.

Күченеп килгән африканерлар яңа ватаннарында микроинвесторлар да була алыр, дип фаразлана: алар монда үз йортларын төзиячәк, оешмалар, балалар бакчалары, медпунктлар ача алачак.

Африканерларның чираттагы делегациясе Россиягә сентябрьдә киләчәк, дип яза «Российская газета».

7 шәһәргә дроннар һөҗүме

Махсус хәрби операция башланганнан соң дроннарның иң массакүләм һөҗүме булды. Оборона министрлыгы Украина дроннарының 7 төбәккә һөҗүм итүен раслый.

Иң башта Псковтагы хәрби аэродромга һөҗүм булуы хакында хәбәр ителде. Төнлә зур янгын чыккан, аны шәһәрдә яшәүчеләр видеога төшергән. Губернатор Михаил Ведерников корбаннар булмавын әйтә. ТАСС 4 хәрби-транспорт самолетка дроннар төшеп шартлавын әйткән. МЧС шушы самолетларга ут кабуын әйтә.

Дроннар барлыгы 20 булган, дип язалар. Псковтан Украинага кадәр 800 км. Шуңа да дроннар Эстония яки Литвадан җибәрелгән булуы ихтимал, дигән фаразлар да барлыкка килде – алардан Псковка кадәр 50-60 км гына.

Псковтагы һөҗүмнән соң Брянск губернаторы Александр Богомаз Брянскидагы дроннарны бәреп төшерүләрен әйткән. Аларның берсе хәрби завод – микроэлектроника ясый торган «Кремний ЭЛ» түбәсенә төшеп шартлаган, янгын чыккан. 2 дрон телебашняга уңышсыз һөҗүм ясаган.

2 дрон нефтебазага уңышсыз һөҗүм ясаган.

Орел өлкәсендә 1 дрон бәреп төшерелгән.

Калуга өлкәсе губенаторы Владислав Шапша 1 дронның бәреп төшерүен, икенчесенең нефть саклана торган резервуарга төшеп шартлавын һәм янгын башлануын әйткән.

● Махсус хәрби операция башланганнан соң дроннар һөҗүменә дучар булган төбәкләр.
Фото: © РБК

Рязань өлкәсендә 2 дрон бәреп төшерелгән.

Төнге өчтә Мәскәү өлкәсендә 1 дрон бәреп төшерелүе турында яздылар. Мәскәү мэры С.Собянин дроннар һөҗүменең «массакүләм» булуын әйтте.

Дроннар һөҗүме сәбәпле, Мәскәүдәге, һөҗүм булган башка шәһәрләрдәге аэродромнар ябылган, пассажир рейслары башка шәһәрләргә төшә.

Севастопольдә диңгез дроннары рейдтагы корабларга һөҗүм иткән, алар юкка чыгарылган, дип язалар. 30 августта Кара диңгездә Украина десантчылары булган 4 катер батырылуы турында хәбәр чыкты.

Интертат.

Мөфти: «Милли үзенчәлекләрне саклыйк»

Мәскәүдә «Традицион кыйммәтләрне саклау мәсьәләләре» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференциядә мөфтиләр һәм Россиянең үзәкләштерелгән мөселман дини оешмалары җитәкчеләре катнашты, РФ Президенты Администрациясенең вазыйфаи затлары, Федерация Советы әгъзалары һәм РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатлары һ.б. катнашты. Татарстаннан мөфти Камил Сәмигуллин һәм аның беренче урынбасары Илфар Хәсәнов та әлеге чарада катнашты. Конференциягә Төньяк Кавказ мөселманнары Координация үзәге һәм Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифкә ярдәм фонды теләктәшлегендә «Халыкара ислам миссиясе» Үзәкләштерелгән дини оешмасы оештырды.

Көн тәртибенә Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 9 ноябрендә имзаланган «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча дәүләт сәясәте нигезләрен раслау турында» 809 нчы Указын гамәлгә ашыру; шулай ук Россия гражданнарын традицион кыйммәтләрне яклау нигезендә берләштерү юллары; деструктив идеологиягә һәм массакүләм мәдәнияткә каршы тору ысуллары эшләү һәм заманча мәгълүмат киңлегендә традицион кыйммәтләрне тарату мәсьәләләре турында фикер алышу чыгарылды.

Пленар утырыш Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Коръән укуы белән ачылды. Чыгыш ясаучылар арасында «Халыкара ислам миссиясе» рәисе Шәфигъ хаҗи Пшихачев, Россия Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Россия мөселманнары Дини җыены рәисе Әлбир хәзрәт Крганов һ.б. бар иде. Мөфти Камил хәзрәт тә доклад белән чыкты.

– Соңгы вакытта без исламга каршы коткы салуларны күп күрдек, – дип билгеләп үтте ул. – Без Коръән мүсхәфләрен яндыру акцияләре турында еш ишетә башладык, хәзер моңа хәтта гаҗәпләнмибез дә инде. Бу мөселман җәмәгатьчелеген мыскыллауларның никадәр еракка китәргә мөмкинлеген һәм үтәргә ярамаган чикнең кайда икәнлеген аңлау өчен кирәк. Җәмгыятьтә традицион кыйммәтләргә, гаиләгә кыйммәтләренә каршы идеяләр да алга сөрелә. Бу «чир»нең Россиягә үтеп кермәве мөһим. Безнең ил традицион гомумкешелек кыйммәтләре өчен көрәшүне үз өстенә алды һәм хәзер аларга игълан ителгән каршылыкларны ничек җиңәргә икәнен аңларга кирәк.

Камил хәзрәт моның өчен Россия халыкларының милли-дини традицияләрен ныгытырга кирәклеген әйтте: «Без күпмилләтле һәм күп динле илдә яшибез. Һәр милләтнең үз традицияләре һәм мәдәнияте бар. Әмма традицион диннәрдә булган кыйммәтләр барлык халыклар өчен дә уртак. Бер Аллаһка чакырган диннәр үз өммәтен әхлаклы булырга һәм барлык кешеләрнең дә, милләтенә карамастан, бер уртак атасы Адәм галәйһиссәләм икәнлегенә өйрәтә. Безнең илдә яшәүче халыкларның традицияләре уртак тамырларга ия һәм барысы да сафлыкны, тыйнаклыкны, игелекне данлый. Россия халыклары үзләренең милли-дини үзенчәлекләрен саклап калу өстендә эшләсә, бу Россия бөтенлегенә бернинди дә куркыныч тудырмый. Киресенчә, гражданнарда Ватан – дошманнардан һәм чит-ят күренешләр үтеп керүдән сакланырга тиешле туган йорт белән бәйле төшенчә, дип аңлауны шулай гына формалаштырырга мөмкин». Мөфти аңлатканча, намаз бүлмәләрен ябу, хиҗаб һәм дини әдәбиятны тыю һ.б. Россия җәмгыяте өчен кабул ителгән норма түгел һәм тәнкыйтьләнә торган очракларга керә, әмма алар диннәр арасындагы үзара аңлашуны какшата һәм шуның белән гражданнарда Ватанга мәхәббәт тәрбияләүгә кыенлаштыра.

Конференция нәтиҗәләре буенча мөфтиләрнең РФ Президенты В.В.Путинга һәм бөтендөнья мөселман өммәтенә мөрәҗәгатьләре эшләнде. Моннан тыш, җыенда катнашучыларның тәкъдим ителгән сорауларга карата позициясен чагылдырган резолюция кабул ителде.

Эльмира СИРАҖИ.

ИСХАКЫЙ ЯДКӘРЕ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Йөзләгәне үз муеннарына тагылган «тавык тәпиләрен» йолкып һәм Инҗил китапларын чыгарып ташлап, баскыннар куәсеннән ябесен булса да, Ислам динен тоткан. Соймонов атлы җәллад генерал, кабат үз диненә кайткан өчен, Кисәбикә-Хөснибикә Байрасова атлы татар хатынын 1739 елда Екатеринбург каласының үзәк мәйданында баганага бәйләп яндырып үтергән. Һаман үз диненә кайткан йөзәрләгән татар кешеләрен еракта Себер сазлыкларына озаткннар. Баскыннардагы мондый кансызлыкка түзмичә, бүгенге Башкортстанның Балтач районыннан чыккан ахун Габдулла Галиев 1755 елда мөселманнарның ихтилал фетнәсен күтәргән һәм Батыршаһ наме белән танылган. Аны хәтта кулга алып һәм Петербургтагы Шлиссельбург зинданына ябып куеп та тезләндерә, җиңә алмаганнар. Ислам динен яклап бәхәскә кергән өчен «изге» атакайлар куллары-аяклары зынҗырланган шул «бичара» тоткынның да телен тартып өзгән. Ни гаҗәп, ни галәмәт, Батыршаһ хәтта телсез калгач та тез чүкмәгән. Камера ишеге ачык калдырылган беренче очрактан ук оста файдаланып, ул коридорда яткан утын балтасын кулына алган һәм, сакчылар өстенә ташланып, дүрт дошманын шундук юк иткән. Бишенчесе өстенә барган чакта, йөрәге ярылып, аягүрә көе җан биргән...

Исхакый драмасының төп герое Зөләйха да, хак-асылда, бөек Батыршаһ яки аннан соң ук баш күтәргән Морат мулла кавеменнән. Әллә ничә тапкыр көчләп чукындырырга да карамастан, ул гомере буе үзенең изге диненә һәм милләтенә тугры калган. Туктаусыз кыйналу һәм изүләргә түзмичә ирен үтергән өчен 20 ел буе төрмә газапларын кичерсә дә, һаман газиз Аллаһы Тәгаләгә табынган. Мәңгелеккә дә ул Аллаһ колы, диндар булып күчкән. Әгәр гомере большевиклар дигән кавем изүенә туры килгән булса, һичбер шик юк, аны да, мөгаен, 1938 елда Уфа төрмәсенең диварына терәп атылган бөек Мөхлиса Буби-Нигъмәтуллина язмышы урап үтмәс иде...

Менә шулай итеп кат-кат күздән кичергәч, Исхакыйның Зөләйхасы да тереләй көе яндырып үтерелгән Хөснибикә Байрасова, теле йолкынган Батыршаһ, төрмә диварына терәп юк ителгән Мөхлиса Бубилар белән бер үк сафта калка. Зөләйха-Хөснибикә-Мөхлисалар образының мәңге сүнәсе юк. Илсез-җирсез калуыбызга биш гасырга якын гомер үтсә дә, безнең милләткә басым һич кимеми. Әнә, кабат телебезне йолкырга, мәҗбүриләп россиянлы милләтенә әверелдерергә, яңа төрле «тавык тәпие» тагарга тырышалар. Без һаман икенче сортлы, буйсынудагы халык. Димәк, юкка чыкмау, изелеп һәм йотылып бетмәү өчен, Батыршаһ-Мөхлиса-Зөләйхалар рухы тансык әле безгә.

Талантлы сәнгать эшлеклесе иде



Танылган татар язучысы, шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рашат Низамиев көтмәгәндә, 2023 елның 1 сентябрендә вафат булды.

Рашат Низамиев 1950 елның 1 мартында Саба районы Олы Мишә авылында (хәзер Теләче районына керә; Олы Яңавыл исеме белән дә билгеле) колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе сугыштан бер кулын югалтып кайткан, амбар мөдире, әнисе хат ташучы булып эшләгән. Р.Низамиев башлангыч мәктәптә Олы Мишә авылында укыганнан соң Олы Саурыштта сигезьеллык мәктәптә укуын дәвам итә. 1967 елда Иске Икшермә урта мәктәбен тәмамлый. 1972 елда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем ала һәм шуннан соң Биектау районының Олы Битаман авылы мәктәбендә укытучы булып эшли.

1974–1981 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында корректор, җаваплы сәркәтип, 1981–1983 елларда «Ялкын» журналында җаваплы сәркәтип.

1983–1997 елларда «Казан утлары» журналында баш мөхәррир урынбасары, 1997–2005 елларда «Идел» журналы баш мөхәррире. 2007 елдан «Казан утлары» журналында эшли. «Йолдыз яңгыры» исемле беренче шигъри җыентыгы 1980 елда дөнья күрә. «Кызыл җәй», «Тормыш трамвае» шигырьләр китабы, повестьлар һәм хикәяләрдән торган «Бөек сер» (1986), «Кызыл кар яугач» (1993), «Яшьлеккә хат» (2003), балаларга атап язылган «Яралы керпе» (1987), публицистик язмалардан торган «Алдым каләм кулыма» (2007) исемле китаплар һәм «Фәрит Яруллин» дип аталган документаль романы авторы.

Ул Әтнә районының Бәрәзә авылы зиратында җирләнде.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе.
«Мәдәни җомга» газетасы редакциясе.

● Америкада каскадер Ивел Книвел гомере буе мотоциклда трюклар ясый, барлыгы 37 сөяген сындыра һәм бергә кушып санаганда өч елын хастаханәләрдә үткәрә, шулай да 69 яшенә җитеп кенә дөнья куя.

● Олимпиадада җиңгән өчен бирелә торган алтын медальләр 92,5 процент көмештән тора, аларның һәрберсендә әлеге кыйммәтле металл 6 граммнан кимрәк булмаска тиеш. Соңгы чын алтын медальләр исә 1912 елда Стокгольмда үткән Олимпия уеннарында бирелгән.

● Америка спортчыларының Олимпия уеннарында яуланган алтын яки көмеш медальләренә салым салына, ә менә бронзага салынмый – чөнки ул нигездә бакырдан ясала.

Байсар авылына 450 ел



«Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире, танылган язучы Вахит Имамов Актаныш районындагы Иске Байсар авылына 450 ел тулуын исбатлаган. Ул әлеге истәлекле датаны билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

«1653 елгы тарихи документта Уфа провинциясе канцеляриесе Бүләр авылында гомер итүче 80 яшьлек карт Байсар Күзәш улының воевода Иван Франзбеков исеменә язган үтенечен терки. Үтенечтә Байсар карт үзенең бу авылда 80 ел буе дәүләткә тиешле ясакны бер елда да өзмичә, даими рәвештә Уфага – 10 сусар, Казанга 2 сусар тиресе һәм 5 батман бал күләмендә түләп килүе турында бәян итә. Өлкән яшьтә булуы сәбәпле, әлеге ясак күләмен бүгенге Мөслим районы Турыш авылы крестьяны Айтуган Сабаков белән бүлешеп түләргә рөхсәт бирүләрен сорый», – ди В.Имамов.

Аның әйтүенчә, әлеге документ Бүләр-Байсар авылының тарихын 1573 ел белән бәйләргә нигез бирә. «Димәк, быел Иске Байсар халкы үз авылларының 450 еллыгын билгеләп үтәргә хокуклы. Безнең якта башка 450 еллык авыллар юк. Бу бөтен татар халкы өчен кирәкле чара. Агыйдел олысы Болгар дәүләте чорында ук булган, Гәрәй, Бүләр, Кыргыз, Янәй һ.б. волостьларда татарлар яшәгән. Ул – хәзерге Татарстан һәм Башкортстан республикаларындагы чиктәш территорияләр. Бу чара башкорт мөтәгалимнәренең Минзәлә өязе җирләренә борын сузуын туктату өчен дә кирәк. Чөнки 1550-1570 елларда гына түгел, хәтта әле 1750-1800 елларга кадәр дә Казан белән Уфа арасында, ягъни Кама аръягында сыңар гына да «чиста» башкорт олысы урнашмаган булган».

В.Имамов Байсар авылының 450 еллыгын район күләмендә үткәрергә, чарага Байсар авылыннан башка җирләргә күчеп киткән кешеләрне дә чакырырга кирәк, дип исәпли.

«Байсар авылыннан биш чакрымда 1738 елда Мәчти-Наратлы, 1860 елларда Сөн елгасы буйлап ике чакрым югарыда Яңа Байсар авылы барлыкка килә. Шул ук елда иллеләп гаилә Башкортстандагы Яңавыл районына күчеп китә һәм андагы Биз елгасы буенда янә Байсар исемле өр-яңа авыл кора, ул үз исемен алыштырмыйча 2015 елга кадәр гомер итә. 1927 елда Иске Байсар авылыннан аерылып, Сөн аръягында Чишмәбаш саласын нигезләгән якташларыбызны да онытырга ярамый», – ди ул.

В.Имамов 1773 елдагы Пугачев күтәрелешендә Байсар авылыннан гына да 31 кеше катнашуын ассызыклый. «Байсар авылы турындагы китабым күптән әзер инде, кайчан да булса басылып чыгар, дип тә өметләнәм. Китапта бик күп архив документлары урын алды. «Европада татар җайдаклары» дигән аерым бүлек бар, анда мин 1757 елда Пруссиягә ясалган походта Актаныш төбәге һәм якын-тирә 18 авылдан киткән 80 кешенең исемен, шул исәптән, Байсар авылыннан дүрт кешенең исемен тәкъдим итәм. Россиядә булган барлык тарихи вакыйгаларда да Байсар авылы халкы актив катнашкан. 1812 елдагы Ватан сугышына да Байсарлылар барган, икешәр медаль алганнарының исем-фамилияләре билгеле. Ләкин Татарстан хөкүмәте, фән белгечләре дә бу турыда белергә, каһарман якташларыбызның исемнәрен мәңгеләштерергә теләми. Югыйсә, бик күп бабайларыбыз 1757, 1771, 1812 елларда ук Пруссия, Польша, Франция җирләрендә һәлак булган. Тик ни өчендер, Татарстанда әлеге вакыйгаларга бәйле бер генә һәйкәл дә юк. 1914 яки 1941 елларда һәлак булган бабаларыбыз кебек үк, 1812 елгы Ватан сугышында башын салган бабаларыбыз да безгә кадерле, алар да бүгенгеләр өчен бер үк кан, бер нәсел бит», – дип ачына танылган язучы.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
Рифкать БИЛДАНОВ фотолары.

Хәзерге шигъриятьтә синонимнар

Ш.Ханбикова үзенең «Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр» хезмәтендә, синонимнарны тезеп китү төрле максатларда файдаланырга мөмкин, дип яза. Ул аларны якынча унга бүлеп күрсәтә. Тикшеренүләр үткәргәннән соң, мәгънәдәш сүзләрнең поэзия телендә түбәндәге максатларда ешрак файдаланылулары ачыкланды:

1. Күпмәгънәле сүзнең кайсы мәгънәсендә кулланылуын ачыклау өчен. Бу төр синонимнар шигъри текстларда аеруча еш очрый. Мәсәлән, татар телендә изү сүзенең берничә мәгънәсе бар, алар «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә теркәлгән:

изү – I. 1) Каты яки порошок сыман нәрсәне су кушып болгатып, йомшак, сыек яки боламык хәленә китерү; 2) Әйберне зур авырлык астында калдырып басу, яньчү, сыту, таптату, шәкелен бозу; 3) күч. сөйл. Бик каты, хәлдән тайдырганчы кыйнау; 4) күч. Йөрәккә авыр булып, борчып, җәфалап, газаплап тору; 5) күч. Төрле авырлыклар, дөнья мәшәкатьләре басу, газап чиктерү, хәлдән тайдыру, эштән чыгару; 6) күч. Иктисади, сәяси һәм рухи яктан кысу, җәберләү; 7) күч. сөйл. Бер үк сүзне кат-кат сөйләү, кабатлау; 8) күч. сөйл. Кирәксез, зарарлы эш эшләү, җайланган эшне бозу; 9) күч. сөйл. Танымаслык, аңлашылмаслык хәлгә китерел бозу.

II. (Иктисади, сәяси һәм рухи) кысынкылык, җәбер, эксплуатация.

III. 1) Киемдә муен турысында күкрәк авызына таба уелган ерык һәм шул ерыкның һәр ике ягы; 2) этн. Татар хатын-кызларының төрле төстәге тасмаларны изү тирәли тегеп, укалар белән чигеп эшләгән, күлмәк якасыннан алып билгә кадәр бөтен күкрәкне каплый һәм бизәнү өчен күлмәк өстеннән киелә торган күкрәкчәсе.

М.Әгъләмов әлеге сүзне түбәндәгечә файдалана:

Күпереп торган илне изү, басу,
Камыр азык ясау дәвам итте…
…һәм, ниһаять,
Өркетелгән милләт
Кимсетелгән милләт…
тәпи китте.
(«Хәтер көне»)

Шагыйрь аның төрле авырлыклар, дөнья мәшәкатьләре басу, газап чиктерү, хәлдән тайдыру, эштән чыгару мәгънәсендә кулланылганлыгын басу фигыле ярдәмендә ачыклап китә.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә кичерү сүзенең 4 мәгънәсе бирелгән. Түбәндәге мисалда ул гафу итү мәгънәсендә кулланылган. Зөлфәт шул рәвешле кичерү фигылен «аныклап» үтә:

Мин кичермим!
Мәңге гафу итмим!» –
Әткәң-әнкәң җыры шул булыр.
Татар! Татар! Моны аңлаганчы
Вакыт узган булыр, соң булыр!
(«Соңгы язмыш яры»)

2. Гомумән сүзнең мәгънәсен аныклау, тулыландыру өчен кулланылган синонимнар. Әлеге очракка да мисаллар еш очрый. Мәсәлән:

Күрәсезме, әнә шул көрәштә
Күзгә карап ил алышына.
Үзгәрә бит Татарстан йөзе –
Кешеләрнең йөзе үзгәрә.
(М.Әгъләмов «Татар көрәше»)
«Әллә нинди дәшмәс йолдыз!» – димсез
Янәсе, без шуңа гел ялгыз.
Ул нигъдер усал караганда,
Пәйда булганбыз без, туганбыз...
(Зөлфәт «Казык йолдыз»)
Шул тузанда мин үзем дә
торам әле чак-чак басып.
Юк, тайпылмыйм, китмим читкә,
тузаным да миңа тансык.
(Зөлфәт. «Мин үтәсе бу юллардан...»)

Югарыда китерелгән шигырь юлларында синонимнар мәгънә төсмере белән бер-берсеннән аерылса да, тулы картинаны күз алдына китерү өчен, автор тарафыннан уңышлы файдаланылган.

3. Чит телдән кергән сүзләргә, терминнарга аңлатма бирү өчен аныклагыч рәвешендә кулланылган синонимнар. Авторлар алынмаларны кулланса да, аларның шигырьләрдә синонимлашуы юк дәрәҗәсендә. Ә терминнар исә, жанр таләбенә туры китерелеп, бөтенләй кулланылмый.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә француз теленнән кергән мираж сүзе түбәндәгечә аңлатыла: мираж – фран. 1) Горизонтта күкнең ялган сурәтләреннән яки ялган җир предметларыннан гыйбарәт оптик күренеш; 2) күч. Аңда, хыялда тудырылган нәрсә, хыял [б. 367]. Бу лексик берәмлек татар телендә рәшә сүзе белән мәгънәдәшлектә тора. Алар икесе дә телдә актив кулланылышта йөри һәм шигъри текстларда да урын ала:

Мөстәкыйльлек шулай килер дисәк,
Бу алдавыч мираж, бу – рәшә...
(М.Әгъләмов «Татар көрәше»)

4. Көчерелмә мәгънәдәге образлы сүзнең мәгънәсен аныклау, ачу өчен тәкъдим ителгән синонимнар. Бу төргә шагыйрьләр иҗатыннан түбәндәге мисалларны күрсәтергә мөмкин:

Кайный Казан, гөрли Казан,
Без нәкъ шуның уртасында.
Без – бар! Димәк, сөю яши,
Димәк, яшәр бездән соң да.
(М.Әгъләмов. «Без – бар!»)

Автор кайнау, гөрләү кебек контекстуаль синонимнарны шулкадәр уңышлы файдаланган ки, күз алдына пар бөркеп кайнаучы казан килә. Ә чынлыкта исә әдип башкалада барган эш-хәлләрнең, вакыйгаларның һәм анда катнашучыларның күңел кичерешләрен бирергә тели.

Моңа дәлил буларак түбәндәге шигъри юлларны да китерергә мөмкин:

Мин янам, шатланам, газапланам,
гаҗәп түгел – дөнья бу!
Карап тора миңа күзләр –
йөзләремдә тук елмаю.
(Р.Зәйдулла. «Мин янам...»)

Биредә автор лирик геройның күңел кичерешләрен тасвирлау максатыннан төрле мәгънәдәге сүзләргә мөрәҗәгать итә, ләкин контекстта алар арасында мәгънә бәйләнешләре барлыкка килә.

5. Сүзнең билгеле бер мәгънәсенә яки мәгънә төсмеренә басым ясау өчен кулланылган синонимнар. Бу төр – шагыйрьләр тарафыннан шулай ук яратып кулланыла, чөнки хиснең югары ноктасын тасвирлауда уңышлы алым булып санала:

Рәнҗүләргә, әрнү, үпкәләргә,
Кимсенүгә хәтле
Тел тидереп сүз әйтүме әллә?
Сүз дә мәрхәмәтле.
(М.Әгъләмов. «Сөю булып җиргә алма ява»)

Әлеге синонимнар кеше күңелендә генә була ала һәм саклана торган авыр хис-кичерешләрне тирәнрәк бирү өчен кулланыла.

6. Нинди дә булса күренешкә тулырак, күләмлерәк характеристика бирү өчен. Бу төргә карый торган синонимнар еш кына парлы сүз буларак та кулланыла. Алар, контекстуаль синонимнардан тора, ләкин тасвирлау объектын тулаем күз алдына китергән вакытта мөһим роль уйный:

Син ипләгән, син сипләгән сүзләр, –
Аңлап, сизеп, тоеп карасаң, –
Якты гомер, утлы күмер икән ләбаса!
(Зөлфәт. «Шигырьдәш»)

7. Нинди дә булса бер билгене тулырак итеп, төрле яктан ачу өчен. Мәсәлән, Р.Зәйдулла халык күңелендәге рәнҗү хисен түбәндәгечә тасвирлый:

Кайда соң ул Тукай күргән
Без бергә теркәлгән җеп?
Гәрәйләрнең сөякләре
Хурланып ята, рәнҗеп. *(«Җеп»)*

Алдагы шигырь юлларында исә ялгыш төшенчәсе ачы, зур сыйфатлары ярдәмендә ачыла. Әлеге синонимнар кылынган ялгышның күләмен, көчен тагын да арттыра:

Йокы аралаш төшләренә кереп,
И йөдәтә икән бер тавыш:
– Йоклау татлы булды синең өчен –
Бу гамәлең ачы, зур ялгыш.
(В.Фатыйхов. «Рәиснең йокы сәгате»)

8. Сөйләмгә киеренке, тәэсирле, гомумән патетик тон бирү өчен. Бу төркемгә керә алырдай мисалларның да күп булуы ачыкланды. Мәсәлән, җанга якын, кадерле булган төшенчәләрне бирү өчен:

Изге өем минем, газиз Татарстан!
Ничә буын инде синдә тапмый җылы,
Яки уңга китә,
Яки сулга китә –
Уңга-сулга китә улларыңның юлы.
(М.Әгъләмов. «Бүген»)

Алдагы мисалда диңгезгә хас сыйфатлар кешегә күчерелеп, аның күңелендә бара торган киеренке хисләрне белдерә:

Сөю тотты да тынлыкны
Урлап китте тәмам.
Хуш, тыныч яр!
Саумы, диңгез!
Дөрлим, дулкынланам.
(Р.Зәйдулла. «Битараф идем...»)

9. Эш, күренеш, процессның дәвамлылыгын, интенсивлыгын күрсәтү өчен. Бу алымнан аеруча М.Әгъләмов оста файдалана:

Яшәргә килгән буласың
Матурлык белән генә,
Мәгънәсез Вакыт
…Сындыра…
…Җимерә…
…Вата…
…Бөгә…
(«Матурлык безнең белән»)

Бу синонимнар «Синонимнар сүзлеге»ндә түбәндәге тәртиптә бирелә: вату – туздыру; җимерү; бозу; зыян китерү; сындыру. Әдип исә, синонимик рәтне кире тәртиптә кулланып, көчле тәэсир тудырырга ирешә. Түбәндәге өзектә дә бу рәвешле кулланылган мәгънәдәш сүзләр укучыга процессның көчәюен анык күзалларга ярдәм итә:

Сызланадыр...
Әрнидер.
Авыртадыр ла тәне
Кыйнылйлар шул
Көтү белән
Йөрисе килмәгәнне.
(Р.Зәйдулла. «Качкын»)

«Синонимнар сүзлеге»ндә бу берәмлекләр түбәндәге тәртиптә бирелә: авырту – сызлау; әрнү; сыкрау; чәнчү; чәнчешү; сулкылдау; сулыгу; сыкрану. Автор исә аларны киресенчә куллана.

10. Иң югары яки иң түбән дәрәҗәне бирү өчен. Мәсәлән:

Ә бит туңам…
Суык…
Калтыранам.
…Күкрәгемнән алып үпкәне
Суган, борыч салып табалыкта
Кыздырмакчы идем.
(М.Әгъләмов. «Кан туганым син…»)

Салкын, суыкның тәнгә тәэсире нәтиҗәсендә кеше туңа, ә калтырану исә шул туну халәтенең бер билгесе генә, әмма шигъри юлларда ул процессның югары дәрәҗәсе буларак бирелә.

Киләсе өзектә билгеләнгән сүзләр үзара тигез хокуклы синонимнар булса да, иң түбән дәрәҗәне белдерү чарасы буларак, бер-берсен тулыландырып килә:

Анда Сәйдәш моңсу көлемсери,
Сибелә көй әкрен, тын гына.
Сибелә язмыш...
Җирдә яшәүләре
Читенрәк икән моңлыга.
(Р.Зәйдулла. «Күз яше»)

Мисаллардан күренгәнчә, шагыйрьләр синонимнарны төрле максатларда куллана. Биредә шуны да искәртеп үтү кирәк: кайбер синонимнарны бер үк вакытта берничә төргә кертеп карарга мөмкин. Мәсәлән, фикерне төгәлләү, аныклау яисә басым ясау, ассызыклап күрсәтү өчен кулланылган төрләргә. Монда авторның һәм укучының субъектив фикерләре мөһим роль уйнавын да ассызыкларга кирәк.

Мәгънәдәш сүзләр күбрәк олы һәм урта буын шагыйрьләрдә очрый. Яшьләр исә, нигездә, телдә еш кулланыла торган синонимнар белән чикләнәләр, алар иҗатында мондый чараларны төрләндерүгә омтылыш бик сизелми.

Эльвира ДЕНМӨХӘММӘТОВА,
филология фәннәре кандидаты.
«Фәнни Татарстан» журналыннан.

Рәис САФИН

Җир-күкләрнең кисәтүе булып, Кышын – яңгыр, җәен кар ява...

КИЛЕР БЕР КӨН...

Әллә белеп, әллә саташыпмы,
Кышын яңгыр, җәен ява кар.
Һәлакәткә илтер хаталарда
Кем гаепле, нинди серләр бар?

Җәмгыятьләр асты өскә килә,
Ил-дәүләтләр тузгып таркала.
Әхлаксызлык канунлашкан саен
Кышын яңгыр, җәен кар ява.

Берәүләрнең иңе тар булса да,
Колачламак бөтен дөньяны.
Кышкы яңгыр, җәйге кар шикелле,
Канлы-яшьле булыр зыяны.

Кешеләрне, игеннәрне егып,
Кышын яңгыр, җәен кар ява.
Табигатьнең кануннарын бозган
Бәндәләрдән Күкләр үч ала.

Җир-күкләрнең кисәтүе булып,
Кышын – яңгыр, җәен кар ява.
...Килер бер көн:
Азып-тузган хәсис мөртәтләрен
Алыштырыр Аллаһ башкага.

И ТУГАН ТЕЛ!..

Кан кардәшем, чал башымны иеп,
Сине сөеп, синә эндәшәм.
Татар белән татар үз телендә
Әйтсен: «Мин татарча сөйләшәм».

Уянырлар шулчак күзәнәкләр,
Калкып чыгар татар тамырдан.
Күкләр күкрәп, яшеннәре яшьнәр,
Җир яшәрер җылы яңгырдан.

Әй, адашкан, кыйбла югалтканнар, –
Маңкортлашкан татар туганнар,
Ана телсез, изге динсез калып,
Чит-ятларның колы булганнар...

Сезгә дәшәм: сез дә бабаларның
Әманәтле татар оныгы.
Рухыгызда, каныгызда сезнең
Милләтебез нәсел орлыгы.

Без мәңгелек ислам динле халык,
Телебез дә – Аллаһ бүләге.
Әл-Коръәннең телен белгәннәрнең
Кыямәттә булыр кирәге.

Агачларны яфраклары бизи,
Кеше күркәм – холкы беләндер.
Һәркемне дә дәрәҗәле итә –
Ана теле, газиз, бердәнбер!

ЯШӘРТИК ӘЛЕ ҖИРЕБЕЗНЕ...

Басуларны чүп үләне басты,
Колач җәйде әрсез әрекмән!
Балтырганнар, шайтан таяклары...
Килде безгә башка җирлектән.

Ил-җирләрне яулап алды шулар,
Яфракларын җәеп як-якка.
Капладылар кояш, ай нурларын,
Котырынып үсеп сабакка.

Элеккечә чайкалмыйлар инде
Талгын җилдә иген кырлары.
Башакларның дулкын очларында
Балкып тормый кояш нурлары.

Кысыр җирдә ачы җилләр уйный,
Тәгәрәшә сәяр кылганнар.
Килмешәкләр илне талап йөри –
Кан-яшь коеп аран корганнар.

Сыкрана җир яраларын ямап,
Зар(ы)гып көтә хаклы хуҗасын.
Аллаһыдан вәгъдә ирешүгә,
Белә аның хуҗа буласын!

Әй, кардәшем, җиңнәреңне сызган,
Чүп үләннән тазарт иленне,
Бабаларның хаталарын төзәт,
Хөр-азат ит мирас җиреңне!

ДӨНЬЯ ГАМЕ

Дөньяның бар ике гаме:
Яхшы, яман гамәле.
Яшәеш өчен көрәштә
Һәркемнең үз әмәле.

Яхшылык – Аллаһ гамәле,
Явызлык – иблис эше.
Кылыч болгап ил яулаучы –
Иблистән яман кеше.

Шул яманнар иш-ишәйсә,
Явызлык баш күтәрә.
«Ут чәчеп, давыл уручы»
Һәлакәткә этәрә.

«Яхшылык – җирдә ятмас», ди,
Алтын да хакын җуймас.
Җир-күкләрнең ил туенда
Явызлык кияү булмас.

Һәркемгә дә фарыз булсын, –
Аллаһ гамәлен кылсын.

БОРЧЫЛУ ҺӘМ ӨМЕТ

Кем әйтмешли, утлар-сулар кичтек,
Дөнья сәхнәсендә сыналдык.
Фиргәвеннәр замандашы булып,
Чорлар кайрагында чарландык.

Татар булдык. Өч кыйтгада бердәй
Ил-дәүләтләр кордык шәһрәтле.
Мәгърифәтле булдык, гыйлем чәчтек,
Үрнәк татар булдык, әхлаклы.

Язлар ел да гөрләп чәчәк атты,
Җәйләр ил-хәятне яңартты.
Киң далада терлек саны артты,
Ефәк юлын урап мал кайтты.

Гамьсез булдык, уяулыкны җуйдык,
Ил капкасын ачтык дошманга.
Аш атканга ул туп, ядрә атты,
Ил-җиребез батты яшь-канга.

Бөтен дөнья хәрәкәттә яши,
Тик үзгәрми тәүге асылы.
Татарның да ай-кояштай балкыр,
Мәңге яшәр милли акылы!

ЭЗЕҢ КАЛСЫН...

Кемнәр килеп, кемнәр китмәгәндер,
Сулар аккан, җилләр искәндер.
Искән җилләр, аккан сулар кебек,
Әллә кемнәр килеп киткәндер.

Әти салган йортлар искергәндер,
Берәүләре тузып аугандыр.
Заманының истәлеге булып,
Нигезләре генә калгандыр...

Тик берни дә үтми эзсез генә,
Ат аунаган җирдә төк кала.
Һәр гамәлең килер буыннарның
Гомер сөрешендә сынала.

Яхшысы да, яманы да – синең
Нәселеңнең булыр өлгесе.
Балта остасы газиз әтиемнең
Йортлар булды мактау билгесе.

Еллар узды. Бу тормышта мулдан
Күрдем агын, күрдем карасын.
Һәр эшемдә тоеп гомер иттем
Ата-бабамнарның мирасын.

Кемнәр килеп, кемнәр китмәгәндер,
Һәркемнең дә кала үз эзе.
Буыннарның нәсел каннарында –
Оныкларның йөрәк тибеше!

БЕРДӘНБЕР!

Бу дөньяга кемнәр килеп китмәгәндер,
Һәркем изге гамәл кылмак теләгәндер.
Бөекләрнең тарих белә исемнәрен,
Саклап тора ташка баскан әсәрләрен.

Һәрберсе булган мәшһүр, булган даһи,
Табигатьнең кануннары бит илаһи.
Күк йөзенең йолдызлары күп меңнәрдер,
Балкып торган нурлы кояш тик бердәнбер!

Дөньядагы китап санын кем белгәндер?
Изге китап – Коръән-Кәрим тик бердәнбер.
Дәрәҗәдә булса да һәр уйлы фикер,
Акыл дигән илаһи көч тик бердәнбер.

Өч кыйтгада дәүләт тоткан – төркиләрдер,
Пассионар татар халкы да тик бердәнбер.
Бердәнберлек – тиңсезлекнең бер төредер,
Аллаһы да өчәү түгел, тик бердәнбер...

АРЫН!

Эш-гамәлме, әллә сүзме алдан?
Фараз кылсын галим-голәмә.
Әйткән сүзе затны мәшһүр итә,
Легендага кеше әйләнә.

Кешене эш, күркәм иҗат данлый –
Шулай булган борын заманнан.
Таш гасырлар аша алгарышка
Килгән кеше ерак чорлардан.

Без – татар да төрле кавем булып,
Шанлы-канлы авыр юл үткән.
Гамәл кылып, ил-дәүләтләр корып,
Бөек халык булып җитлеккән,
Сакланмаган ләкин этлектән.

Чит-ятларның усал ач этләре
Ябырылган аның өстенә.
Хыянәтчел хәйлә һәм мәкерле
Этләр белән икән эш йөртмә...

Эт-этлеген итә, тешләп китә,
Хуҗасын да талый симерсә.
Азгын этләр урлап, талап йөри,
Ил-дәүләтнең малын бүлешә.

Табигатьне бүре – санитарлар
Арындыра, диләр, казадан.
Арын, татар, җаһил этләр кебек
Баскын биргән газап-җәзадан!

БУЛДЫР ӘЛЕ!

Мөхтәрәм Фәндәс Сафиуллинның
якты истәлегенә.

Милли университетыбыз
халкыбызны
Киләчәккә алып барачак
локомотив булыр.
Фәндәс Сафиуллин.

Локомотив тукталышта тора,
Йөгерешми җитез вагоннар.
Халыкларга белем-гыйлем нуры,
Җан җылысын илтә торганнар.

Белеме бар меңне ега булыр,
«Белем ал син барып Кытайга».
Туган телне локомотив итик,
Алып барсын безне уңайга!

Үсемлек тә үсмәс, чәчәк атмас,
Җимеш бирмәс кояш булмаса.
Адашырлар иде – ай яктысы
Нурлар сирпеп күктә тормаса.

Газиз халкым, җыеп аң-исеңне,
Ай-кояшлы ит син үзеңне.
Булдыр әле милли университет
Фәндәс Сафиуллин исемле!

ТАТАР МОҢЫ

Татарымның моңлы-зарлы моңын
Уйга чумып тыңлыйм ис китеп.
Назлы моңнар айкый бәгыремне,
Күңелемне тора үксетеп.

Илаһи моң татарымны сөеп,
Җир-күкләрдән ингән җанына.
Башым иям әби-бабайларның
Җан авазлы милли моңына.

Татар моңы – моңнарыбыз таҗы,
Энҗе-мәрҗәннәргә бизәлгән.
Остазы ул халкым көйләренең,
Тәсбих сыман җепкә тезелгән.

Татарымның милли рухы сеңгән
Татар моңы, яшә берлектә.
Күкләр күкрәт, җанда яшен уйнат,
Нурлар булып балкы тәхеттә!

ИСХАКЫЙ –

Гаяз Исхакыйның әдәби эшчәнлегенә кагылышлы беренче җитди мәгълүматлар 1900 елда, Казан шәһәрендә «Кәләпүшче кыз» повесте басылып чыккач, Кырымдагы Бакчасарай каласында Исмәгыйль бәк Гаспралы тарафыннан нәшер ителә торган «Тәрҗеман» газетасында ук елдан күренә башлый. Әмма вакытлы матбугатта Т.Исхакыйның тормыш юлы хакында язу һәм аның иҗатына тулаем күз салу процессы бары тик 1904 елдан соң гына көчәеп китә.

Аерым алганда, Г.Исхакыйның 1904 елда басылган «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле фантастик-публицистик повесте татар дөньясын тетрәтеп җибәрә, һәм шул вакыттан бирле инде бу әсәр берничә буын татар кешесен тәрбияләүдә, аның дөньяга карашларын формалаштыруда актив катнашып килә. Әсәр, басылып чыгуга ук, татар дөньясындагы төрле катлам вәкилләренең игътибарын үзенә тарта һәм милли матбугатта аның хакында җитди генә мәкаләләр, тикшеренүләр басылып чыга. Шулар арасында Н.Хуҗашиның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре хакында», Г.Гобәйдуллинның «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары» һәм «Ике йөз елдан соң инкыйраз (комментарий)», Н.Гасрыйның «Шимали төрки әдипләреннән Гаяз Исхакый», Г.Ибраһимовның «Әдәбият агымы» («Ике йөз елдан соң инкыйраз» турында), С.Рәмиев белән Г.Хөсәеновның «Мөхәммәтгаяз әфәнде» дип аталган хезмәтләрен күрсәтергә була. Чөнки бу язмалар Г.Исхакый әсәренә төгәл һәм дөрес бәя биреп кенә калмыйлар, бәлки аның татар дөньясы өчен гаять зур әһәмияте булуын, милләтне инкыйраздан саклап калу өчен максаты ачык күренгән җитди программа тәкъдим итүен дә билгеләп узалар. Бу нисбәттән Газиз Гобәйдуллинның «Ике йөз елдан соң инкыйраз (комментарий)» дип аталган хезмәтендә әсәргә бирелгән гомуми бер нәзар Гаяз Исхакый повесте хакында язып чыгучыларның уртак фикерен бер юнәлешкә туплый алу сәләте белән үзенчәлекле.

«Аның һичбер әйткән нәрсәсе юк ки хисебезгә сукмасын... Иске заманнардагы «Курчак» туйларын, байларның тормышларын яки болгар агаеның сәүдәдәге хәрәкәтен сөйлиме, йә бер конференц тасвир итәме, йә татар рәссамнары ясаган рәсемнәр турысында язамы – һәммәсендә йөрәгемезгә тия, һәммәсе «аркаларымызны чеметтереп-чеметтереп ала». Аның тасвирлары безне шаккатырып калдыралар. Ни әйтергә дә белдермиләр. Әле үткәнемезне сүктерәләр, әле бөтенләй өметемезне өздерәләр дә бер хиссез калдыралар йә киләчәккә өметне уяндыралар да «көрәшкә» өндиләр.

Тормышыбызны язуда әүвәл һичнәрсәдән курыкмый, сүзне дә ул үлчәп тормый, укучыларны уятырга тырыша... Ул каты җөмләләрдән курыкмый, чөнки аның җиңел каны безне бишеккә салып тирбәтәсе, йоклатасы килми, әмма йоклаганда «кабыргамызга» төртәсе килә...»

Гаяз Исхакыйның чираттагы иҗат уңышы булган һәм шулай ук татар дөньясына көчле тәэсир иткән «Кәләпүшче кыз» повесте турындагы җитди мәкаләләрнең берсе күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, үзе дә әдәби әсәрләр иҗат иткән Йосыф Акчура яза. Аның «Гаяз әфәнде» дип исемләнгән мәкаләсе «Й.Акчура углы» имзасы белән «Казан мөхбире» газетасында дөнья күрә. Ул Г.Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» повестена язган рецензиясендә тәэсирләрен болай белдерә: «Татар әдәбиятыннан иң күп тәэсир бирлән укыган китабым «Кәләпүшче кыз» булды. Ул заман зиһенемне Казанның карлы, тавышсыз, җансыз көннәре, кыска буйлы татарларның йомшак киез итекләре белән Плэтән урамында сак кына йөрүләре, мәчет манараларыннан бер дә еракларга сузыла алмаенча эре-эре яуган кар кисәкләре арасында югалган азан тавышлары, хөласән (җыеп әйткәндә), татарлар Казанны тутыра иде. «Кәләпүшче кыз»ны укыр өчен мин шул Казанда гомер иттем һәм милләтемә чыккан иң тәһликәле (һәлакәтле), иң агулы бер чобанның сызлавын үз рухымда хис кыларак гомер иттем. Хикәянең икенче басылуында гыйлавә (кушымта) ителгән хатны укыганда чыдый алмадым, «Корнея Латэн» мөсафирханәләреннән беренең хөҗрә – караңгы, фәкыйрь бер бүлмәсендә япа-ялгыз мескен татар кызының сөкуте (өнсез калуы), фәләкәте (афәте), атасының тәэсире шәфкате өчен озын-озын егләдым.

Ул заманнан игътибарән фикеремдә тәмамән урнашкан иде: милләттәшләрем арасында ике чын әдип җитешә, берсе – хәссас (сизгер), атәшле (ялкынлы) милләтпәрвәр, идеалист вә романтик Гаяз, икенчесе – гасабый тешләүчән, милләтне чеметеп сөя торган рационалист вә реалист Фатих (Фатих Кәрими)».

Йосыф Акчура мәкаләсеннән алынган өзектән күренгәнчә, Гаяз Исхакыйның беренче әсәрләре үк укучылар арасында яхшы абруй казанып өлгергән. Һәм дә бирегә әйтергә кирәк, Г.Исхакыйның башка әсәрләре дә әдәбият сөючеләр һәм татар зыялылары тарафыннан бик җылы каршыланган. Мәсәлән, 1907 елда Г.Исхакыйның «Мөгаллим» драмасы дөнья күргәч, К.Бәкер, Г.Баттал, Г.Камал, Ф.Әмирхан төрле газеталарда шактый җентекле анализ ясаган мәкаләләр белән чыгалар. Рецензентлар нигездә «Мөгаллим» драмасын «гүзәл әсәр» (Г.Камал), «татар тормышын тәмам белеп язылган» (К.Бәкер) дип бәялиләр һәм, халыкка, милләткә хезмәт итү кебек авыр эшкә алынган шәхес һич кенә дә Салих кебек үз идеалына хыянәт итмәскә тиеш дигән фикер үткәрәләр. Драма турында фикер йөртүчеләрнең һәммәсе дә диярлек бу сәхнә әсәренең гыйбрәтле һәм милләткә файдалы булуын таныйлар, укучыларны да шул фикергә иярергә чакыралар.

Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» драмасы, «Сөннәтче бабай» повесте, «Шәкерт абый» хикәясе, «Солдат», «Тормышмы бу?», «Остазбикә» повестьлары хакында Г.Газиз, «Дамелла» псевдонимы астында Ф.Әмирхан, Г.Ишеряков вакытлы матбугатта саллы гына рецензияләр бастыралар. Әлеге мәкаләләрнең авторлары, әдип иҗатының үсүгә, өлгерүгә таба йөз тотуын билгеләп үтү белән бергә, анда милли яңарыш мотивлары көчәюен, аның эстетик идеалының милләт мәнфәгатьләрен аңлау һәм аңа хезмәт итәргә теләү югарылыгына күтәрелүен дә сизми калмыйлар. Шул хасиятенә күрә татар укучысы да әдипнең әсәрләрен якын итә. Моңа, әлбәттә, Г.Исхакый иҗаты хакында әнә шундый уңай фикер әйткән рецензентларның мәкаләләре дә беркадәр дәрәҗәдә булыша. Һәрхәлдә әдипнең иҗаты өлгерү, җитлегү чорына аяк баса.

Г.Исхакыйның һәр әсәре дә гел уңай бәягә генә лаек булмаган, әлбәттә. Кайчак аның аерым бер әсәре тирәсендә кызу гына дискуссияләр дә кабынып киткән. Мәсәлән, 1913 елда Санкт-Петербургта язылып. 1914 елда шул ук шәһәрдә дөнья күргән «Мөгаллимә» драмасы шундый катлаулы язмышка очрый. Ул хәтта күпмедер вакыт татар милли вакытлы матбугаты битләрендә барган кайнар полемика объектына да әйләнә.

Моның сәбәбе, әлбәттә, «Мөгаллимә» драмасының Г.Исхакый иҗат иткән башка әсәрләрдән үзенең пафосы белән нык аерылып торуында. Билгеле булганча, бу сәхнә әсәрен иҗат иткәнчегә кадәр, Исхакый татар дөньясындагы кимчелекләрне, кадимчелекне, милләтне инкыйразга таба сөйри торган яман сыйфатларны фаш итү, аларны каты тәнкыйтьләү белән актив шөгыльләнә. Ә бу әсәрендә исә ул кадими тормышның нәкъ капма-каршысы булган икенче бер яшәү рәвешен – алга киткән җәмгыять моделен тасвирлый. Халык мәнфәгатьләре өчен көрәшүче мөгаллимә Фатыйма белән мөгаллим Габдулла алдында берниндәи киртәләр һәм каршылыклар юк. Әлеге яшь шәхесләр белән җәмгыять арасында идеаль мөнәсәбәтләр хөкем сөрә, тулы гармония урнашкан. Фатыйма белән Габдуллага үзләренең һөнәри һәм милли бурычларын үтәү өчен хәтта аларның әйләнә-тирәсендәгеләр дә булышырга әзер булып торалар. Сәяси, иҗтимагый, милли конфликт бөтенләй юкка чыккан һәм ниндидер бер идиллик халәт, җәннәткә тартым яшәеш барлыкка килгән. Халыкка хезмәт иткән, аны мәгърифәтле итү өчен игелекле гамәлләр кылган Фатыйма белән Габдулланың үзара илаһи мәхәббәте дә якты романтик буяулар белән тасвирлана һәм психологик нюанслар, лирик мотивлар, фәлсәфи детальләр белән тыгыз үрелеп барыла. «Мөгаллимә» драмасының менә шушы үзенчәлеге әдәби җәмәгатьчелектә фикер төрлелеге китереп чыгара. Зыялыларның бер өлеше, әйтик, Г.Гыйсмәти, Ш.Әхмәдиев, Г.Кәрам, Ә.Мөхетдиния, Җ.Вәлиди «Мөгаллимә» драмасының татар әдәбияты өчен яңалык булуын әйтәләр һәм аны өр-яңа образлар белән баетуын таныйлар. Бу фикер белән бары тик Г.Ибраһимов кына килешми һәм ул, «Мөгаллимә»нең сыйнфый асылы юк, әсәр тормыш дәреслеген бозган һәм иҗтимагый яктан әһәмиятсез, дип белдерә. Ләкин Г.Ибраһимовның шәхси фикере «Мөгаллимә»гә зур зыян китерә алмый. Киресенчә, җәмәгатьчелектә әлеге драмага булган игътибарны көчәйтеп кенә җибәрә һәм, үзе дә сизмәстән, Г.Ибраһимов әсәрнең абруен гына күтәрергә булыша.

1917 елгы октябрь борылышыннан соң илдән китәргә мәҗбүр булгач, тоталитар хакимиятнең карышусыз инструментына әйләндерелгән татар матбугатында Г.Исхакый әсәрләре туксанынчы елларга кадәр басылмый. Әмма аның иҗаты һәм сәяси эшчәнлеге 1987 елга кадәр татар матбугатында гел негатив яктан гына телгә алына һәм һәрвакыт мәсхәрәләү, көлү, түбәнсетү, мыскыллау объектына әйләндерелә. Илдә чакта иҗат ителгән бай әдәби мирасы исә татар әдәбиятыннан бөтенләй читләштерелә. Әйтергә кирәк, Исхакыйны каралту, аны пычратырга тырышу эше ул чордагы большевиклар фиркасе җитәкчелеге астында алып барылган, һәм аның бу социаль заказын үтәүгә татар зыялылары да тартылган. Аерым алганда, күренекле татар большевигы М.Солтангалиев «Милләтләр тормышы» дип исемләнгән газетаның 1921 ел, 5 ноябрь санында дөнья күргән «Татарлар һәм Октябрь революциясе» дигән мәкаләсендә Г.Исхакыйны, кадет Садри Максуди белән берләшеп, татар зыялыларына басым ясау һәм Кызыл Армиягә каршы көрәшү өчен мөселман полклары оештыруда һәм пролетариат диктатурасына каршы көрәшүдә кискен гаепләп чыга. Әле берничә ел элек кенә Г.Исхакый белән бергә «Идел-Урал штаты» төзү өчен көрәшеп йөргән С.Атнагулов та кичәге иптәшләрен, шул җөмләдән Г.Исхакыйны да «фаш» иткән хезмәт бастыра.

Г.Ибраһимовның «Икенче съезддагы тәэссоратым» (1917), «Бер-ике сүз» (1918), «Мәркәздә һәм урыннарда мөселман комиссариатлары» (1918), «Иҗтимагый революция вә татар зыялылары» (1919), «Дошманнар арасында дүрт ай» (1919), «Еллык хисап урынында» (1919), «Моңарчы төзелә алмавының сәбәбе нәрсәдә?» (1920), «Яңа савытта иске эчемлекләр» (1921), «Кавказ курортлары» (1921), «Мең



● Милләт юлбашчысы, даһи Г.Исхакый.

ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕ



● **Милләт юлбашчысы Гаяз Исхакый. Үзәктә – тугра: «Мөхәммәдгыйас Исхакый». Тугра өстендә чирек айда: «Милләтем». Туграның уң ягында: «Тартышканда гына табарсың үз хакыңны». Туграның сул ягында: «Татар булып калу шарты – милли телдә мәгариф». Тугра астында: «Без чит милләтләр тарафыннан йотылмаслык дәрәҗәдә көчле булырга тиеш. Әгәр без шулай көчле була алсак, безнең бер милләт булып торуыбыз хәл ителгән». Нәҗип НӘККАШ эше.**

дә беренче мәртәбә» (1921), «Моны пролетариат кына эшли алачак»(1922), «Революция тарихына материаллар» (1922), «Кәфене – муенында, бер-ике көннән җеназасы күтәрелачәк диләр иде» (1923), «Кара маяклар, яки ак әдәбиятлар» (1924), «Шәһит иптәш Ходайбирдин» (1924), «1905 ел революциясе эчендә татарларның хәрәкәтләрен өйрәнү өчен материаллар җыю турында» (1925), «Татарстан җөмһүрияте нинди каршылыклар эчендә туды һәм беренче 10 елда нинди каршылыкларга очрады» (1930), «Революция тарихына материаллар җыю һәм тикшерү турында» (1931), «Бөек Октябрьнең беренче елларында» (1932) дип исемләнгән мәкаләләре Г.Исхакыйның сәяси карашларын һәм аның бай әдәби мирасын бөтенләй диярлек кабул итә алмау рухы белән сугарылган. Мәсәлән, «Бөек Октябрьнең беренче елларында» дигән мәкаләсендә Г.Ибраһимов татар милләтчеләренең һәм татар халкының бәйсезлеге өчен көрәшүче зыялыларның хезмәтләренә, шул җөмләдән Гаяз Исхакый эшчәнлегенә дә менә нинди бәя бирә: «Уфа миллионеры Госманов Гыйбадулла үзенең «Тормыш» гәзитәсендә, Закир Кадыйри кебек ярым гарәп-ярым төрек бер дәрвишне яллап, аның авызыннан пролетариат революциясен сүктерде. Арада оятсызлыкта, хулиганлыкта иң алга киткәне, шиксез, Мәскәү татар капиталистларына ялланып, татар буржуазиясенә агентлык иткән «таңчы Гаяз Исхаков аркылы чыгартылган» «Ил» гәзитәсе булды.

Советка, Октябрьгә, большевикка, революциягә каршы иң кабахәт, иң битсез, төпсез, ахмак, түбән, пычрак ялганнар менә шул сатлык таңчы «Ил» гәзитәсендә, шул Исхаковлар каләме белән чыкты. Әстерхандагы «Сарай» белән Сембердәге «Җөмһүрият» (Ибраһим Биккулов) гәзитәләре Совет сүгүдә шул таңчы «социалист» Исхаковларның «Ил»дәге кара гайбәтләренә ияреп маташтылар. Менә бу кара гәзитәләр – 1918 елның җәй уртасына, чех-словакия фетнәсе чыгар замангача дәвам итеп, революция өстенә туктаусыз өрделәр. Халык массасын саташтырырга азапландылар».

Әнә шулай, Г.Ибраһимов кебек, Г.Исхакыйның әдәби һәм сәяси мирасын большевистик идеология күзлегеннән чыгып бәяләү ул чор өчен табигый күренеш була. Хәтта Гаяз Исхакыйны мыскыллау, түбәнсетү тоталитар идеология тарафыннан хуплана, мактала, совет режимына лояль булуның уңай бер күрсәткече итеп тә санала. Бу авырудан драматург Фәтхи Бурнаш та котыла алмый. 1929 елда басылып чыккан «Революция һәм татар әдәбияты» дигән хезмәтендә ул үтеп барышлый гына Г.Исхакыйга тибеп китә: «Гаяз Исхакый һич тартынмастан турыдан-туры кара контрреволюция юлы белән китте, аклар һәм чехлар белән йөреп чит мәмләкәтләргә чапты, Төркиядә советларга каршы фикер тарату белән булышып, аннан да сөрелде; шулай итеп, татар җәмәгатьчелеге белән булган хисабын бөтенләй өзде».

Ул чорда Гаяз Исхакый идеяләреннән татар әдәбиятын гына түгел, бәлки аның сәяси карашларыннан тарих фәнен дә тазарту эше активлаша. Тарихчы Х.Хәсәновның «Тарих фронтында буржуа милләтчелегенә каршы» дип исемләнгән китабы нигездә татар милли азатлык хәрәкәтен каралтып, аның ролен бик кечерәйтеп һәм әһәмиятен түбәнсетеп күрсәтү максатларына хезмәт итә. Бу хезмәт ул чорның социаль заказы рәвешендә язылу сәбәпле, фәннең асыл принцибы булган объективлыктан, гаделлектән һәм төгәл фактлар ярдәмендә дөрес нәтиҗәләр чыгарудан бик ерак тора. Мәгълүм идеологиягә хезмәт итүен дә китапның исеме үзе үк әйтеп бирә.

Шәхес культы котырган утызынчы елларның икенче яртысында Г.Исхакыйның исемен дөньяның барлык илләре разведкаларына бәйләп төрләндерү һәм аңа әллә нинди ярлыклар тагу ниндидер бер модага әйләнә. Хәтта шундый кәмит хәлгә дә килеп җиткәннәр ки, әйтик, заводта эшләүче токарьның профессиональ әзерлексезлеге нәтиҗәсендә станок ватылып сафтан чыкса, аның сәбәбен дә Г.Исхакыйдан һәм татар милләтчеләреннән күрү очраклары булгалаган. Ә кайбер каләмдәшләре исә аны форсат чыккан саен «фаш итә» торганнар. Мәсәлән, М.Җәлил «Педагогика училищелары өчен төзелгән татар әдәбиятын укыту программасы проекты турында» дигән 1937 елда язылган эчке рецензиясендә, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Н.Думави, М.Укмаси, С.Рәмиев кебек әдипләрнең әсәрләрен программага кертүне яклап, аларның Г.Исхакый кебек әдипләрдән нык аерылып торуын күрсәтә һәм болай дип белдерә:

«Бу урында югарыда әйтелгән вульгар социализм элементлары үзләрен сиздерәләр. Мәсәлән, бу чор әдәбиятында зур урын тоткан Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд кебек язучылар беренче вариантта бөтенләй төшерелеп калдырылганнар. Аннан соң кара белән генә, тырнаклар эчендә генә «укытучы Әмирхан, Дәрдемәнд әсәрләреннән үрнәк алып кына күрсәтә» дип өстәлгән. Ягъни аларның контрреволюциягә баручы, реаль тормышны бозып күрсәтүче либераль буржуа язучылары булуларына мисал рәвешендә генә искә алырга тәкъдим ителә. Ә иҗатларын тикшерү бурыч ителми.

Бу дөрес түгел! Идеологик карашлары, сыйнфый эчтәлекләре белән бу язучылар демократик язучылардан нык аерылдылар. Ләкин алар – шул ук вакытта зур мастерлар һәм эре художниклар. Эре художник буларак, алар татар әдәбиятының үсешендә зур роль уйнадылар. Алар шулай ук контрреволюциягә – фашизмга киткән Г.Исхакый кебек язучылардан да аерылалар».

1937 елларда Татарстан Язучылар союзы һәм «Совет әдәбияты» журналының җитәкчеләреннән берсе булган Т.Имаметдинов та Гаяз Исхакыйны мәсхәрәләүдә башкалардан калышмый. Һәр уңайлы очрак килеп чыккан саен, ул аның иҗатына гел кизәнеп тора. Мәсәлән, аның 1938 елда дөнья күргән «1937–1938 елгы сезонда Татар дәүләт академия театры» дигән мәкаләсе үзенең тупаслыгы белән аерылып тора. Фикергә дәлил рәвешендә әлеге мәкаләдән бер өзек китерәбез. Анда авторның әхлакый йөзе һәм вөҗданы көзгедәге кебек ачык чагыла. «Татар буржуа милләтчеләре фашистик бандит Г.Исхакыйның әсәрләрен һәм «Бүз егет», «Йосыф-Зөләйха», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», «Таһир-Зөһрә» һ.б. шуның шикелле Көнчыгышның дини әкиятләреннән төзелгән әсәрләрне башта һичбер төрле тартынусыз куйсалар, соңыннан үзләренең әсәрләрен бераз кызылга буяп, төбендә турыдан-туры советка каршы әсәрләр куя башладылар».

Шәхес культы чоры узып, икенче бөтендөнья сугышы беткәч һәм Сталин дәвере тарих битләренә күчкәч тә Г.Исхакый белән рәсми идеология арасында көрәш туктамый. Рәсми хакимият идеологиясенең социаль заказы нигезендә әдипнең милли карашлары һәм татар милләтен берләштерүне үзмаксат итеп куйган «бердәм агым» теориясе әледән-әле марксистик методология нигезендә тәнкыйтьләнеп торыла. Торгынлык дәверендә аеруча нык көчәя башлаган бу «сәяси һөҗүм»нең максаты, бердән, Г.Исхакыйны әдип һәм фикер иясе буларак тарихтан сызып ташлау булса, икенчедән, милли үзаңы үсә, милли фикере уяна башлаган халыкның зиһенен милли идеологиядән саклау да була. Шул уңайдан бербер артлы теоретик характердагы хезмәтләр, монографияләр чыга башлый.

Г.Исхакый иҗатының халыкка кайту процессы, тоталитар хакимият дилбегәсе бушагач та, шактый авыр барды. Элеккеге СССРда яшәүче йөзләрчә милләтләрнең әдәбиятлары кайчандыр коммунистик идеология тарафыннан кире кагылган үзенчәлекле әдипләрнең бай мираслары белән тулыланган һәм бу процесс көчәйгән бер чорда, бездә бу хәрәкәт баштагы мәлдә бер урында «йөгереп» алды. Моның сәбәбе, әлбәттә, 1987–1989 елларда көчәеп киткән сәяси вакыйгаларга һәм милли яңарыш хәрәкәтенә барып тоташа. Идарәче фирка булган КПССның җәмгыятьтәге абруе бик нык төшә барган бер вакытта, формаль булмаган иҗтимагый берләшмәләрнең, шул җөмләдән татар халкының милли азатлык хәрәкәтенең дә роле шактый көчәеп китә. Зыялылар, милләтпәрвәрләр, фән һәм сәнгать әһелләре, язучылар, журналистлар, эшчеләр, студентлар, Татар иҗтимагый үзәге тирәсенә тупланып, Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм хокукый статусын союздаш республика дәрәҗәсенә күтәрү өчен актив көрәш башлап җибәрәләр. Элеккеге СССРдагы «биш сортлы» дәүләт төзелеше иерархиясендә өченче сортлы дәүләт – автономияле республикадан икенче дәрәҗәдәге дәүләткә – союздаш республикага әверелү Татарстанның икътисади һәм мәдәни үсеше өчен киң мөмкинлекләр ачар иде. Аннары союздаш республика статусы ул, формаль төстә булса да, мөстәкыйль дәүләтнең барлык атрибутларын да бирә. Ягъни союздаш республика булган очракта Татарстан Россия аша түгел, бәлки турыдан-туры Россия белән тигез хокукта СССР дәүләтен төзүдә катнаша ала. Ә ул чакта «биш сортлы» республикалардан (СССР – союздаш республика – автономияле республика – автономияле өлкә – автономияле округ) торган СССРда икътисади, фәнни, мәдәни потенциалы буенча башка союздаш республикалардан берничә мәртәбә куәтлерәк булган Татарстанны «автономияле республика» читлегенә ябып, аның үсешен шактый чикләргә теләделәр. 1917–1918 елларда Г.Исхакый, С.Максуди, Й.Акчуралар төзергә теләгән «Идел-Урал штаты»н әнә шулай ваклап, Татарстанны бернинди сәяси һәм хокукый статусы да булмаган «автономияле республика» бавы белән «тышаулап» куйдылар. Татарстанның сәяси һәм хокукый статусын союздаш республика дәрәҗәсенә кадәр күтәрү өчен татар зыялылары башлап җибәргән хәрәкәт, нигездә, Г.Исхакыйларның 1918 елда өзелеп калган «Идел-Урал штаты»н төзү өчен көрәшен яңартып, аны яңа формада дәвам итү иде. Бу хәлдән, билгеле, Мәскәү идарәчеләре һәм аларның Казандагы «күз-колаклары» куркып калдылар һәм, туып килүче милли хәрәкәтне һич югы йөгәнләү, кулда тоту өчен, аның идеологиясен җимерергә маташтылар.

(Дәвамы киләсе санда).

Миңнәхмәт СӘХАПОВ.
«Бердәм агым» китабыннан.
ТКН, 2006.



Чыңгыз АЙТМАТОВ

ДӨЯ КҮЗЕ

Чиләгемне чишмәгә бер генә тапкыр батырып алырга өлгердем – бөтен дөньяга сөрән салып:

– Ә-әй! Академик, җаныңны ала-ам! – дип кычкырган аваз ишетелде.

Тынымны кыстым. Нәрсә булды икән дип тыңлап тора башладым. Минем чын исемем Камил югыйсә, ә менә монда килгәч, миңа «академик» дигән исем тактылар. Тракторның суы беткәндер дип уйлаган идем, шулай булып чыкты да: басуның теге башындагы трактор, йөрәккә шом салып, тынып калган иде. Минем җанымны алам дип кычкырган кеше – Әбәкер ул. Тагын акырып-җикеренер инде, әллә нинди сүзләр әйтеп сүгәргә керешер, йодрыгы белән кизәнергә дә күп сорамас. Тракторлар икәү, ә мин – берүзем. Сыңар ат җиккән арба белән мин аларга суын да, ягулыгын да, маен да – бөтенесен дә китереп-җитештереп торырга тиешмен. Бөтен әйләнә-тирәдәге бердәнбер чишмәдән тракторлар көн саен ерагая баралар. Цистерна белән ягулык саклана торган безнең бердәнбер кыр станыннан да ераккарак китә баралар. Аны күчермәкче булып караган идек тә, күчерергә ярамый икән – ул да судан аерыла алмый, Әбәкер исә моны белергә дә теләми: «Тракторны эштән туктатсаң, җаныңны алам, бел аны! – ди. – Ниндидер җебегән бер студент кисәге аркасында вакыт әрәм итәр өчен, җык чигеп җир сөрергә килмәгән мондый!» – ди.

Ә мин бернинди студент та түгел әле. Институтка керергә уйлаганым да булмады. Мәктәпне тәмамлагач та, монда, Анархайга килдем. Безне бирегә эшкә җибәргән чакта җыелышта әйттеләр: янәсе, без, ягъни мин дә, «чирәм җирне буйсындыручы каһарманнар, яңа җирләр яулап алучы беренче батырлар». Әнә кем идем мин башта. Ә хәзер кем? Әйтергә дә оят: «академик». Андый кушаматны шул Әбәкер кушты миңа. Үзем дә гаепле инде: эчемдәге – тышымда, сабый бала шикелле, ни хыяллансам, шуны кычкырып әйтеп бирәм, кешеләр үземнән көләләр аннары. Монда минем үземнән бигрәк безнең тарих укытучысы Аллаяров гаепле икәнен белмиләр. Туган якны өйрәнүче ул! Аның сөйләгәннәрен авыз ачып тыңлавым аркасында әнә шундый хәлгә төштем дә инде мин...

Мичкәне тутырып та җиткермичә, чокырдан менеп, юлга чыктым. Дөресен генә әйткәндә, монда моңарчы юл дигән нәрсәнең әсәре дә булмаган. Арбам белән мин салдым аны.

Трактор зур кара басуның теге башында туктап калган. Ә трактор өстендә – кабинада – Әбәкер утырып тора. Ул, йодрыгын селкә-селкә, һаман әллә нинди сүзләр әйтеп сүгенә, мине тирги, мине хурлый.

Мин атка сугып алдым. Мичкәдәге су чайпалып аркама түгелә башлады, шуңа да карамастан атны куып чаптырырга керештем.

Монда мин үзем килдем, үз теләгем белән. Мине берәү дә килергә мәҗбүр итмәде. Башкалар Казакъстанга, газеталарда языла торган чын чирәм җирләргә киттеләр. Ә Анархайга мин берүзем килдем. Биредә әле беренче яз гына эшкә керештеләр, анда да нибары ике генә трактор эшли. Быелтыр агроном Сорокин – монда бөтенебезгә баш кеше ул – кечерәк бер басуда богара арпасы үстереп караган. Уңышы ярыйсы ук яхшы булган, диләр. Киләчәктә дә шундый уңыш алып булса, Анархай даласында терлекләргә азык мәсьәләсен, бәлки, хәл итеп булыр, диләр.

Хәзергә исә алдыңа-артыңа каранып кына эш итәргә туры килә. Җәй көне бик эссе, коры була шул Анархай даласы: хәтта чәнечкеле таштикән үләне дә тамырына хәтле кибеп корый. Көз көне бирегә кыш чыгарга мал-туарларын куып китерүче колхозлар да хәзергә ашлык чәчүдән тыелып торалар; карап карыйк, башкаларның ничек килеп чыгар, янәсе... Шуңа күрә без монда бармак белән санарлык кына: ике тракторчы, ике прицепщик, пешекче хатын, мин – су ташучы һәм агроном Сорокин. Чирәм җир буйсындыручыларның бөтен армиясе менә шул. Безнең монда эшләгәнне дөньяда берәр кеше белә микән, хәер, без үзебез дә дөньядан хәбәрсез яшибез, әллә нидә бер Сорокин гына берәр яңалык алып килә. Ул, атка атланып, күрше тугайдагы чабаннар янына барып кайта, шунда рация буенча начальство белән талаша, отчёт өчен мәгълүматлар тапшыра.

Алай икә-ән, ә мин тагын, чирәм җир булгач, эшләр бик зурдан купкандыр дип уйлаган идем! Хәер, һаман да шул тарихчыбыз Аллаяров гаепле. Без мәктәп малайларын кызыктырып, Анархай турында ниләр генә сөйләми иде ул: «Курдай калкулыгыннан җәелеп китеп, Балхаш күленең куе камышлыкларына чаклы сузылган, гасырлар буена кеше кулы тимәгән, аксыл-зәңгәрсу әремле гүзәл дала! Риваятьләрдә әйтелүенчә, борын заманнарда Анархай калкулыклары арасында адашып көтү-көтү атлар югала торган булган һәм шуннан соң анда шактый озак вакытлар буена кыргыйлашкан ат көтүләре йөргән. Анархай ул – узган заманнарның телсез шаһиты, бик зур сугышлар мәйданы, күчмә кабиләләрнең туган бишеге. Безнең көннәрдә исә Анархай даласы иң бай күчмә терлекчелек төбәгенә әйләнәчәк...» һәм башкалар, һәм башкалар...

Ул чагында Анархайны картадан каравы гына ансат булган икән, ул анда уч төбе хәтле генә. Ә хәзер? Хәзер иртә таңнан торып ат җигәм дә, шушы каһәр төшкән су мичкәсе белән дырык-дырык тик йөри бирәм. Кич җиткәч, атны көч-хәл белән туарып, алдына прессланган печән салам (ул печәнне бирегә машина белән китерделәр). Шуннан соң, бернинди аппетитсыз, безнең Әлдәй биргән ашны ашыйм да, тирмәгә кереп, үлгән кебек йокыга талам.

Анархайның әремле гүзәл дала булуы чыннан да хак. Биредә аның матурлыгына сәгатьләр буе сокланып карап йөрерсең, тик вакыт кына юк.

Барысына да түзәр идем, тик бернәрсәгә аптырыйм: Әбәкергә минем нәрсәм ошамый, ни өчен мине шулхәтле дошман күрә ул? Әгәр монда үземне ниләр көткәнен белгән булсам... Мин теләсә нинди табигать авырлыкларына да түзәргә әзер идем. Монда бит кунакка дип килмәдем. Ә менә бирегә килгәч бергә эшлисе һәм бергә яшисе кешеләр турында ни өчендер бөтенләй искә дә алмаганмын. Бөтен җирдә дә кешеләр бертөсле дип уйлаганмын...

Бирегә мин машина белән ике тәүлек килдем. Минем белән бергә машина әрҗәсендә су ташый торган шушы арба да килде. Ул чагында мин бу арба аркасында газап чигәрмен дип уема да китермәгән идем.

Мин бит монда прицепщик булып эшләргә дип килдем. Язын трактор янында эшләп йөрермен дә, өйрәнеп, үзем дә тракторчы булып китәрмен дип уйлаган идем. Районда шулай дип әйткәннәр иде. Әнә шул хыял белән мин Анархайга киттем. Монда килгәч, шуны белдем: прицепщиклар бар икән, ә мин су ташучы итеп җибәрелгәнмен, янәсе. Миңа, билгеле, бу эштән шундук баш тартырга, кире кайтып китәргә кирәк булган. Минем бит гомеремдә дә камыт, тәртәләр белән эш иткәнем юк. Гомумән, беркайда да эшләгәнем юк әле, өмә көннәрне шикәр заводына барып, әнигә булышкалаганым гына бар. Әти фронтта үлеп калган. Мин аны белмим дә. Шулай итеп, үзем эшләп яшәргә уйлаган идем... Барыбер миңа шундук кире кайтып китәргә кирәк булган. Уңайсызландым шул. Киткән чакта җыелышта күпме шау-шу булды! Әниенең җибәрәсе килмәде, ул мине врач итәргә хыяллана иде. Ләкин үз сүземдә тордым, әнине ризалаттым – ярдәм итеп торырмын, дидем. Китәргә үзем ашыкдым. Шундук әйләнеп кайтсам, ни бит белән кешеләр күзенә күренермен, янәсе. Шулай итеп, су ташучы булырга туры килде. Ләкин минем шушы хәлгә төшүемнең сәбәбе ул түгел.

Юлда, машина кузовына басып барганда, исем китеп, сокланып карап бардым: менә нинди икән ул дастаннарда җырланган борынгы Анархай! Еракта чак-чак кына зәңгәрсу томан белән өртелгән дала өсте ямь-яшел булып яшәреп килә, аның калкурак сыртлары арасына китеп югалган беленер-беленмәс юл буйлап безнең машина җил кебек очып бара. Җиргә әле кар сулары сеңеп бетмәгән. Шулай да дымлы һавадан аксыл-зәңгәрсу Анархай әременең әчкелтем исе сизелә башлаган инде – былтыргы корып сынган сабаклары төбендәге тамырыннан яшь әрем шытып чыккан. Каршыга искән җил белән иркен дала чыңы һәм язгы бер сафлык ургылып килә сыман. Без гүяки офыкка җитәргә ашыгабыз, ә офык ерактагы калкулыкларның язгы кар сулары белән юылган тигез итәкләре буйлап һаман саен бездән китә бара, сыртлыкларны узган саен, Анархай даласының яңадан-яңа киңлекләре ачыла.

Шул чагында гүяки мин үткән заманнарның авазларын ишетәм сыман тоелды. Меңәрләгән ат тоякларыннан җир гөрселдәп, тетрәп тора, имеш. Кулларына сөңге, әләм тоткан күчмә кабиләләрнең атлы гаскәре, һай-һулап, акырып-үкереп, диңгез дулкыны шикелле җәелеп китә. Күз алдымнан коточкыч дәһшәтле сугыш-кырылыш тамашалары узып китә. Тимер кораллар чак-чок итә, кешеләр кычкыра, атлар тибешәләр, тешләшәләр. Кайнап торган шушы сугыш мәхшәре эчендә кайдадыр мин үзем дә йөрим, имеш... Ләкин сугышлар тына, һәм язгы Анархай өстендә ак тирмәләр калкып чыга, җәйләүләр өстеннән кизәк төтене күтәрелә, тирә-юньдә ат, сарык көтүләре утлап йөри, кыңгыраулар чыңлатып, кайлардандыр килгән, кайларгадыр юл тотучы дөя кәрваннары узып бара...

Сузып кычкырткан паровоз тавышы мине хыялларымнан айнытып җибәрде. Вагоннар өстенә куе төтен бөркә-бөркә паровоз китеп бара, гүяки койрыгын җилгә сузып, ялларын җилфердәтеп аргамак ат чаба иде. Ерактан әнә шулай тоелды ул миңа. Поезд исә, һаман кечерәя-кечерәя, кара бер сызык шикелле генә булып калды да аннары бөтенләй күздән югалды.

Без ерак дала эчендә яткан бер разъезд янында тимер юлны аркылы чыктык та юлыбызны дәвам иттердек...

Монда килгәннең беренче көнендә үк мин үземне үзем фаш иттем. Юлда килгәндәге хыялларымнан айнып җитмәгән булганмын, күрәсең, кыр станыннан бер читтәрәк, калкулыкта, борынгы бер таш пот тора иде. Тупас кына итеп чокылган соры гранит ташы, җир эченә шактый иңеп, мәгънәсез, җансыз карашын еракка төбәп, сакка баскан кебек, гасырлар буе шушында торган. Аның җил-яңгырдан ашалып чокырайган уң күзе агып чыккан сыман, буш кебек; авыр кабагын йома төшеп, күзен усал итеп кыскан шикелле. Шактый озак карап тордым мин таш сынны, аннары тирмә янына кайттым да Сорокиннан:

– Ничек уйлыйсыз сез, иптәш агроном, бу сынны монда кемнәр куйган булуы ихтимал? – дип сорадым.

Сорокин каядыр китәргә җыена иде. Ияренә атлана-атлана:

– Калмыклар булса кирәк, – дип җавап бирде дә китеп барды.

Шуның белән тынычланып калган булсамчы! Юк шул! Шайтан котыртты диярсең – әле юньләп танышып та өлгермәгән тракторчылар белән прицепщиклар алдында сөйләнергә керештем:

– Юк, бигүк дөрес түгел. Калмыклар монда унҗиденче йөздә генә булганнар. Ә бу кабер ташы уникенче гасырныкы. Бу таш сынны монголлар көнбатышка яу белән барганда куйган булырга тиеш. Без кыргызлар да бирегә, Тянь-Шань төбәгенә, Енисей буеннан алар бергә килгәнбез. Безгә хәтле монда кыпчак кабиләләре яшәгән, аларга хәтле кызыл чәчле, зәңгәр күзле кешеләр.

Мин тарих эченә тагын да тирәнгәрәк керәсе идем дә, шулвакыт трактор янында басып торган комбинезонлы бер кеше сүземнән бүлдерде. Әбәкер иде ул.

– Әй, сабый! – дип, маңгай астыннан гына миңа ачулы караш ташлады. – Бик укымышлы егет икәнсең. Бар әле, тирмәдән тавотлы шприцны алып кил әле.

Тавотлы шприц урынына мин ялгыш солидоллыны китергәнмен.

Әбәкер миңа кызыл кан тамырлары беленеп торган усал күзе белән кырын гына карап, мыскыллы бер тавыш белән:

– Их син, Академик! Без наданнарга лекция укыган буласың тагын, ә үзең атны дөядән аера алмыйсың, – диде.

«Академик» дигән кушамат әнә шуннан китте инде.

(Дәвамы киләсе санда.)

«Сугышчан дан клубы» ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов хәрби архивлардан Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителеп тә әлеге югары дәрәҗәне алмый калган 219 якташыбызның исемнәрен һәм батырлыкларын ачыклады. Герой исеменнән мәхрүм ителгәннәрнең 67 се татар. Алар арасыннан 16 сугышчы үзләре вафат булганнан соң мондый дәрәҗәгә тәкъдим ителгән. Әмма аларның каһарманлыгы да, исемнәре дә тарихларда урын ала алмаган.

Герой исемен алмаган 8 татар

Әхмәтҗанов Госман Сабир улы 1924 елда Казан шәһәрендә туган, 1942 елда Сталин хәрби комиссариаты аша фронтка озатылган. 5 нче аерым гвардия мотоукчылар бригадасында пулемет взводы командиры һәм кече лейтенант дәрәҗәләренә ирешә, ике тапкыр яралана.

1944 елның августында Молдавия җирендә атаклы Измаил каласын штурмлаган чакта ул үзенең пулемет взводы белән пристаньга бәреп керә, 92 гитлерчыны әсирлеккә ала, ике пулеметы булган дошман катерын да үз кулына эләктерә. Шул катер белән Дунай елгасын кичеп, каршы ярда плацдарм яулый. Ул бәрелеш вакытында да 26 немец солдатын сафтан чыгара, 72 гитлерчыны әсирлеккә ала. Шушы каһарманлыгы өчен 1944 елның 26 августында Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин татар егетен Кызыл Байрак ордены белән генә бүләклиләр.






НАГРАДНОЙ ЛИСТ



Әхмәтҗанов Газиз Әхмәтҗан улы 1909 елда туган, 1941 елның май аенда ук Лаеш комиссариаты аша Кызыл армияга чакырылган. 1943 елның август аеннан соң ул Брянск, 1 нче һәм 2 нче Балтыйк буе, Ленинград фронтларында яу йөри. Ике тапкыр яралана. 3 нче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнергә өлгерә. Баш командование резервындагы дивизиянең 15 нче артеллерия корпусында, 18 нче миномет бригадасының 227 нче полкында разведка отделениесе командиры, өлкән сержант булып хезмәт итә.

1944 елның 10 июнендә Карелиянең Александровка авылын азат иткән чакта Газиз дошманнарның яхшылап яшерелгән миномет батареясын, танкка каршы тубын һәм өч станоклы пулемет нокталарын шәйләп ала һәм рация аша аларның координаталарын совет артеллериячеләренә тапшыра. Әлеге дошман нокталары тиз арада юкка чыгарыла. Пехота белән бергә һөҗүм итү башлангач, Газиз гранаталар ыргытып, дошман ДОТындагы тагын бер пулеметны сафтан чыгара. Кутерсельск атлы авыл янында финнарның бер дистәдән артык сугышчысын һәм танкка каршы атучы 2 тубын юк итә.

1944 елның 15 июнендә өлкән сержант Г.Әхмәтҗанов яңа яуда тагын 6 фин сугышчысын юк итә. Карелияне азат итү барышындагы батырлыклары өчен ул 1944 елның 24 июнендә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, тик әлеге татар егете дә 2 нче дәрәҗә Дан ордены белән генә мәмнүн булып кала.

ВСЕ ГРАФЫ ЗАПОЛНЯТЬ ПОЛНОСТЬЮ

НАГРАДНОЙ ЛИСТ



Баһманов Рәхим Баһман улы 1907 елда туа, 1941 елның 18 июлендә Беренче Май районы комиссариаты аша сугышка озатыла. 1941 елның 1 декабрендә фронтка эләгә. Кызыл байраклы 354 нче укчы дивизиянең 476 нчы аерым сапер батальонында сапер булып хезмәт итә. Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, ике мәртәбә «Батырлык өчен» медальләре белән бүләкләнә. 1944 елның 4 сентябрендә ул Төньяк Буг елгасының Урта Байки авылы янында винтовкасы белән дошманның 12 солдатын юк итә, яуда яраланган рота командирын сугыш кырыннан алып чыга. Икенче көнне Карневск авылы янында Нарев елгасын кичкәндә дошман уты астында паром һәм причал төзүне оештыра, шулар ярдәмендә артеллерия һәм снарядларны икенче як ярга чыгаруга ирешә.

16 сентябрьдә Рәхим Баһмановны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп рапортлар юллыйлар. Ә татар өчен каһарманлык нибары Кызыл Байрак ордены булып кына әйләнеп кайта.

(**Дәвамы киләсе санда**).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.

Мәдәни җомга
8 сентябрь
№35, 2023

● Нияз–Хәния пары Минзәлә театрында: Илдар Халиков белән Илсинә Минемуллина.

● Айвар-Динә пары Минзәлә театрында: Илназ Хисмәтуллин белән Индира Гайфуллина.

ЧИШЕНГӘН ХАТЫНЛЫ

Бүген – Камал театрында «Ситса туй» моңсу комедиясенең премьерасы. Татарстанда быелгы театр сезоны август аенда татарның иң өметле ике режиссёрының тандемы белән башланып китә. Татарның «беренче номерлы» драматургы һәм «два в одном» буларак режиссеры да, «Әкият» татар дәүләт курчак театрының сәнгать җитәкчесе Илгиз Зәйниев пьесасы буенча татарның иң өметле һәм перспективалы режиссеры Айдар Җаббаров Камал театры сәхнәсендә «Ситса туй» спектаклен чыгарды.

Пьеса тарихыннан башласак, Илгиз Зәйниев бу әсәрне, Минзәлә театры директоры Илнур Гайниев үтенече буенча, махсус Минзәлә театры өчен язган һәм үзе үк аны, барып, театрның яшь артистлары белән куйган да. Спектакль «Кече ватан театрлары» федераль гранты хисабына куелды. Шунысы да игътибарга лаек – пьеса Минзәлә театрының кайбер артистларын күздә тотып язылган.

«Ситса туй» – Минзәлә театрының касса спектакле, театр аны рәхәтләнеп башка калаларга да йөртә, халык ярата. Ул аны Казанга да алып килгән иде, дөрес, ул вакытта режиссер авырып китеп, спектакльне яңа сәхнә өчен көйли алмаган, шул сәбәпле шактый тәнкыйть сүзе дә яңгырады. Шәхсән мин «Ситса туй» комедиясен Минзәлә театры залында «Кече ватан театрлары» федераль проектының партия кураторы Людмила Рыбакова һәм спектакльнең шигырьләре авторы Резеда Гобәева белән янәшә утырып карадым. Бөтенебез бик канәгать калдык.

Шулай итеп, Минзәлә театрының уңышлы спектакленә Камал театры күз төшергән, һәм Айдар Җаббаров, театрның яшь артистларын туплап, тиз арада куеп та чыкты.

Камал театрында кассалы спектакльләр Илгиз Зәйниевнныкы була торган иде: «Мәхәббәт FM», «Бию пәрие», «Өйләнәм. tat» – аның үзе язып үзе куйган популяр комедияләре. Алар инде искереп килә. Рамил Төхфәтуллин Камал театрына әйләнеп кайткач яңартылган «Килә ява, килә ява» комедиясе дә репертуардан төште. Театрга шуларны алыштырырдай һәм халык «егылып йөри» торган ниндидер җиңел әсәр кирәк иде. Шунлыктан – «җиңел әсәр» кирәклегеннән – хәтта Рөстәм Галиуллинның дебют пьесасы да драмадан комедиягә әйләндерелде. Ул гына азмы? Менә тагын берсе – «Ситса туй»!

Сүзне рәссам эшеннән, ягъни, декорацияләрдән башлыйк. Спектакльнең рәссамы – Булат Ибраһимов. Минзәлә театрында рәссам Сергей Скоморохов иде. Анда декорация ЗАГС мөһере булса да, төзелеп бетмәгән мөнәсәбәтләргә тиңдәш – төзелеп бетмәгән йортны хәтерләтте. Йорт бар, бүлмәләр бар, диваны-өстәле тора, әмма нидер җитми кебек. Барысы да пастель тоннарда кебек хәтердә калган. Ә биредә барысы да ноктасына кадәр төзелеп беткән: җете һәм җитеш. Сергей Скоморохов белән Илгиз Зәйниев, парлар мөнәсәбәтләрен гомере буе төзи, дип санаса, Айдар Җаббаров белән Булат Ибраһимов паспортыңа мөһер сугылган икән – димәк, төзелгән, дип санаган.

Бу комедиянең Камал театрында моңарчы куелган комедияләрдән бер үзенчәлеге – кыйммәтле булуында. Әйе, Айдар Җаббаров шактый кыйммәтле спектакль куйган. Декорацияләр мәсьәләсендә әйтүем. Сәхнәдә ике бүлмәле фатир корылган. Суы агып килә һәм агып китә торган чын душ кабиналары, кухняда чын духовкалар белән. Театрда бикләнеп калсаң, сәхнә уртасында алма бәлеше пешереп, юынып, рәхәтләнеп яшәп була.

Ә инде акча ягына килгәндә, сәхнәдәге 4 яшь хатынның күлмәк арты күлмәк алыштыруы да сәхнә уртасына канализация үткәрү бәясе белән чагыштырганда чүп кенә, әлбәттә. Менә бит безнең өчен ничек тырышканнар, дип, тамашачы күкрәген киереп утыра ала. Кыскасы, сәхнәдә байлык, муллык – бүгенге татарның ураза тотса-тотмаса да ифтар табыны кебек.

«Ситса туй» – 4 парның бер ел яшәгәннән соң гаилә кризисы турындагы спектакль. Парлар 1 ел бергә яшәгәннән соң ситса туй үткәрелә, ди. Әмма 1 ел яшәгән кешедә туй кайгысы түгел икән, кайсынадыр – акча, кайсынадыр игътибар җитми. Нияз (Эмиль Талипов) Хәниягә (Алинә Мөдәрисова) бик яратып өйләнгән, әмма туйның 1 еллыгына хатынын кафега алып барырга да, чәчәк алып кайтырга да акча җиткерә алмый, дөресрәге, «өйләнгән – эш беткән» дип саный һәм соңгы акчасына кармак алып кайта. Дилүс (Раил Шәмсуаров) көне буе эштә, өйгә кайтып бераз ял итим дисә, эшсезлектән интеккән хатынга игътибар җитми. Илсур (Илнур Закиров) бик игътибарлы – хатыны Гөлнараның тиенләп җыйган акчасына икесенә дә айфон күтәреп кайткан. Карьера ясарга маташкан эшлекле ханым/түрәчек Динә белән укытучы Айварның да тормышлары

● Илсур белән Гөлнара пары Минзәлә театрында: Зөлфирә Гәрәева белән Рөстәм Зиннуров.

● Дилүс белән Рамилә пары Минзәлә театрында: Диләрә Кәримуллина белән Нәфис Гайфуллин.

● Нияз–Хәния пары Камал театрында: Алинә Мөдәррисова белән Эмиль Талипов.

● Айвар белән Динә пары Камал театрында: Ләйсән Гатауллина белән Алмаз Сабирҗанов.

«СИТСА ТУЙ»

барып чыкмый. Динә көне-төне эштә... Эштә генәме икән?

Залда утырган һәр пар бередә үз проблемаларын күрә аладыр. Ир белән хатынга спектакльдән кайтканда да, чәй эчкәндә дә, йокларга яткач та сөйләшерлек сүз күп монда.

«Ситса туй» – әйбәт пьеса. Андагы монологлар да, диалоглар да шулкадәр җор тел белән матур язылган. Артистларны тезеп утыртып кына текстны укытсаң да көлеп утырырга була.

– «Мин сине кире әниеңә илтеп бирәм – үстереп бетерсен.

– Бер котылгач кире алмас шул инде ул».

– «Мин синнән аерылгач нишләрмен икән?

– Өйләнгәнче нишләгәнсең – шуны эшләрсең.

– Өйләнгәнче мин синең арттан йөрдем».

Шундый диалоглар бередә тулып ята. Яхшы текстлы спектакльдә уйнау артистка җан рәхәтедер. Авыз тутырып рәхәтләнеп сөйлисең, син сөйләгән саен тамашачы көлә.

Артистлар дигәннән, спектакльне премьера алдыннан караган килеш, алар уены турында сүз әйтү дөрес түгел, әлбәттә. Артист рольгә уйный-уйный керә, җайлаша. Шуңа күрә миңа ошап бетмәгән кайбер рольләр турында әйтеп тору урынсыз. Ә менә кайбер персонажларга мишәр акценты, кайсыларына сакау сөйләшү, кайсына иләмсез бас тавыш кую нигә кирәк булды – тамашачы шулай хәтердә калдырсын өченме? Монысы артык булмадымы икән?

Спектакльдә мин сәнгати мәгънәсен аңламаган бер эпизод бар. Дүртенче пардагы ханым – Динәнең (Ләйсән Гатауллина) душта юынуы нигә кирәк иде? Ул юынсын өчен душ кабинасы алынган, су кергән һәм чыккан.

Әллә Камал театрында яшь прималарны чишендереп күрсәтеп «боевое крещение» уздыралармы соң? Заманында «Курчак туе» спектаклендә Нәфисә Хәйруллинаның чишенгән эпизодлары искә төште. Мәскәүгә китеп бармаса, приманың да примасы буласы Нәфисә иде бит ул! Театрның баш режиссеры куйган ике спектакльдә төп рольне уйнаган, студент килеш «Тантана» премиясен алган, тамашачыга исеме танылганчы ук Муса Җәлил премиясен алган Ләйсән Гатауллина «боевое крещение»не әйбәт узды – гәүдәсе матур, үзе чибәр. Пьеса буенча бераз өлкәнрәк булырга тиеш булса да, Айдар Җаббаров түрәчек ханым ролен яп-яшь Ләйсәнне алып ялгышмагандыр – талантлы кыз инде. Кыскасы, Айдар Җаббаровтан тамашачының ир-ат җенесле өлешенә матур бүләк.

Ләйсән темасын дәвам итеп, аның кайбер моментларда театр примасы һәм беренче ледие Люция Хәмитовага охшап китүе Фәрит Бикчәнтәев укучысы булуыннан гынамы? Әллә Айдар Җаббаровтан остазына бүләкме?

Спектакльдә 4 пардан тыш Вәсилә ханым образы бар. Ул ЗАГС хезмәткәре – парлардан гаризалар кабул итүче. Айдар Җаббаров бу персонажны үстергән – ул спектакльнең буеннан-буена яшьләрне озатып йөри. Бу рольгә театрның иң сөйкемле һәм зәвыклы актрисаларының берсе, «Алтын битлек» театр премиясе номинанты Ләйсән Рәхимова алынган. ЗАГС хезмәткәре булып яшьләрне каршы алган моментта башына калфак кадап куюы ачуны китерде китерүен... нигә Камал театры икенче спектакль рәттән калфаклы ханымнардан көлә икән ул? (Рөстәм Галиуллин пьесасы буенча куелган «Көзге кайтаваз» спектаклендә дә бер ханымны шулай чыгардылар).

Ачу китерде дигәннән, хәзер инде спектакльнең миңа ошамаган бер ягына күчәм – музыкасына. Минзәлә театры куелышы өчен Резеда Гобәева белән Эльмир Низамов тарафыннан махсус 4 җыр язылган. Аларны башта театр артистлары җырлап, хәзер алар интернетта профессионаллар башкаруында яңгырый. Аларны интернетта Эльмира Кәлимуллина, Мубай һәм Илгиз Мөхетдинов башкаруында тыңлап була. Әйе, әйе, Илгиз Мөхетдиновның «Син минем» җыры «Ситса туй» өчен махсус язылган. Тыңлап туярлык түгел, килешәсезме?

Программадагы исемлеккә караганда, бередә татар эстрадасының 13 һәм «Империя» төркеме башкаруында бер җыр кулланылган. Исемлектә Зифа Нагаева, Ринат Рәхмәтуллин, Наил Табанаков, Оскар Усманов, Тәслимә Низами, Сагыйть Гыйбашев кебек татар эстрадасының популяр исемнәре бар. Ә җырлары – заманында һәр үтүктән яңгыраган җырлар.

Картларча шыңшып алыйм әле: без яшь чакта җырлар башта спектакльдә яңгырап, соңыннан халык арасына чыга, эстрадада яңгырый иде. Хәзер киресенчә, яңгырап-тузып беткән җырлар театрның өр-яңа спектакльләрен бизи башлады. Әйе, алар спектакльдә күрсәтелгән күренешләрне ача, үстерә, бизи. Әйе, алар шулкадәр төгәл сайланган. Әмма минем театр сәхнәсеннән аларны ишетәсем килми, тыңлыйсым килми минем Камалда Гыйбашев җырын! Әмма бу да – минем проблемадыр.

Мин бередә бер үк әсәрләрнең төрле театрларда куелуын проблема итеп күтәрмим. Гәрчә төрле бюджетлы, төрле шартларда иҗат итүче театрларны чагыштыру алдына куюны ни дәрәҗәдә дөрестер – әйтә алмыйм. Бик сорасалар, Илгиз Зәйниев Камал театры өчен махсус та язып биргән булыр иде инде. Каләме кулында бит: языла тора, куела тора, карала тора...

«Ситса туй» – Айдар Җаббаровның беренче халыкчан комедиясе дип беләм. Артистларның сәхнә алдына килеп микрофонга монолог укуы яки җырлап алуы – Камал театрының «Килә ява» кебек «база комедияләренә» референс булгандыр. Дәвамчанлык. Илгиз әсәренә алынуы да шул дәвамчанлык белән аңлатыладыр, бәлки.

Спектакльгә минем шәхси мөһерем – Айдар Җаббаров әйбәт әсәр сайлап, әйбәт спектакль куйган. Тамашачы әйбәт йөриячәк – театр директоры Илфир Якупов акчаны санап кына өлгерсен!

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

Салават Камалетдинов һәм Минзәлә театры матбугат үзәгеннән Рәмис Нәҗмиев фотолары.

Интертат.

● Илсур белән Гөлнара пары Камал театрында: Айгөл Шакирова белән Илнур Закиров.

● Дилүс белән Рамилә пары Камал театрында: Гүзәл Гюльвердиева белән Раил Шәмсуаров.

АКТАНЫШ

(Дәвамы. Башы 33, 34 нче саннарда).

Богады – Йәнәй, соңрак Байсар волосте җирләрендә тернәкләнгән, «башкорт» авылы буларак, 1795 елгы ревизиягә кадәр исәпкә алынмаган. Ул архив документларында Богады түбәсе төзелү уңаеннан грамоталарда **1646 елда ук** телгә алына. Шулай ук, XVII гасырның II яртысында Йәнәй волостен яңа түбәләргә бүлгән чакта да Богады түбәсенең Иске һәм Яңа Богады, Сәфәр, Кадермәт, Солтангол һәм Җәйләү (Илеш районында) авылларыннан хасил булуы санап үтелә (Ә.Әсфәндияров. Аулы... 26 бит).

Богады 1712 елда яңа тарихи документларга кергән. Улчакта Богадыдан Дәвем Айманов белән Чүрә Азаматов Ык елгасы буен, Тодыш һәм Торалы күлләрен 3 елга арендага бирүдә катнашкан. 1730 елда шушы ук авылдан «башкорт» Солтан Айманов Йәнәй волостеннан Хөсәен Уразаевны үз вотчинасына авыл төзү өчен яшәргә керткән. 1749 елда Богадының 17 «башкорты» үз җирләрен Пьяный Бор, Сарсаз (Шаршады-?) /алар бүгенге Әгерҗе районында/ крестияннарына 25 ел буе файдалану өчен арендага биргән.

1729 елда Богадыдагы Солтан Аймановның Сарсаз авылы «башкорты» Юныс Төрбәневны богадылылар хуҗа булган сулыкларда капкын белән сусар тотып ятканда тоткарлавы теркәлгән. Шушы җинаяте өчен Юныска гомум бәясе 7 сум торган 2 ат белән «штраф» түләргә туры килгән.

1836 елда авылда бер мәчет, 1853 елдан аның каршында мәдрәсә эшли. 1848 елда авыл янында ике тегермән эшләве дә мәгълүм.

1912 елда Иске Богадының 221 хуҗалыгында 1150 кеше гомер иткән.

Яңа Богады – шул ук Бикады елгасы буена урнашкан, Йәнәй волостена буйсынган. Авыл XVII гасырның II яртысында, Йәнәй волостен яңа түбәләргә бүлгән чакта ук, Иске Богады түбәсе составына кертелгән һәм тарихи документларда телгә алынган. Икенче документ 1733 елда Каракүл конторасында төзелгән, ул чакта Яңа Богадыдан Тәвәккәл Сәфәров белән Яңа Җияштән Зәет Кадермәтов, Әит һәм Сөләйман Каенчиннар үз вотчиналарында Байлар волостеның Салагыш түбәсеннән күчеп килгән «башкортларга» яңа авыл төзергә рөхсәт бирә. 1751 елда ук Яңа Богады «башкортлары» да Ык елгасының түбән агымындагы Тудыш, Торалы күлләре буен, Чиста үзәнне Каракүл крестияннарына 25 еллык арендага тапшырып, елына 14 әр сум «табыш» ала башлый. 1816 елда Яңа авылда 43 хуҗалык һәм анда яшәүче 283 «башкорт» исәпкә алына. 1912 елда 178 йортта яшәүче «башкортлар» саны 923 кә җитә.

Түбән (Иске) Гәрәй – Гәрәй волостеның Такталачык түбәсендә, Шәбез елгасы буенда урнашкан «башкорт» авылы. Түбән Гәрәй 1795 елгы ревизиягә кадәр исәпкә алынмаган, ә бу елда 26 йортта 66 ир-ат һәм 70 хатын-кыз яшәве ачыкланган. 1912 елда 140 йортта яшәүче «асаба башкортлар» саны 796 га җиткән. 1905 елда ук игенне атлы чапкычлар белән урганнар.

Югары (Яңа) Гәрәй – 1816 елда үткәрелгән 7 нче ревизия 8 хуҗалыкта 66 «башкорт» яшәвен ачыклаган. 1912 елда халык саны 169 га җиткән. Авыл янында һәм Шәбез елгасында җил һәм су тегермәннәре эшләп торган.

Елан – Сөн һәм Калмия елгалары арасында урнашкан, Бүләр волостена кергән. Авыл XVIII гасыр башыннан билгеле. 72 төр яңа салымнарга каршы күтәрелгән восстание барышында, **1708** елның гыйнварында Күчем Теләкәев һәм Алдар Исәкәев гаскәрләре Казан каласын штурмларга юнәлгәч, Елан авылында гомер итүче Мәскәү Уразаев үзенең 2 мең җайдаклы отряды белән Сарапул янындагы рус авылларын туздырып йөри, ә ахырда Уфа өязенә күченеп, Бакалы белән Яркәй арасында үз исемендәге авылны нигезли.

Бу вакытта Елан үз мин-минлеге белән волость үзәге булып та саналып йөри, аңа якын-тирәдәге Тегермәнлек, Тугаш (Мөслим районында), Бишкүмәч авыллары буйсына. Шушы төбәктәге авыл кешеләре бүгенге Илеш, Шаран тарафына күченү сәбәпле, аеруча Илеш районы җирләре бераздан ныклап Елан волосте дип атала башлый.

1785 елда, Ахун, Байсар, Кадермәт авылларының вәкилләре үзләренең Зәй елгасы буендагы вотчиналарын генерал А.Г. Петров-Соловковка сатып җибәргәндә, әлеге алыш-бирештә Елан авылыннан Әбиш Котлымөхәммәтов та катнашуы мәгълүм. 1795 елда тәүге тапкыр җанисәп үткәргәндә Еландагы 18 хуҗалыкта 158 кеше гомер итә. 1912 елда 128 хуҗалыктагы халык саны 659 га җитә. Бүгенге Сарман районындагы Петров спирт заводы нәкъ әнә шул генерал төзеп калдырган нәфес җимеше инде ул.

●Такталачык авылында Гамил Афзал көннәре.

● Байсар авылы янындагы иген басуына Р.Миңнеханов һәм М.Әхмәтов килү, 2008 ел.

Иске Җияш – Шәбез елгасы буена урнашкан, Гәрәй волостеның Әҗәкүл түбәсенә карый. **XVII гасырда** нигезләнгән. 1795 елда тәүге тапкыр үткәрелгән ревизия барышында авылдагы 27 йортта 223 «асаба башкорт» яшәве ачыклана. Җияшнең 5 вәкиле 1744 елда ук Әҗәк күлен Каракүл крестияннарына 30 ар сум хисабыннан 10 елга арендага бирү килешүен төзегәндә катнаша. Шул ук елда җияшлеләр Бурсык, Кабан, Ногай, Такталачык вотчинниклары белән бергә Ямалы һәм Мүкле күлләрен дә арендага тапшыра. 1763 елда Җияш, Актанышбаш, Әҗәкүл, Куян, Мерәс, Теләкәй авылы вәкилләре Әҗәк күлен яңа срокка, 15 елга 26 шар сумнан арендага бирә. XIX гасыр башында әлеге авылдан Яңа Җияш аерылып чыга. 1816 елда анысында 36 кеше яшәсә, 1912 елда 473 типтәр гомер итә. Иске Җияштән дистәләгән гаилә 1763 елда Башкортстанның бүгенге Нуриман районындагы Кызылъяр авылына күчеп утыра.

Зөбәер – Бәҗәнә елгасы буенда урнашкан, Бүләр волостеның Мөшегә түбәсенә карый. Тәүге тапкыр ревизия кергән 1795 елда 28 йортта 214 «башкорт» гомер итә. Авылга исем биргән Зөбәернең **1739** елда туган улы Акай тирә-юньдә бурычка биреп торучы кредитчы буларак танылa, бер 1785 елда гына да Уфа һәм Минзәлә өязләрендәге 13 авылдан 16 кеше аңа бурычлы булып санала. Зөбәернең Шәнгәрәй һәм Хөсәен атлы ике оныгы 1812 елгы Ватан сугышында катнашып, икешәр көмеш медальгә лаек була.

1903 елда авылда 695 «асаба башкорт» санала.

Илчебай – Гәрәй волостеның әүвәл Әҗәкүл, аннары Җәнҗегет (Краснокама районында) түбәсенә буйсынып яшәүче «асаба башкортлар» авылы. 1795 елда тәүге тапкыр бу авылда үткәрелгән ревизия биредә 223 «башкорт» яшәвен ачыкласа да, тарихы бик катлаулы. Әҗәкүл түбәсенә буйсынган Уразай, Актанышбаш, Әҗәкүл, Җияш, Теләкәй, Мерәс, Балтач, Шәрип, Ирмәш авылы вәкилләре 1838 елда Оренбург губернаторы В.А.Перовскийга үтенеч кәгазе язып бирә һәм ерак бабаларының Агыйдел аръягындагы Бөре өязендәге, Җәнҗегет түбәсендәге җирләргә **1620**, 1641, 1651, 1685, 1700 елларда бирелгән грамоталар буенча хуҗа булып торуларын дәлилли. Әмма 1832 елда Оренбург губернасына караучы өязләрдә Генераль чик сызыгы - межалау үткәрү башлангач, Минзәлә өязе составына кергән авыл крестияннары Бөре өязендә, Җәнҗегет һәм Ябалак түбәсендә һ.б. җирләрдә үз бабаларына беркетелгән вотчиналарыннан мәхрүм ителә. Бер Җәнҗегет түбәсендә генә дә бу рәвешчә вотчинасыз калдырылганнар саны 778 кешегә җитә. Илчебай авылыннан Җәнҗегет түбәсендә хәтта туганнары булганнары да печән чабу, язгы чәчү барышында элек үзләренеке саналган басу-яланнарга кертелми, вотчина җирләре дә бермә-бер кими. Аңлашыла булыр: мондый үтенеч-шикаятьләрнең берсен дә бер генә түрә дә кара халык файдасына хәл итми...

Ирмәш – без аның тарихын Байсар авылы белән бәйле аңлатмаларда телгә алдык инде, кабатлап тору артык. Авылны 1738 елда Йәнәй волостеннан күчкән Ирмәш Урмашев атлы вотчинник нигезләгән.

Кадермәт – Терпеле елгасы буенда, әүвәл Йәнәй, аннары Байсар волостеның Богады түбәсенә карый. 1795 елгы ревизиядән соң гына телгә алына, авылдагы 7 йортта 37 «асаба башкорт», тагын 3 хуҗалыкта 19 типтәр булып язылган крестияннар яши. Ләкин Кадермәт авылы **XVII гасырның II яртысында**, Йәнәй волостен яңа түбәләргә бүлгән чакта ук, Богады түбәсе составында санап үтелә (Ә.Әсфәндияров. Аулы..., 26 бит). Ә шушы ук галим Ә.Әсфәндияров Йәнәй волостеның Калмаш авылындагы йөзбашы Кадермәт Дусмәтевны Кадермәт авылына беренче йорт нигезен салучы булуы да мөмкин, дип фаразлый. Чөнки әлеге Кадермәт атлы шәхес 1745 елгы бер документта Суыксу авылы вәкилләре белән бергә Кама елгасы буендагы бер вотчинасын 40 ар тиен түләп тору исәбеннән Сарапул өязендәге Касево авылы крестияннарына 16 еллык арендага бирү уңаеннан искә алына. Ләкин 1745 елда сарапуллылар белән килешү төзеп йөргән Кадермәт Дусмәтовның Йәнәй волостен түбәләргә бүлгән 1660 яки 1670 еллар тирәсендә Кадермәт авылына нигез сала алуы мөмкин түгел. Димәк, XVII гасыр уртасында бу авылга нәкъ шундый ук исемдәге бүтән бер Кадермәт нигез салган.

Ә Йәнәй волостеннан Тугыз түбәсеннән күчеп килгәннәрне Богады түбәсендәгеләр вотчинник дип түгел, ә типтәр катламындагылар дип кенә кабул итә. Чөнки «асаба башкорт» дип язылганнарның һәркайсына 40 дисәтинә хисабыннан җир бүләргә кирәк, ә типтәрләр җан башына 15 дисәтинәдән дә артыгына өмет баглый алмый. Төп сәбәп менә шул булгангадыр, ахрысы, 1816 елгы җанисәп вакытында Кадермәттә нигезләнгән 364 крестиян – Богады түбәсе «башкортлары» дип, ә 48 кеше Тугыз түбәсеннән күчкән типтәрләр булып языла. 1777 елгы бер килешү буенча, Кадермәт һәм Богады «башкортлары» Каракүл авылыннан күченгән

АВЫЛЛАРЫ

дәүләт крестияннарына Богады янәшәсендә Рус Әҗбие авылын нигезләргә рөхсәт бирә (ул авыл озак яшәми).

1912 елда Иске Кадермәттәге «башкортлар» саны 733 кә җитә.

Яңа Кадермәт авылы 1870-1900 еллар арасында барлыкка килә. 1912 елда анда 66 гына типтәр яши.

Кәзкәй – Сөн һәм Тыңламас елгалары буенда, Кыргыз волостеның Ябалак түбәсе составындагы авыл. Коркыт би дәвамчыларының янәшәдәге Кыргыз авылында 1570 елларда ук гомер итүен истә тотсак, әүвәл казах халкының бер ыруы исеме белән аталган Кәзкәй дә XVII гасырда ук нигезләнгән булырга тиеш. Ул 1795 елгы ревизиягә чаклы телгә алынмый, ә шул елда 15 йортта 80 «асаба башкорт» гомер итүе ачыклана. 1840 еллар башында Кәзкәйгә хәзерге Әгерҗе районының Тирсә, Туба, Чишмә авылларыннан элек генерал-алпавыт Котлыгмөхәммәт Тәфкилевның крепостнойлары саналган крестияннар да күчеп урнаша, 1848 елда алар 17 хуҗалыктагы 117 кеше исәпләнә. Авыл шундый «коллар» белән баетылуга да карамастан, халык аны тоташы белән «башкорт вотчинасына» әйләндерүгә йөз тота. 1861 елда 13 кешелек 3 гаилә типтәрне бүгенге Нуриман районындагы Кызылъяр авылына да куып җибәрәләр. Ләкин төрле катламга бүленеп яшәү үзгәрми, тирә-юньдә элек 173 «башкорт» вотчиннигына исәпләп бирелгән имана җирләре дә җитми. 1912 елда 144 йортта 714 «башкорт», 55 хуҗалыкта элек Тәфкилев коллары булып исәпләнгән 274 татар яши.

Каентүбә – Йәнәй волостеның Камбарка түбәсенә карый. 1800-1808 елларда Байсар, Кадермәт, Исәнбай, Апач, Сикия авылларыннан 20 шәр йорт күчеп өстәлгәч, Каентүбәнең исеме Татар Әҗбие булып үзгәрә. Мондагы «башкортлар» Бүләр волостендагы вотчинникларга да үз авылына күченергә рөхсәт бирә. Кайбер вотчинниклар Байлар волостеның Салагыш түбәсеннән дә күчеп утыра. 1754 елда каентүбәлеләр Йәнәй волосте старшинасы Уразман Уразаев җитәкчелегендә Кама буенда үзләренә беркетелгән һәм балык тоту өчен файдаланылган урыннарны Уфа сәүдәгәре Шишковскийга һәр ел өчен 60 сум исәбеннән 25 елга арендага бирүдә катнаша.

1863 еллар тирәсендә кантон системасын бетерү турында имеш-мимеш тарала башлагач, Усы белән Каентүбә-Тат.Әҗби ирләре Оренбург казаклары янына вәкилләр юллый һәм Үрге Урал яки Троицк казаклары сафына кушуларын сорап сөйләшүләр алып бара. Соңыннан казак булырга әзер 300 «башкортның» исеме ачыклана. Алар җәза күтә, ә 9 гаилә, түзмичә, 1911 елда Кыр-Каентүбә утары ясап яши башлый.

1912 елда Каентүбәнең 115 йортында 541 крестиян гомер итә.

Карач – Байлар волостеның Калмаш түбәсенә буйсына. Үзләре файдаланган җирләргә законлы рәвештә хуҗа булуларын исбатлау өчен, карачлылар бабалары **1691** елдан башлап ясак түләү турында квитанцияләрне чыгарып сала. 1764 елда Карач «башкорты» Габделсәлам Кадыйрбәков коллежский регистратор С.Лутохиннан 12 ел дәвамында эшләп түләү шарты белән бурычка 25 тәңкә акча ала һәм тарихка элгә. 1795 елда 27 «башкорт» һәм 48 мари гомер итә. Кантон башлыклары кенәгәләрендә алар типтәр дип тамгалана.

Калмаш – биредә дә Йәнәй волостеның Камбарка түбәсендә саналучы «башкортлар» яши. 1795 елда 30 йортта 238 «башкорт» исәпкә алына. Әмма йөзбашы Кадермәт Дүсмәтевнең Сарапул янындагы Касево крестияннары белән алыш-биреш итүе аркасында 1745 елда ук авыл тарихка керә. 1749 елда авыл «башкортлары», шушы ук Кадермәт якындагы Терпеле, Өшәр, Карт, Апач, Буазкүл вәкилләре белән берлектә, елына 20 сум түләү шарты белән Агыйдел тамагыннан Ямалыга кадәр арадагы балык урыннарын Каракүл крестияннарына 10 елга арендага тапшыра.

Карт – Йәнәй волостеның Камбарка түбәсендәге «башкорт» авылы. Бирегә 10 гаилә Каентүбә, 5 хуҗалык Кадермәт, 3 гаилә Теләнче (Мөслим районындагы бүгенге Октябрь) авылларыннан күчеп килә. Мәгәр 1816 елда 18 йортта 105 «башкорт» яши, дип җанисәпкә алына. Ләкин тарихи документларда Карт вәкиле Сәфәр Габдуллов, күрше берничә авыл елгырлары белән бергә, Камбарка елгасы тирәсендәге яланнарны Кама буендагы Сарапул каршында урнашкан Березово авылы крестияннарына 10 елга арендага бирү турында килешү төзү уңаеннан телгә алына. 1746 елда Карт «башкорты» Давыт Сөрмәтев та Кече Сагадак күлен 10 елга Каракүл крестияннарына арендага тапшыра.

1905 елда авылда 527 кеше яши, Башкортстанның Балтач районына күчеп киткәнгәме, алар 1912 елда 340 ка гына кала.

Качкын – Бәҗәнә елгасы буена урнашкан, Бүләр волостеның Мөшегә түбәсенә карый. **1728 елдан** билгеле (әмма качкынлылар үзләре безнең атайлар Әмәкәй авылы белән бергә, 1687 елда бирелгән саклау грамотасы нигезендә килеп төпләнгән, дип бара). Ул чакта Качкын «башкорты» Әхмәт Кутуев үз вотчинасын һәм Мөшегә, Мазар, Тозлыбүләк елга-инешләре буенда улы Күчем исеменә язылган кишәрлекләрен Исәнсеф авылы татары Туктар Тимеевка сатып җибәрә. 1762 елда авылда 45 типтәр теркәлгән, ә 1816 елда алар 83 «башкорт» булып язылган. Килмешәк «башкортлар» Байлар волостеның Салагыш түбәсеннән (Әгерҗе районында) күчеп утырган, аларның вотчинник булуын раслап, ерак бабалары 1673, 1684 елларда ук грамоталар алган. 1834 елгы ревизиядән соң җир җитмәгәнгә 46 «башкорт» типтәре Бәләбәй өязендәге Кыр-Елан волостена (Ярмәкәй районында) күчеп китәргә ризалыгын бирә.

1905 елда авылда 807 кеше гомер итә.

Күҗәкә – Байлар волостеның Калмаш түбәсе составында. 1700 елдан билгеле. 1795 елда анда инде 49 хуҗалыкта 359 «башкорт», 5 йортта 30 типтәр гомер итә. 1798 елдан соң типтәрләр 1 нче типтәр командасына буйсына. 1816 елда авылда 465 «башкорт» исәпкә алына. Бу авыл вәкилләреннән Габдессәлам Габдрәшитов белән Габделҗәлил Солтанов хәрби хезмәттә күрсәткән батырлыклары өчен дворян дәрәҗәләренә лаек була. 1905 елда авылда 822 кеше исәпләнә.

Колын – Бүләр волостеның Мөшегә түбәсенә карый. **1700 елдан** билгеле. 1816 елда авылда 66 «башкорт» һәм 35 типтәр исәпкә алына. 1905 елда халык саны 642 гә җитә.

Иске Кормаш – Шәбез елгасы буенда Бүләр волосте «башкортлары» авылы. Тарихи документларда **1614** елда ук телгә алына, әмма тәүге җанисәпләргә кертелми. 1795 елда 57 вотчинник исәпкә алынса, 1834 елда алар саны 247 гә җитә. Аларның 159 ы Байлар волостеның Салагыш түбәсеннән күчеп килгән була.

Яңа Кормаш 1859 елгы ревизия алдыннан барлыкка килә, шул елда анда инде 166 вотчинник исәпләнә. 1905 елда Иске Кормашта – 1109, Яңасында 736 кеше гомер итә. Яңа Кормаштагылар үзләрен Салагыш түбәсенең Барҗы авылыннан күчеп килгән «башкортлар» дип күрсәтә. Бабаларының бер өлеше 1811 елгы ревизиядән соң, бигрәк тә җир җитмәгәнгә күрә, кабат Барҗыга кайтып китә, ләкин имана җире алар өмет иткән күләмдә бирелмәгәч, элек үз вотчиналары булган урында Яморза авылын нигезли. Әмма анда да җир күләме аз бит, аптырагач, алар Алабуга өязе судына мөрәҗәгать итә һәм Салагыш елгасы буенда үзләре сайлаган яңа төбәккә күчерергә рөхсәт бирүләрен үтенә. Тик җирдәге эт өрүне күк йөзендәге Ай ишетәме соң?! «Башкорт катламы» булып 40 ар дисәтинә җир эләктерә алмагач, ул бичаралар типтәрләр сафын ишәйтә.

1912 елда Яңа Кормашта 512 «башкорт» һәм 512 типтәр яшәсә дә, «башкортларга» – 1525, типтәрләргә 574 дисәтинә генә җир элгә. Типтәрләрнең һәр хуҗалыгы 3,7 дисәтинәдән артык имана җиренә өмет итә алмый. Мәгәр үзеңне урыс җире өчен кан коеп күрсәтү мөмкинлеге бар бит. Кормашлылардан Габидулла Җомангулов 1812 елгы Ватан сугышында, 1814 елда Парижны яулауда катнашып, ике көмеш медаль иясе булып кайта.

Иске Кормаш 1893 елда Әхмәтхафиз хәзрәт Дәүләтьяров төзегән мәдрәсә белән дан ала. Бу авыл мәктәбе берьюлы өч атаклы рәссамны тәрбияләве белән дә танылды. Әсгать Сәфәргалин - Украинаның халык рәссамы, Харьков өлкәсендәге Рәссамнар берлеген 20 ел буе җитәкләп һәм аеруча Бөек Ватан сугышы чорындагы партизаннар каһарманлыгын сурәтләп дан алды. Зилфәт Басыйров 1960 елларда Башкорстан Рәссамнәр берлеген җитәкләде, рәсем генә түгел, сыннар да ясап, үзенең искиткеч талантлы булуы белән танылды. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Васил Маликовны Казанның М.Горький исемендәге парк капкасы алдына Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә ясаган гаҗәеп һәйкәле һәм совет хакимияте чорында танылган революция, хезмәт һәм сугыш каһарманнарын тасвирлаган йөзгә якын сыннары буенча бар татар дөньясы яхшы белә. Берьюлы өч халык рәссамын тәрбияләп үстергән мәктәп – барча Советлар Союзы өчен бердәнбер.

Куян – Гәрәй волостеның Әҗәкүл түбәсендә. 1795 елгы ревизия үк авылда 250 «башкорт» яшәвен ачыклый. Рәсми китапларда Куян авылы 1784 елда Ирәкте волостена беркадәр җир сатуда катнашуы уңаеннан гына телгә алына иде. Әмма шушы авылда туып үскән Фәнис Газетдинов тапкан шәҗәрә һәм документлар нигезендә Гөлүсә Закирова «Агыйдел Куяны» исемле аерым китап бастырып чыгаргач, авылның әле **XVII гасырда** ук нигезләнеп китүе һәм аңа бәйле вакыйгалар аша без аның тарихи байлыгына сокландык.

1912 елда авылның 172 хуҗалыгында 453 «башкорт» гомер итә.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

● Актаныш әдипләренә багышланган панно.

● Актанышта Г.Тукай бүләгенә лаек булган якташлар хөрмәтенә куелган һәйкәл.

Якутиягә сәяхәткә барып чыккач, «Сахафильм» якут дәүләт кинокомпаниясе студиясендә кино төшерүчеләр төркеме белән аралашмыйча калу мөмкин түгел иде. Алар – җитәкче, кинопродюсер Сардана Саввина (июнь башыннан җитәкче итеп Алексей Егоров билгеләнде, Сардана Саввина «Сахафильм»нан китте); сәнгать җитәкчесе, кинорежиссер, сценарист Алексей Романов; режиссерлар Эдуард Новиков һәм Любовь Борисова. Аларның һәркайсы бу феноменны үзенчә ничек күрүен сөйләде. Әңгәмәдән чыгып, якут киносының барлыкка килүе, уңышы серләре, киноның халык узаңына тәэсире сурәтен күзалларга мөмкин булды.

ЯКУТ КИНОСЫ

●Сулдан уңга: Алексей Романов, Любовь Борисова, Сардана Саввина, Эдуард Новиков.

Әңгәмә башында Алексей Романов якут киносы башлангычы турында бәян итте. Ул Бөтенроссия дәүләт кинематография институтында (ВГИК) укыган, Якутск шәһәрендә ул вакытта киночелтәр һәм кинопрокат кына булган, ә Романов милли кинематография турында хыялланган.

Алексей, бөтенесен шаккатырып, «Ленфильм»нең чакыруыннан баш тарта да, ВГИКтан туган җиренә кайтып китә. Бу – 1990 еллар, Алексейга диванага караган кебек карыйлар: монда ил тарала, ә бу кеше студия төзергә тели! Ул 2 ел эшсез йөри, аннары исә «Северфильм» иҗади берләшмәсен төзиләр. Эшне чиркәүнеке саналган зур булмаган бүлмәдә, совет фильмнарын якут (саха) теленә дубляж ясаудан башлыйлар. Җиһазлар булмый, әмма республика җитәкчелеге, төгәлрәге, Якутиянең беренче президенты үтенечләрен канәгатьләндерә – «Сахафильм» дәүләт кинокомпаниясен дә төзиләр, җиһазлар да сатып алалар. Режиссерлар алдан ук бүтән киностудияләр белән уртак проектлардан баш тарта – киноны үз тырышлыклары белән төшерергә карар кылалар. «Киноны «эчтән» эшләргә кирәк иде», – ди Романов.

Кызыксынган кешеләрне җыеп, әкренләп, «Орто Дуйгу» («Серединный мир», 1993) фильмын төшерәләр. Ул этнографик нәфис фильм була, җирле йолалар – баланың дөньяга килү йоласыннан башлап, теге дөньяга күчүенә кадәр гореф-гадәтләрне күрсәтүче фильм-реконструкция. «Фильм төшерү өчен акчаны халыктан җыйдык: аерым кешеләрдән, оешма-предприятиеләрдән», – ди Романов. Фильм прокатка чыга, телевидение аша күрсәтәләр. Әмма ул вакытта прокаттан табыш алу турында сөйләү урынсыз була. Ләкин «Сахафильм» иң мөһимен эшли – бүген бөтен дөнья таныган киләчәк фильмы өчен нигез сала (баштa программалар Пусан һәм Берлин фестивальләрендә катнаша, ә быел якутлы Арбугаевлар төшергән фильм «Оскар»да номинацияләнде).

Кино тармагының алдагы этабы – белгечләр әзерләү. Республика җитәкчелеге режиссерлар, тавыш операторлары, оператор, сценарист, продюсерлар әзерләү буенча максатчан, системалы эш алып бара. 30 ел эчендә 60 тан артык кеше илнең төрле югары уку йортларында укып чыга, алар өчен бюджеттан түлиләр. Укуны тәмамлагач, алар үзләренә кайта, Якутиядә эшли башлыйлар, үз шәхси компанияләрен ачалар. Һәм иң мөһиме – кинотеатрлар да, «Сахафильм» да шәхси компанияләргә көндәш итеп карамый, киресенчә, аларга ярдәм итә.

Алексей Романов сөйли: «Быел «Сахафильм»га 30 ел. Кинокомпания, локомотив шикелле, Якутиядә кино үсеше өчен импульс бирде. 2015 елдан җитдирәк фильмнар төшерә башладык, алар республика чикләрен дә үтеп чыкты, чыгымнары каплана башлады. 2013 елларга кадәр «үз казаныбызда» гына кайнадык. Аннары Якут халыкара кинофестивале барлыкка килде; экспертлар, кино тәнкыйтьчеләрен чакырдык; аннары үзебезнекеләр республика чикләрен чыга, төрле фестивальләрдә катнаша башлады. Шулай, төрле фестивальләрдә бүләкләнә-бүләкләнә, әкренләп, якут киносы танылды. Шул вакыттан «якут киносы феномены» турында ешрак сөйли башладылар.

– Һәм тамашачы йөри башладымы? Кинотеатрлар да сезне тыңладымы?

– Кеше дә йөри, кинотеатрлар үзләре үк заказ бирүче дә. Гомумән, безнең кино берләшмәсе үзара дустанә мөнәсәбәттә, бер-берләренә ярдәм итәләр. Әгәр Эдуард Новиков картинасында бер кеше түләүсез эшләгән икән, икенче юлы Эдуард аларга бушлай барачак. Белгечләр белән шундый натуралата алмаш. Нәтиҗәдә, очсызлы җитештерү барлыкка килә, чыгымнар каплана. Кеше 3 миллионга кино төшереп, 10 миллион җыярга мөмкин. Дөрес, табышның 50%ын кинотеатрларга бирәләр...

Кино төшергәнсең икән, ул әле сатылырга да тиеш. Бездә ул үсеш стадиясендә, соңгы 3 елда Россия кинопрокатына 5 картина чыкты. Минемчә, безнең кинопродюсерларга әле үсәсе дә үсәсе, һәм әгәр барып чыга икән, режиссер һәм киносценаристлар да лаеклы тормышта яшәячәк, иҗат итәчәк. Әгәр «Сахафильм» турында гына сөйләсәк, чама белән 160 фильм төшерелгән инде. Шәхсиләрне дә санасак, 230-240 фильм тирәсе.

Әңгәмәгә режиссер Эдуард Новиков кушыла: «Мин режиссерлыкка 1996-2001 елларда Петербургта укыдым, «Сахафильм»га эшкә урнаштым. Монда килгәч, «Харамааска» («Кара маска») детективын төшердек. Фильм заказга эшләнде, Саха Республикасы Социалистик Хезмәт героеның (Якутия) этисе Тарас Десяткин турында. Betacam видеокассеталарына 2 елга якын төшердек. Бюджетлы телевизион формат. «Харамааска» бөтен кинотеатрларда куелды, кеше йөрде. Кинода да акча эшләп була икән, дигәнниндидер этәргечне шул биргәндер».

– Мин үзем бәләкәйдән үк якут фильмнарын карап үстем, алар бар иде инде, – дип кушыла Любовь Борисова. – Һәм бик югары дәрәҗәдә иде: анда драматургия дә, стиль дә, тел дә бар. Димәк, безгә әле бәләкәйдән үк үз кинобызны төшерү теләге салынган булган. Соңрак яшьләрне Петербургка, Мәскәүгә укырга җибәрә башладылар. Берничә агым белән 60 тан артык кеше укырга җибәрелде – бу республиканың кадрлар буенча максатчан сәясәте иде. Иң элек чыганак – чишмә башы бар иде, аннары кадрлар әзерләнде, алга таба сан ягыннан үсеш – «кинобум» башланды, алар арасыннан иң яхшы фильмнар сайлап алынып, фестивальләргә җибәрелде.

Шундый вакытлар булды – без аны «кинобум» дип атыйбыз – бөтенесе, ашкынып, кино төшерә башлады. Беләме-белмиме – мөһим түгел, төшерә. Елына 20 шәр фильм төшерәләр иде. Кинотеатрлар бөтен фильмнарны рәттән ала, сыйфатка карап тормый иде. Ә киноны тиеннәргә төшерәләр – бик кечкенә бюджетка. Соңыннан исә сан, әкренләп, сыйфатка күчте. Тәҗрибә туплый башладык, очраклы кешеләр китте, профессионаллар калды. Шулай итеп, күләм 6-7 тапкырга кимеде.

Иң беренче пионерларның берсе – режиссер Семен Потапов – кинотеатр заказы белән «Любовь моя» авторлык фильмын төшерде. Бу фильм белән бәйле бераз тавыш булды, һәм күпмедер дәрәҗәдә шуның аркасында ажиотаж чыкты, кинотеатрларга халык агылды. Кинотеатр хуҗалары шундук аңлап алды: әһә, халык өелеп килсен өчен, үзебезнең фильмнарны төшерергә кирәк икән! Шулай итеп, коммерция ягыннан мәнфәгатьләр баш калкытты. Ул вакытта чыгым каплану дәрәҗәсе искиткеч зур иде. Уйлап кара, 100-200 мең кертәсең дә, берничә миллион табыш аласың.

– 100 меңгә кино төшереп буламыни?

– Ул вакытта була иде. Телефон форматын күз алдына китер, ләкин ул вакытта телефоннар юк әле. Бер егет, әйтик, камера күтәреп йөри дә, кино төшердем, дип сөенә. Энтузиазм белән. Хәтерлим, бервакыт бер кино тәнкыйтьчесе безгә 2 мастер-класс күрсәтте дә: «Сыйфат саннан гына килеп чыга», – дигән фикерне хәтергә төшерде. Шуңа күрә, әйдәгез, бөтен акчага бер яхшы фильм төшерәбез, дигән схема беркайчан да эшләми. Берсе уңсын өчен 10 фильм төшерергә кирәк.

– Кинотеатрлар ала идеме?

– Алар үзләре үк заказ бирә иде. Күбрәк болай була: режиссер яки продюсер үзенең дусларын чакыра да: «Әйдәгез, фильм төшерәбез», – ди. Бөтенесе дә бушка эшли. Бу фильм касса җыйгач, акчасын алалар да бүләләр. Шундый схема иде. Ягъни барысы да акча алачагына команда ышанырга тиеш... Әлбәттә, оттыручылар да булды, тәвәккәллек сорый торган эш бит... Хәзер актив рәвештә тагын 10 студия эшли, тагын 5 әле күренә, әле юкка чыга...

– Актерлар да бушлай төшәме?

– Ул вакытта – әйе. Ә хәзер укыйлар, гонорарлар да үсә. Хәзер актерлардан берәү дә бушка эшләми. Нигездә, бездә театр артистлары хезмәт куя. Ниндидер типаж кирәк икән, без халык театрлары буйлап эзли башлыйбыз яки кастинг игълан итәбез. Бөтен театр артистлары безнең «йолдызлар» инде. Халык арасыннан Степан Петровны таптык, ул инде 2 фильмда төште. Беренче ролен уйнаганда аңа 73 яшь иде.

– Ә кинорежиссерлар?

– Шулай ук, юк. Якут киносы ул – акча, дан түгел. Ул – халык мәхәббәте. Тамашачыбыз бик таләпчән, һәрчак сыйфатны арттыруны таләп итә, тормыш дөреслеген сорый. Уңга-сулга бер адым – аталар, без һәрчак, алар ни әйтер, дип борчылабыз.

ФЕНОМЕНЫ

Сардана Саввина дилбегәне үз кулына ала: «Әгәр проектлар баштан ук кыйбатлы, әйтик, 100 млн сумнан башланса, табигый, мондый уңыш булмас иде. Нәкъ менә башта арзанлы проектлар булганга, аларны әйләндерергә, касса җыярга, нольгә, кайвакыт хәтта «плюска» чыгарга мөмкин булды. Соңгы елларда, әлбәттә, бөтенесе дә "плюска" чыгарга тырыша. Аппаратура белән тәэмин итү программасы барлыкка килүгә бәйле рәвештә, кинотеатрлар саны артты. Кино фонды авыл кинотеатрларына аппарат – кинофикация, экран өчен акча бүлеп бирә. Әлбәттә, пандемия, сәяси вакыйгалар – Голливудтан китүебез аркасында, прокат хәзер бик зур авырлыклар кичерә. Анализлар буенча, илдәге кинотеатрларның 25%ы ябылган инде. Ә бездә якут контенты булганга, әлегә эшлиләр. Әйтик, Голливуд китте, аның урынына безнең тамашачы якут киносын карый. Идеалда, без аена 1-2, иң яхшысы – 3 картина чыгуын телибез, елына 36 картина булыр иде. Ә хәзергә без 10-12 картина планын үтибез, ягъни айга 1 картина дигән сүз. Бу – бик яхшы. Элек беркайчан да мондый саннар булганы булмады. Әлбәттә, мин бөтен якут студияләре фильмнары турында әйтәм, «Сахафильм» үзе генә ул кадәр фильм чыгара алмый».

– Ә «Сахафильм» елына ничә фильм чыгара?

– Елына кимендә 1 картина чыгарырга телибез, идеалда – 2. Кино төшерүдән тыш, безнең тагын башка бик күп эшләребез бар: залларны тотабыз, дәүләт заказы буенча документаль фильмнар төшерәбез. Уен фильмнары да бар. Безнең бурыч – якут киносына ярдәм итү. Якутиянең 90% фильмнары «Сахафильм» аппаратурасына төшерелә. Без ташламалы бәядән җиһазлар бирәбез, югыйсә алар нинди базада эшләрләр иде?! Аппаратура бик кыйбат. Шул рәвешле, бәйсез якут киносына дәүләт ярдәме килеп чыга.

– Фильм уңышының төп критерие сценариймы, идея, актерлармы?

– Иң мөһиме – әйбәт эчтәлек. Кешеләр бит матур сурәт карарга килми, аларга күңелләренә үтеп кереп, балаларның да, өлкәннәрнең дә йөрәкләрендә эз калдыра торган тарих, вакыйга кирәк. Безнең кинематографларга кайчакта, фестиваль фильмнары төшерәсез, диләр. Ышаныгыз, авторларның берсе дә башта бу турыда уйламый. Ул бер тарих төшерә, әгәр бу тарих шулай уңышлы чыккан һәм фестивальгә дә, прокат өчен дә бара икән, бер атуда ике куянга тигерә, дигән сүз. Бу – бик шәп! Бөтен кеше дә тамашачыга барып җитәр өчен төшерә.

– Димәк, сездә, миңа шуның кадәр акча бирегез, мин сезгә яхшы фильм төшереп бирәм, дигән схема юк? Яки, читтә яхшы сценарийга заказ бирү дигән нәрсә?

– Юк. Читтә ниндидер яхшы сценарийга заказ бирү мөмкин түгел, чөнки чит кеше белән мәдәни контекстны аңлап булмый. Милли материал белән эшләгәндә консультантларның нәкъ шул шул мәдәният вәкиле булуы кирәк, куючы да шундый булса, тагын да яхшы. Шул вакытта гына теманы эксплуатацияләүче түгел, ә тамашачы ышана торган фильм туа.

Мин нәрсә әйтергә телим: себер кешеләре образы кинода, мәдәнияттә кимсетеп бирелә, мәсәлән, барысы да – чукчалар. Ә бит Себердә бик күп халыклар яши, һәм алар бер-берләреннән нык аерыла. Шуңа күрә андый сорауларга бик сак карарга, хөрмәт һәм игътибар белән якын килергә кирәк.

Якут киносы хәзер уңыш казана, чөнки якут мәдәнияте вәкилләре үзләре дә үз телләрендә иркен сөйләшә һәм материалны үзләре төшерә. Үзе турында һәм үзе өчен. Читтән килеп, безнең хакта түгел. Менә сезнең «Әпипә» фильмы бар иде. Тамашачылар үзләренең җирле «йолдызларын» карарга барсын өчен, җирле «йолдызларның» актерлык осталыгын күрсәтергә кирәк.

Әгәр лидерлык позициясендә җирле кадрлар икән, ә төшерүчен читтән килгәннәр төшерә икән, бу – нормаль күренеш. Консультантлар, куючыларның җирле кадрлар булуы мөһим. Алай түгел икән, алар теманы эксплуатацияли булып чыга.

– Ә сез Россия « йолдызларын» чакырасызмы?

– Әлбәттә, Россия «йолдызлары» катнашуы турында хыялланабыз. Ләкин аларның бәяләрен сез беләсез. Шулай да, барыбер, киләчәктә алар белән эшләргә планлаштырабыз. Безнең инде Россия сериал актерлары белән эшләү тәҗрибәсе бар. Алар үзләре үк теләк белдереп, безгә язалар, пробаларын җибәрәләр.

– Кино төшерүчеләр, бюджетның яртысы рекламага китә, дип әйтергә ярата...

– Әйе, ләкин безнең шәһәр бәләкәй. Бюджетка акча салганда, әлбәттә, аны алга җибәрү өчен дә салырга кирәк. Зур проектларга, чынлап та, реклама өчен бюджетның яртысы китә, диләр. Бездә алай ук күп түгел. Җиңел комедияләр куючы яшь блогерлар бик акыллы эшли. Алар эшне алга дөрес итеп җибәрә, социаль челтәрләр аша рекламалыйлар. Безнең компания аны акча түләп эшли, хәтта полиграфия өчен бик күп акча китә. Әмма «Сахафильм» – ул бренд, шуңа күрә «Сахафильм» иҗат җимеше чыкканда, тамашачы килә.

– Иң популяр фильм күпме тамашачы җыйды?

– Бүгенге көнгә рекорд – «Агент Мамбо» криминаль комедиясе. Ул – шәхси студия эше, фильм 17-18 млн сум җыйды, ягъни 70 меңгә якын тамашачы караган, дигән сүз. (Әңгәмәдән соң инде башка фильм – режиссер Степан Бурнашевның «Айта» картинасы 26 млн җыеп, яңа рекорд куюы билгеле булды – авт.) «Тамашачы агымы» дигән төшенчә бар. Якутиядә миллионнан азрак кеше яши, аларның 300 меңе – Якутск шәһәрендә. Төп публика – яшьләр, бәләкәй баларны, өлкәннәрне, үз телендә иркен сөйләшмәүчеләрне «койсак», нәкъ менә 70 мең тамашачы килеп чыга.

Ләкин якут киносын күрергә теләгән төбәкләр бар, әйтик, «Татаркино» – без ел саен анда үзебезнең фильмнарны җибәрәбез. Новосибирск безнең белән бик кызыксына... Әкренләп, шулай башка төбәк тамашачыларын да ияләштерәбез.

– Хәзер фильм бюджеты уртача күпме тора?

– Иң гади фильм 5 млн сум тирәсе. Җитди тарихлылар – күпкә кыйбатрак. Тарихи фильм Россия мәдәният министрлыгыннан 20 млн сум алды, безнекеләр дә 9 млн сум бирде, барысы 29 млн сум.

– Сезнең тәҗрибәне өйрәнергә киләләрме?

– Һәрвакыт. Без татар коллегаларыбыз белән еш аралашабыз, барыбыз да бер-берләребезне беләбез. Кинематографлар Миләүшә Айтуганова, Илдар Ягъфәров, Илшат Рәхимбай, Алексей Барыкин киләләр, без дә аларга бардык. «Татаркино» безнең белән күптән хезмәттәшлек итә, һәм без ел саен анда якут киносы программасы эшли идек. 2016 елдан Россия кинематографлары берлеге бездә форум уздырды, якут киносы үсеше тәҗрибәсен күрсәтү өчен, Россия төбәкләрен чакырды. Без бөтен Россиягә таратырга теләгән эксперимент мәйданчыгы булып торабыз.

Рәмис ЛАТЫЙПОВ,
intertat.tatar.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

9 сентябрь (шимбә). ***Сәфәр аеның 24нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 23.29 сәгатьтә калка, 17.49 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 13.18 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Йөрәккә ярдәм

Йөрәк эшчәнлеген яхшырту өчен, гөлҗимеш, кызыл миләш, дүләнә, балан җиләкләре, йөзем һәм күрәгәне тигез микъдарда алып, 1 стакан кушылманы 1 литр кайнар суда төнгелеккә калдыралар да, көне буена чәй урынына эчәләр. Озак вакыт буе шулай дәвалану файдалы. Миокард инфарктыннан соң йөрәк мускулында барлыкка килгән җөйләрдән котылу өчен, термоска 1 аш кашыгы канлут үләне (чистотел) салып, өстенә 1 стакан кайнар су агызалар, 15 минут төнәтәләр, сөзеп, суыткычта саклыйлар, иртән ач карынга 1әр аш кашыгы эчәләр. Дәва курсы – 10 көн. Инфарктан соң хәлне яхшырту өчен, 200әр грамм вакланган суган һәм балны кушып, көненә 3-4 тапкыр 1әр чәй кашыгы кабалар. Кичләрен 1 стакан әчегән сөт белән 1-2 бүлем сарымсак ашау да йөрәк мускулын ныгыта.

10 сентябрь (якшәмбе). ***Сәфәр аеның 25нче көне. 25 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Арыслан йолдызлыгында, 0.45 сәгатьтә калка, 18.19 сәгатьтә бата. 4нче фаза. Көн озынлыгы 13.13 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Сабынлы суган дәвалый

Чуан чыкканда, тигез микъдарда алынган уылган суган, балалар сабыны һәм туңмайны бераз җылытып, яхшылап болгаталар да, дүрткә бөкләнгән марляга сылап, фурункулга төнгелеккә бәйләп калдыралар. Көн буена йөрергә дә була. Сызлау басыла, эрен суырылып чыга, җәрәхәт урыны тиз төзәлә. Яисә 1әр чәй кашыгы шикәр, уылган балалар сабыны һәм туңмайны кушып болгатып, чуан өстенә компресс куялар.

11 сентябрь (дүшәмбе). ***Сәфәр аеның 26нчы көне. 26нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 2.04 сәгатьтә калка, 18.37 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 13.08 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Ютәлдән – шалфей

Ютәлләгәндә, 1 аш кашыгы шалфейны 1 стакан суда кайнатып чыгаралар, йокларга ятканда кайнар килеш эчәләр. Яисә 1 стакан уылган кызыл чөгендергә 1 аш кашыгы алма серкәсе кушып болгаталар да, бераз төнәткәч, согын сыгып алалар, аннары шуның белән тамакны чайкыйлар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

12 сентябрь (сишәмбе). ***Сәфәр аеның 27нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 18.48 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 13.04 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Сихәтле катнашма

Академик Амосов, операциядән соң организм тизрәк сихәтләнсен өчен, мондый катнашма белән дәваланырга киңәш иткән, ул сәламәт кешеләр өчен дә бик файдалы: 300әр грамм йөзем, курәгә, инҗир, кара җимеш, әстерхан чикләвеген һәм кабыгы белән 1 лимонны иттарткычтан чыгаралар да, 300 грамм бал кушып болгаталар, суыткычта пыяла савытта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, 1әр аш кашыгы кабалар.

13 сентябрь (чәршәмбе). ***Сәфәр аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 3.22 сәгатьтә калка, 18.56 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.59 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

14 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Сәфәр аеның 29 нчы көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 4.40 сәгатьтә калка, 19.02 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.55 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

15 сентябрь (җомга). ***Сәфәр аеның 30нчы көне. 1 нче, 2 нче Ай тәүлекләре. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 5.56 сәгатьтә калка, 19.06 сәгатьтә бата. 4 сәгать 40 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 12.50 сәгать.***

Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

Тозлы кәбестә

Уртача зурлыктагы 1 баш кәбестәне вак итеп тапыйлар, өстәлгә җәеп, 1 аш кашыгы (өеп) тоз сибәләр дә, кул белән яхшылап уалар. 1 кишерне кыралар. Аннары 5 литрлы кәстрүлгә катлап тутыралар: уылган кишер, берничә дәфнә яфрагы һәм төелмәгән кара борыч, кәбестә; аннары тагын кишер, тәмләткечләр, кәбестә. Барысын да тутыргач, зур тәлинкә белән каплыйлар, өстенә 3 литрлы банка белән су куялар. Икенче көнне ачып, берничә урыннан пычак белән тишкәлиләр, кабат банка белән бастыралар. 3 көн шулай эшлиләр. Аннан соң кәбестәне, банкаларга тутырып, суыткычта саклыйлар. Озаграк торган саен, ул тәмләнелә генә бара.

Исламда мәрхәмәтлек

Әхлак вә мөгамәлә мәсьәләләре – ислам диненең иң күп әһәмият биргән нәрсәләреннән бередер. Бер кешенең камил мөселман булуы, дөньяда рәхәт вә тыныч яшәве, хәтта ахирәттә зур дәрәҗәләргә ирешүе дә әхлак вә кешелекле булуының дәрәҗәсендәдер. Бу эшләрдә ислам диненең кагыйдәләрен, Коръән-Кәрим вә хәдис шәрифтә сөйләнгән сүзләрне, күрсәткән юлларны һәрбер мөселман белергә вә белдерергә тиешледер.



●«Йөз ел элек.

Рәсүлуллаһның (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) күбрәк вәгазь вә нәсыйхәтләре ошбу хосусларда була. Безнең мәктәп вә мәдрәсәләребездә якын заманнарга кадәр дин исламның хөкем вә гыйбадәт бүлекләрен генә өйрәтеп, ислам әдәпләре хакында тиешле мәгълүмат бирелмәү вә балаларның күңеленә әхлак вә ислам әдәбен урынлаштыруда тиешенчә тырышмау – рәсүлуллаһның сөннәтләренә хилафтыр.

Муллаларымызның да күбесенчә вәгазьләре халыкның әхлак вә мөгамәләләрен яхшырту, бер-беренә шәфкать вә мәрхәмәтләрен арттыру, һәртөрле юллар илә аларның тыш вә эчләрен төзәтергә вә тәрбияләргә тырышудан гыйбарәт булырга тиештер.

Хосусан, хәзерге кебек бөтен дөньяны дәһшәт каплаган, бик күп зәгыйфь аталар баласыз калган, бик күп яшь балалар тәрбиячесез калган, бик күп хатыннар тол һәм башкаларның ярдәменә мохтаҗ булган бер заманда халыкны бер-беренә ярдәм итәргә, шәфкать вә мәрхәмәткә кызыктыру – шәригать вә ислам җәһәтеннән караганда да, акыл белән уйлап караганда да иң тиеш нәрсәләрнең берсе, бәлки беренчеседер.

Шәфкать вә мәрхәмәт хосусларында мөселманнар һәрвакыт башка милләтләрдән алда торырга, бу эштә башкаларга үрнәк дәрәҗәдә булырга, ислам карьяләрендә (авылларында) мохтаҗ вә ярдәмчесез калган кешеләрнең эшләрен кайгыртышырга тиешледер. Моның өчен имамнар һәрвакыт халыкның исенә төшереп, вәгазь сөйләп, юл күрсәтеп, халык белән киңәшеп торырга, мәхәллә кешеләре, ил агалары шул эшләрне җиренә җиткереп торырга тырышмак тиештер.

Халыкның бер-беренә шәфкать вә мәрхәмәт итүләре – ислам диненең иң зур әһәмият биргән нәрсәләреннән бередер. Халык вә мәхлукатларга шәфкать итү хакында ислам дине зур әһәмият биргәнгә, «Диннең нигезе ике нәрсә – Аллаһның әмерен зурлау һәм Аның бәндәләренә шәфкатьле булу», дип әйткәннәр.

Ошбу хосуста килгән хәдисләр дә күп. Пәйгамбәребез хәзрәтләре кешеләргә шәфкать итү хосусында гына түгел, хайваннарга, хәтта һәрбер җан иясенә шәфкать вә мәрхәмәт күрсәтү хосусында да бик күп хәдисләр сөйләмештер. Ошбу хосусларда вәгазь сөйләргә һәм ислам иршадларын (туры юл күрсәтү) аңларга теләгән кешеләргә һәрбер хәдис вә сөннәт китапларында бик күп мәгълүмат бар.

Инде хайваннарга шәфкать хакында да берәр сүз языйк. Төрле хайваннарның, хосусан атларның һәртөрле эшләрдә халыкка ярдәмнәре күп, эш вакытларында аларга бер көн дә буш торырга туры килмидер. Хайван белән мөгамәлә итүче затлардан байтак кешеләр хайваннарны ригая кылмый, аларга тиештән артык авырлык йөкләтә, аз гына ачуы килсә дә хайваннарга суга, кайбер кешеләр һич гаебе булмаган хайваннарга сугалар, аларга золым итәләр, хәтта кайбер яшь инсафсыз балалар да хайваннарга сугалар, һәртөрле юл белән аларны рәнҗетәләр. Бу эшләр, әлбәттә, акыл ягыннан да, шәригать ягыннан да начар эшләр.

Халык һәрвакыт боларны да хәтердә тотарга, мөгаллимнәр үз ихтыярларында булган шәкертләргә яшьтән үк хайванарга шәфкать итү тиешлеген төшендерергә, күңелләренә урынлаштырырга, муллалар да мәчетләрнең михраб вә минбәрләрендә вәгазь вә нәсыйхәт итеп, мөселман булган кешегә бөтен җан ияләренә мәрхәмәтле вә шәфкатьле булырга кирәк икәнен искә төшереп торырга тиеш. Хосусан яз вә көз көннәрендәге каты хезмәт вакытларында авыллардагы ахмак мужиклар, калалардагы тәрбиясез ямщикларның хайваннарга золым итүләре бик күп күренә. Шул вакытларда җомгада – бер генә мәртәбә мәчеткә килә торган кешеләргә муллалар вәгазь сөйләп, исләренә төшерергә тиешледер. Ошбу хосуста хәдис вә әхлак китапларында бик күп озын мәгълүматлар, кирәкле нәсыйхәтләр язылган.

Безнең илебездә татар галимнәре арасыннан хайваннарны якларга вә ригая кылырга тиешлеге хакында башлап кулына каләм тотучы Мәрҗәни хәзрәтләре булмыштыр. Аның бу хосуста язган сүзләренең кыскасы вә мәгънәсе ошбу:

Рәсүл мөхтәрәм Мөхәммәд әл-Мостафа (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) Аллаһның мәхлукатына шәфкать вә мәрхәмәт, алар белән күркәм мөгамәлә итүне өммәткә өйрәтеп бик күп хәдис шәриф вә нәсыйхәтләр сөйләгән.

Рәсулуллаһ (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм) әйтә:

«Мин яхшы холыкларны тәмам итмәк вә шуларны камил өйрәтмәк өчен җибәрелдем».

«Мәрхәмәтле кешеләргә Аллаһ Тәгалә мәрхәмәт итә. Сез җирдә булган затларга мәрхәмәт итегез, сезгә күктә булган Зат мәрхәмәт итәр, рәхмәт иңдерер».

«Үзең ничек мәрхәмәт итсәң, сиңа да шулай мәрхәмәт итәрләр».

«Явыз вә бозык кешеләрнең генә күңелләрендә мәрхәмәт булмас».

«Бер кешедә өч сыйфат булса, Аллаһ ул кешегә үлемне җиңел кылыр, җәннәткә кертер, ул сыйфатларның берсе – зәгыйфьләргә йомшаклык вә мәрхәмәт итү».

«Туктаган вакытта, утыргыч кебек итеп, хайваннар өстендә утырып тормагыз».

«Бер хатын бер мәчене ябып куеп, һич ашарга бирмәгән, җирдәге хәшәрәтләрне ашарга да юл куймаган, шулай итеп үлтергән, ул хатын шул мәче өчен газапка лаек булды».

Бер вакыт рәсулуллаһ бер дөянең аркасы белән эче ябышканын күреп: «Бу – телсез, үзенең хәлләрен аңлата алмый торган хайваннар хакында Аллаһтан сакланып эш кылыгыз, яхшылык белән алардан файдаланыгыз һәм яхшылык белән аларга ирек бирегез», – дигән.

«Бер вакыт бер кеше юлда бик эчәсе килеп сусап барганда, бер кое күреп, шунда төшеп су эчеп чыккан да, авызыннан телен чыгарган бик сусаган бер эт күргән. Соңра, бу эт тә минем хәлемә төшкән икән дип, этне кызганып, яңадан коега төшеп, читегенә су тутырып алып чыгып, эткә эчергән. Аллаһ Тәгалә бу кешенең эшеннән разый булып, гөнаһларын кичергән». Моны сөйләгәч, кайбер сәхабәләр: «Йә рәсүлуллаһ, хайваннарга ярдәм итүдә дә әҗер бармы», – дип сораганнар. Рәсүлуллаһ та: «Һәр җан иясенең дә әҗере бар», – дип җавап биргән.

Болардан башка, бу бабта килгән хәдисләр, әсәрләр, һәм төрле олуг затларның сүзләре күп. Ислам дине һәр урында әдәп вә әхлакка ригая (ригая – кайгырту, тәрбияләү) иткәне кебек, хайваннарга шәфкать итү, аларга да яхшы кешечә мөгамәлә итүгә зур әһәмият бирә.

Шәһәр ШӘРӘФ.
(«Әд-дин вәл-әдәб» журналы, 1916 ел, №9).

Авылымның тансык кичләре

Изге азан тавышы яңгырый икән,
Тальян гармун барда шуны бел.
Туган телне хөрмәт итә икән,
Яши әле, яши нәни ил!

Авылда гомер иткән кешегә, аһ, якын, тансык ул – кендек каны тамган туган җир! Ул туган нигезеннән аерылганнарның да гел уенда, йөрәк тибешендә! Корымлы кара мунчаларда тальян гармунда уйнарга өйрәнгән авыл малайлары, үсә төшкәч капка төпләрендәге утыргычка утырып, бар авылны, тәнендә җаны бар кешене магниттай үзенә тарткан, караңгы төшкәч урамга чакырган. Сукыр лампа яктысында туган-тумача, тирә-күршеләрне түргә дәшеп кич утырган авылдашлар, йөрәгендә йөрткән илаһи моңны, мәңгелек халык җырларын бүгенгеләргә, киләчәк буынга иңдергән. Татарның әнә шул, борын-борыннан килгән «Кич утыру» дип аталган бәйрәм йоласын бүгенгеләргә, яшьләргә җиткерәсебез килә безнең!

Чираттагы «Кич утыру»ны Мөэмин-Каратай авылының үзәк урамында уздырырга ниятләдек. Каршыдагы мәһабәт йортның капка төбендә кәефне күтәрә торган җанлылык сизелә. «Кич утыру»-ны өйнең хуҗасы, тугызынчы дистәне ваклаган саланың иң уңган балта остасы, бүгенге көндә кызы, кияве карамагында бәхетле картлык кичерүче динле-иманлы Габделәхәт ага Габдрахмановның ихатасы каршында уздырырга җыйналдык.

Менә көтеп алган бәйрәм башланып та китте... Авыл кешесенең талант иясе булганлыгына барыбыз хәбәрдар инде. Гүзәл табигатьле «Трактор» авылында туып-үскән, алты яшендә ат җигеп, өйләрендәге ишле мал-туарга бер олау печән чабып алып кайткан, бүгенге көндә уңган-булган гаиләсе белән Лениногорск районының Мөэмин-Каратай авылында яшәүче җитмеш төрле һөнәр иясе, яшьли гармунда уйнау серләренә төшенгән Нәбиулла Габидуллинны чирәм белән түшәлгән сәхнә түренә чакырдык. Мөэмин-Каратайга атап үзе иҗат иткән җырны башкарды ул. Авылдашлар да аның тәэсиренә бирелеп, моңга кушылмыйча булдыра алмады:

И авылым, Каратаем,
Ямьле синең кырларың...

Аннары халкым табышмаклар әйтүгә дә хирыс булган. Сезгә дә берсен ирештерик әле: Башы – мунчала, койрыгы – сус. Җавабы, әлбәттә, ата-бабаларның ел буена кия торган аяк киеме – чабата инде ул!.. Әнә шундый гаҗәеп кызыклы

табышмаклар да әйтелде бу кичтә. Татар мәкальләрен дә искә төшердек...

Татар халкы, гомер бакый, юктан да кызык табып уйнарга яраткан. Бер «көтү» тамашачы җыеп та элек-электән килгән уеннарны яңартмау мөмкин түгел иде. «Капкалы», «Түбәтәй», «Йөзек салыш» һ.б. уеннарда тамашага килгәннәр барысы да теләп катнашты.

Кичке утыруларның җырсыз узганы юк. Арабызда Мөэмин-Каратайның оста гармунчысы, җырчы Җәдит Шәрифуллин да бар бит, ул авылдашларына иң яраткан моңнарын бүләк итте. Гел картлар гына җыелган икән бит, дип уйлый күрмәгез. Иске Иштирәк мәктәбендә белем алучы, «Кояшкай» бию төркеме кызлары гүзәл биюләре белән сокландырды. Аларны янә дә бер оста гармунчыбыз, моң иясе Хаҗиморат Әхмәтшин алыштырды. Аннары чирәм сәхнә уртасына «Башкорт биюе» белән әвыл мәдәнимят йорты җитәкчесе Лилия Вәлиәхмәтова чыкты.

Авылыбызда талантлар да байтак безнең. Тегү, чигү, бәйләү генә түгел, нәфис сүз осталары да санап бетергесез. Флүрә апа Гафиатуллина, яшьләрдән Мәгъсүм Вәлиев белән Нурия Шәйдуллина талантлы чыгышлары белән сөендерде. Авыл җирлеге башлыгы Әнисә Ханнанова рәхмәт сүзләрен дә, истәлекле бүләкләрен дә кызганмады. Кичке утыру йоласы, әлбәттә инде, кайнар самавыр янындагы бай өстәлләр артында тәмамланды.

Таһир ШӘМСУАРОВ,
Лениногорск районы,
Мөэмин-Каратай авылы.

Чиста булсын, балкып торсын!

Дөньяда һәркемгә таныш һәйкәлләр бар. Көн саен аларны күрергә (һәм тотып та карарга) дип меңләгән турист килә. Шунлыктан, ничек кенә зур булсалар да, аларны әледән-әле чистарту зарур. Мәсәлән, АКШ тагы Линкольн сынын елына ике тапкыр куәтле шланглардан су сиптереп юалар, колак эчләрен мамык уралган таяклар белән арулыйлар. Лондондагы Биг-Бен сәгатенең циферблатын дүрт альпинисттан торган махсус команда биш елга бер тапкыр чистарта, сәгатьне бу вакытта да туктатмыйлар – туристлар рәхәтләнеп күзәтә ала. Чираттагы “генераль җыештыру” 2025 елда булачак. Париждагы Эйфель манарасын гел чистартып тормасалар, ул тиз арада гигант чүплеккә әйләнер иде, кырыс каравылчылар да туристларны күз уңыннан җибәрми. Елына бер тапкыр манараны яхшылап җыештыралар, моңа 10 мең данә чистарткыч матдә, 4 тонна губка һәм 25 мең чүп капчыгы китә. Акропольдәге сыннарга химия белән зыян китермәс һәм бу гүзәллекне киләчәк буыннарга да саклап калу өчен, 2008 елда галимнәр чистартуның 40 лап вариантыннан иң югары технологияле инновацион ысулны – инфракызыл лазер белән ультрашәмәхә нурланыш комбинациясен сайлап алган. Тик ул сәламәтлек өчен дә бик зыянлы, шунлыктан белгечләр саклагыч костюмнардан һәм күзлекләрдән эшли. Америкада 93 метрлы Азатлык сыны 1886 елдан бирле тора, үзен юып та булмый, шунлыктан аны эчке яктан гына арулыйлар. Дөньяның яңа җиде могҗизасы исемлегенә кертелгән Христос-Ярлыкаучы сыны Рио-де-Жанейро һәм Бразилия символы санала, аны карарга ел саен 1,8 миллион турист килә. 38 метрлы сынны су белән юу тыела, шунлыктан аны ун кеше бер ай буена бик вак ком һәм махсус силикон белән чистарта. Әлеге сынга елына уртача 4 тапкыр бик каты яшен суга, шунлыктан кителеп төшкән урыннарны тиз арада “ямап” кую өчен кирәкле таш запасы бер дә бетмәскә тиеш.

(“Die Presse”).

Бер кешелек камерада

Мөгаен, безнең һәрберебезнең кайвакыт берьялгызы каласы, бүлмәгә бикләнеп, телефон белән компьютерны сүндереп, бөтен нәрсәдән һәм бөтен кешедән ял итәсе килгән чаклар буладыр. Бервакыт Британиянең Channel-5 каналы теләүчеләргә шундый мөмкинлек бирергә һәм сынау үткәрергә булган – алар биш көнгә бер кешелек камераларга ябылган. Аларга теләгән кадәр ризык бирелгән, караватта теләсә күпме аунарга, үзләре белән электроникасыз тагын өч әйбер алырга рөхсәт ителгән. Биш кешенең берсе – 28 яшьлек шәфкать туташы Шермейн ябык бүлмәдә дүрт сәгать кенә түзә алган. Икенчесе – телевидениедә эшләүче Джордж – бер тәүлектән соң сынаудан баш тарткан. Аның көн белән төнне аера алмавына ачуы чыккан, бераздан ул бүлмәдәге лампаларга кычкыра башлаган, тагын берничә сәгатькә ялгыз калса, акылдан язудан курыккан. 36 яшьлек Сара биш көн чыдаган, тик ул бик каты нервланган, курыккан, күңеле болганган. Оештыручылар үзләре, сәламәтлеге өчен кайгырып, Сара өчен сынауны туктатырга теләгән, әмма ул, бөтен куркуын җиңеп, ахырга кадәр түзгән. Йоркширдан 28 яшьлек Ллойд, социаль челтәрләрсез яши алмый башлагач, куркуга төшкән һәм смартфонын күрмәс өчен әлеге сынауга ризалашкан. Ялгызына ничек кенә күңелсез булса да, егет түзгән, ул күп вакытын камералар белән сөйләшеп үткәргән. Экспериментта үзен сынап карар өчен катнашкан блогер Люси исә ялгызлыкны шактый җиңел кичергән, чөнки рәхәтләнеп рәсем ясаган. Яраткан эше белән шөгыльләнгәч, вакытның үткәнен сизми дә калган.

(“Daily Mail”).

Тормышын җиңеләйткән

Америкада Матильда Каль исемле кыз һәр иртә саен эшкә нәрсә кияргә дип баш ватудан туйган. Бу күп вакыт таләп итә һәм канәгатьләнүгә караганда күбрәк ризасызлык хисе тудыра башлаган. Матильда нәкъ бер төрле 15 ефәк блузка һәм 6 пар кара чалбар сатып алган. Нәрсә киясен төгәл белгәч, иртән эшкә соңга калудан туктаган, нервлары тәртипкә килгән. Хезмәттәшләре генә баштарак аптырашта калган. Бер ай буена гел бер киемнән йөргән Матильданы йә кем белән булса да бәхәсләшкәндер, йә нинди дә булса сектага эләккәндер, дип хафаланганнар, җитәкчелек исә, аның кием алырга акчасы җитмидер дип, эш хакын күтәрергә җыенган. Кызның үзеннән сорагач, барысы да ачыкланган, һәм Матильда менә инде өч ел буе эшкә көн саен шулай киенеп йөри. Ял көннәрендә исә ул бик матур киенә, үзенә төрле төстәге, модалы кием-салым сатып алудан да туктамаган, бары тик эш киеме генә үзгәрешсез калган.

(“Лента.ру”).

● Миссури һәм Йөрәк елгалары очрашкан җир.

● Конго (Заир).

● Мул сулы Амазонка.

Гаҗәеп елгалар

Елга нәрсә белән гаҗәпләндерсен инде, дисезме? Алар барысы да бер-берсенә охшаган һәм бары тик үлчәме, формасы, ярлары, андагы үсемлекләре белән генә аерыла бит. Чынлыкта исә һәр елга уникаль, һәркайсының кабатланмас холкы бар. Араларында Нил кебек озын һәм куәтлеләре дә, Роу сыман кечкенә һәм тынычлары да, Зәңгәр елга төсле саф сулылары да, Хуанхэ яки Цитариум кебек болганчык һәм пычраклары да очрый. Мәсәлән, АКШ тагы Төньяк Дакота штатында Миссури һәм Йөрәк елгалары очраша, һәм бу вакытта табигый йөрәк сурәте пәйда була. Африкадагы Конго (Заир) исә дөньяда иң тирән елга санала. Кайбер җирләрендә тирәнлеге 230 метрга җитә, анда 700 төрле балык яши. Көньяк Америкадагы куәтле, мул сулы Амазонканы “елга диңгезе” дип йөртәләр. Бөтендөнья океанына агып төшә торган барлык төче суның 20 проценты аның өлешенә туры килә. Тирәнлеге уртача 50 метр тәшкил итә, әмма кайбер җирләрендә 135 метрга җитә, елына ике тапкыр, су күтәрелеше вакытында, диңгездәге кебек зур дулкыннар пәйда була.

(“AdMe.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

11 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». 16+
10.00, 23.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Ринат Закиров турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Адымнар». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Калеб». 6+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПРЕДЛАГАЕМЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 16+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «О времени и о реке». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.15, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Дарья Богарнэ.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.20 «Жизнь и судьба».
8.40 «ПЯТНАДЦАТИЛЕТНИЙ КАПИТАН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Театральные встречи». Дом-музей М.Н. Ермоловой.
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.00 Большие и маленькие.
15.00, 23.35 «Три минуты тишины».
15.05 «Мир, который построил Пьер Карден».
16.05 Линия жизни. Владимир Фокин.
17.15 «Элементы».
17.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Яна Шурупова. «Динозавры: взлёт или падение?»
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Больше, чем любовь.
21.40 «Сати. Нескучная классика...»
22.20 «ДЕТИ ДОН КИХОТА».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
22.15, 0.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+

Сишәмбе

12 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». 16+
10.00, 23.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Теймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Динамо» (Мн). 6+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПРЕДЛАГАЕМЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 16+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «О времени и о реке». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 20.05 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.15 Футбол. Россия - Катар.
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «История одной вселенной».
7.50 «Почерк эпохи». «Михаил Румянцев. Коверный клоун».
8.20 «Жизнь и судьба».
8.40 «ОЛЬГА СЕРГЕЕВНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Урмас Отт с Татьяной Дорониной».
12.15 «Забытое ремесло».
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 «Игра в бисер» «Поэзия Расула Гамзатова».
13.40 «НЕНАГЛЯДНЫЙ МОЙ».
15.05, 23.55 «Три минуты тишины».
15.10 «Обитаемая Вселенная».
16.15 «Сати. Нескучная классика...»
17.15 «Эрмитаж».
17.45 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.00 «Почерк эпохи». «Леонид Андреев. Луч света...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Андрей Сарабьянов. «Предвиденья русского авангарда».
20.50 Юбилей Татьяны Дорониной. «Театральная летопись. Избранное».
21.40 «Старшая сестра». Любите ли вы театр?»
22.20 «СТАРШАЯ СЕСТРА».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
22.15, 0.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+

Чәршәмбе

13 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». 16+
10.00, 23.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА». 12+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЕРАКТАГЫ ЙОЛДЫЗЫМ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15, 0.50 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп әйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән - йөрәккә». Әнгам Атнабаев турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ГУРЗУФ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПРЕДЛАГАЕМЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 16+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «О времени и о реке». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАССКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.15, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Лунные скитальцы».
7.45 «Почерк эпохи». «Леонид Андреев. Луч света...»
8.20 «Жизнь и судьба».
8.45 «ОЛЬГА СЕРГЕЕВНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Дети России».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 Искусственный отбор.
13.40 «СТАРШАЯ СЕСТРА».
15.15, 23.45 «Три минуты тишины».
15.20, 23.50 «Обитаемая Вселенная».
16.15 Больше, чем любовь.
17.15 «Библейский сюжет».
17.45 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.00 «Почерк эпохи». «Александр Куприн. Чудная штука - эта жизнь...»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Алексей Савватеев. «Математика и жизнь».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.40 Власть факта. «Цивилизации Мезоамерики».
22.20 «ПРОДЛИСЬ, ПРОДЛИСЬ, ОЧАРОВАНЬЕ...»

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
22.15, 0.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+

Пәнҗешәмбе

14 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». 16+
10.00, 22.00 Ежегодное послание Раиса Республики Татарстан Р.Н. Минниханова Государственному Совету РТ.
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 23.30 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 Хоккей. «Салават Юлаев» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Вызов 112». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Ватандашлар». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00, 21.25 Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнехановның Татарстан Дәүләт Советына еллык юлламасы. 6+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Ватандашлар». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ГУРЗУФ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «ПРЕДЛАГАЕМЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 16+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «О времени и о реке». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «В ШАГЕ ОТ РАЯ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «УГРЮМ-РЕКА». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.

11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СПАСКАЯ. НОВЫЕ СЕРИИ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.15, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Почему Луна не из чугуна».
7.45 «Почерк эпохи». «Александр Куприн. Чудная штука - эта жизнь...»
8.20 «Жизнь и судьба».
8.45 «ОЛЬГА СЕРГЕЕВНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Я желаю вам счастья... Дин Рид на стройках БАМа».
11.55 «Вологда. Усадьба Брянчаниновых».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 Абсолютный слух.
13.40 «ПРОДЛИСЬ, ПРОДЛИСЬ, ОЧАРОВАНЬЕ...»
15.00, 23.45 «Три минуты тишины».
15.05, 23.50 «Обитаемая Вселенная».
16.00 «2 Верник 2».
17.15 Моя любовь - Россия! «Оренбургский пуховый платок».
17.45 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.00 «Почерк эпохи». «Михаил Нестеров. Моя профессия прекрасна!»
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Евгений Жаринов. «Супергерои».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Простая история» Нонны Мордюковой».
21.40 «Энигма. Екатерина Антоненко».
22.20 «ОДИНОКАЯ ЖЕНЩИНА ЖЕЛАЕТ ПОЗНАКОМИТЬСЯ».

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
22.15, 0.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+

Җомга

15 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
17.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 «Туган җир». 12+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «НА ЛУНЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Без кабызган утлар сүнмәс алар». Кәрим Тинчурин турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «В ШАГЕ ОТ РАЯ». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОАЗИС ЛЮБВИ». 16+
14.40 «Вместе с наукой». 12+
15.10 «Магия вкуса». 12+
15.40 «О времени и о реке». 12+
16.30 «ПИСЬМА НА СТЕКЛЕ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
23.50 «ПРИНЦЕССА НА БОБАХ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Уже не дети». 12+
23.45 К 100-летию Михаила Танича. «Счастье - такая трудная штука». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 8.15, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Женский космос».
7.45 «Почерк эпохи». «Михаил Нестеров. Моя профессия прекрасна!»
8.20 «Жизнь и судьба».
8.35 «ОЛЬГА СЕРГЕЕВНА».
10.20 «ЛЕТЧИКИ».
11.40 «Хозяйки Удоры».
12.45 «Первые в мире».
13.00 Власть факта. «Цивилизации Мезоамерики».
13.40 «ОДИНОКАЯ ЖЕНЩИНА ЖЕЛАЕТ ПОЗНАКОМИТЬСЯ».
15.00, 22.50 «Три минуты тишины».
15.05 «Обитаемая Вселенная».
16.00 Цвет времени. Валентин Серов.
16.15 «Энигма. Екатерина Антоненко».
17.15 Письма из провинции.
17.45 «Бутлеров. Химия жизни».
18.25 Цвет времени. Эдвард Мунк. «Крик».
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «Никола Тесла из Царицына».
20.35 Линия жизни. Алена Долецкая.
21.35 «ИЗ ЖИЗНИ ОТДЫХАЮЩИХ».
22.55 «2 Верник 2».
23.45 «БИБИНУР».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЗАПОВЕДНЫЙ СПЕЦНАЗ». 16+
22.15 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+

Шимбә

16 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 Спектакль «Миркәй белән Айсылу». 16+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
17.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Торпедо». 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «Я НЕНАВИЖУ ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы-тылсымчы Бакый Урманче». 16+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 Фердинанд Сәлаховның юбилей кичәсе. 16+
17.15 «Татар халык җырлары». 6+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 16+
23.10 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Вместе с наукой». 12+
5.30 «Предки наших предков». 12+
6.30 «Я тебя знаю». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30, 14.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «ЛЮБОВЬ НЕ ДЕЛИТСЯ НА ДВА». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КОММУНАЛЬНЫЙ ДЕТЕКТИВ». 16+
14.45 «Ночной дожор». 12+
15.45 «ВЫСОКАЯ КУХНЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ПАДЕНИЕ РИМСКОЙ ИМПЕРИИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 К 100-летию Михаила Танича. «Счастье - такая трудная штука». 12+
13.20 «Мороз и солнце». 12+
14.10 «ОСЕННИЙ МАРАФОН». 12+
15.55 «Горячий лед». Фигурное катание.
16.55 «Ванга. Пророчества». 16+
18.20 «Сегодня вечером». 16+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «ЭЙФЕЛЬ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.55 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Юморина». 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ПРЕВРАТНОСТИ ЛЮБВИ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.55 «ИЗ ЖИЗНИ ОТДЫХАЮЩИХ».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ДЕЛО «ПЕСТРЫХ».
11.50, 23.00 «Три минуты тишины».
11.55 Земля людей. «Кабардинцы. Идущие впереди души».
12.25 Черные дыры. Белые пятна.
13.05 «Первые в мире».
13.20 «Лазурная обитель».
14.05 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.25 «Нобелевские победы российской науки». «Иван Павлов».
16.05 Большие и маленькие.
18.15 «Энциклопедия загадок».
18.45 80 лет со дня завершения Новороссийской десантной операции. «Чистая победа. Штурм Новороссийска».
19.45 «Кино история контрразведки».
20.25 «ЗАСТАВА В ГОРАХ».
22.00 «Агора».
23.05 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «НашПотребНадзор». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Секрет на миллион». 16+
22.20 «Ты не поверишь!» 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

17 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 Илсөя Бәдретдинова концерты. 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 Ришат Төхвәтуллин концерты. 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Әйләнә дөнья». Ришат Фазлиәхмәтов концерты. 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «БЫТЬ ФЛИННОМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Серләреңне миннән яшермә». Ринат Мөслимовның иҗат кичәсе. 16+
9.00, 3.40 «Йөрәктән-йөрәккә». Дамир Сираҗиев турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20, 4.35 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Яшәү- мизгел». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты. 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15, 5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Риваять» этно төркеменең юбилей кичәсе. 16+

«ЭФИР»

5.00 «Вместе с наукой». 12+
5.30 «Предки наших предков». 12+
6.30 «Я тебя знаю». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30, 14.35 «Первые в мире». 12+
8.45 «ВЫСОКАЯ КУХНЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ХОРОШИЙ ДЕНЬ». 12+
14.45 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.45 «ЛЮБОВЬ НЕ ДЕЛИТСЯ НА ДВА». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БОРСАЛИНО И КОМПАНИЯ». 12+
22.50 «ОАЗИС ЛЮБВИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Обязательно к прочтению». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.00 «РОЗЫГРЫШ». 12+
15.50 Владимир Меньшов. «Кто сказал. «У меня нет недостатков»?» 12+
16.40 «Горячий лед». Фигурное катание.
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «ДОКТОР». 16+

«РОССИЯ»

6.10 «БЛЮЗ ДЛЯ СЕНТЯБРЯ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 «Большие перемены».
12.55 «ЗАГС». 12+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.35 «ЗАСТАВА В ГОРАХ».
9.15 «Кино история контрразведки».
9.55 Диалоги о животных.
10.40 Острова. Михаил Пуговкин.
11.20 «ГОДЕН К НЕСТРОЕВОЙ».
12.30, 23.00 «Три минуты тишины».
12.35 Неизвестные маршруты России.
13.15 Невский ковчег. Теория невозможного. Иван Ефремов.
13.45 «Элементы».
14.15 «Игра в бисер» «Книга Иова».
15.00, 23.45 «МИЛЛИОНЕРША».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Первые в мире».
17.30 «Донна Татьяна».
18.20 Концерт «Мои любимые мелодии. Муслим Магомаев».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «ДЕЛО «ПЕСТРЫХ».
22.05 «Геннадий Рождественский. Дирижёр или волшебник?»
23.05 «Кинескоп».

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! Суперсезон». 6+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Балаларга карата җенси бозыклыклар кылу очраклары судларда еш карала. Ләкин, гадәттә гаепкә #... педофил дип табылмый. Быел 20 апрельдә шундый җинаятьләре өчен хөкем ителгән 59 яшьлек абзыйны суд-психиатрия экспертизасы җенси яктан балаларга өстенлек бирә торган ир-ат, дип белдерде. Зарар күрүчеләр балигъ булмаган затлар булгач, педофилның кыланмышлары хакында аларның яшәү урыннарын атамыйча һәм күпчелек исемнәрне үзгәртеп сөйләргә туры килә.

Талипов тайпылышы

1963 елны Венер Талипов тумышы белән Баулы районыннан, ә мөстәкыйль тормышка Түбән Камада аяк баса, шунда өйләнә, кызы туа, әмма гаилә тиз таркала, чөнки 26 яшендә үзенең кечкенә баласына карата җенси рәвештәге көчләү гамәлләре дигән явызлыклар эшләгән ир-ат колониягә озатыла. Аннан кайткач та шул каладагы автотранспорт предприятиесендә слесарь булып эшләп йөри. 2010 елда язмыш 45 яшьлек ире үлеп тол калган Халидә белән очраштыра, күп тә үтми ялгызаклар никах укытып, хатын-кыз фатирында бергә тора башлый, берничә елдан Шин берләшмәсендә эшләп пенсиягә чыккан ханым торагын сатып, Тәтеш районында йорт алалар, Халидәнең туган авылында гомер итәләр.

Хатын-кыз уникe ел чамасы бергә яшәгән Венерның эшчән һәм оста куллы икәнен, төзелеш эшләре башкарып акча табуын әйтә. Шулай ук эчәргә хирыс булуын, бер утыруда бер яртыны бушата алуын, исерек чакта холыксызланып йөрсә дә, аңа кул күтәрмәвен искәртә. Кыскасы, мактамаса да, бөтенләй үк яманлап ташламый. Абзый холык-фигыленең кайбер башка якларына соңрак тукталырбыз.

Хәзер Халидәгә туган тиешле икенче бер гаилә белән танышыйк. Чөнки алардан башка В.Талиповка тиешле бәяләмә биреп булмый. Халидәнең туганнан туганы Мәликә 2018 елда Таҗикстаннан күрше районга күченеп кайта. Бу якларда яшь чагында Урта Азиягә киткән әнисенең бик күп туганнары яши. Аның белән Татарстанга 2013 елгы кече улы Булат Красин да күченә, соңрак кече яшьтәге улы Исмәгыйль һәм кызы Җәмилә белән олы кызы Резедә шул ук фатирга кайтып урнаша. Боларга хуҗабикәнең бер-ике яшькә өлкәнрәк абыйсы Вахидны да өстәргә кирәк әле. Булатның әтисе Санкт-Петербургта тора, онықларныкы туган якларында кала.

Кыз туганнар бик еш аралаша, ара шактый ерак булса да кунакка йөрешәләр. Балалар Халидәне алма апа дип атый, Резедә Казанда эшләгәнгә, алар белән күбрәк Мәликә ханым йөри, килгән саен мунча кереп кунак булып китә алар. Венер агай белән дә аралашалар, әлбәттә.

Узган елның июль аенда оста куллы Венер Мәликәнең фатирын ремонтларга алына. Су үтүче түбәне төзәтергә, черегән идән такталарын, искергән газ казанын алмаштырырга һ.б. эшләр башкарырга кирәк була. Бушлай түгел, әлбәттә, Мәликә бензин бәясен кайтара, хезмәт хакы да түли. Венер берничә көн үзе белән ярдәмче алып килә, соңрак Вахид абзый ярдәм итә. Көнне төнгә ялгап эшләми ирләр, черем итеп алырга да, ара-тирә тамак чылатырга да җай чыгаралар.

2022 елның 22 июлендә агайлар торбалар алыштыру белән шөгыльләнә, сәгать көндезге өчләр тирәсендә Вахид кечкенә бүлмәдә, Венер залда ятып тора, уянгач, Мәликәгә җилем (герметик) алып кайтырга куша, хатын-кыз кибеттән бик тиз әйләнеп кайта һәм көтелмәгән күренешкә тап була. Диванда сигез яшьлек кыз баланы бер кулы белән кочаклап Венер утыра, Җәмиләнең аяклары аның тезләрендә ята, ыштаны төшерелгән икәне һәм ир затының дөньясын онытып, хәтта өйгә кеше керүен дә сизмичә аның җенес әгъзасын сыпырып кәефләнүе күренеп тора. Ошбу галәмәтне янәшә караватта телефонга текәлеп утырган 11 яшьлек Исмәгыйль дә сизмәгән булып чыга. Хәер, ул мәлдә кызчык кулында да шул аппарат була. Тынычлыкны боза әби кеше, ул: «Бу нәрсә булды әле?!» – дип кычкырып җибәргәч тә өненә килеп каушап калган Венер яныннан шуып төшеп әбисе артына качкан кызчык мондый хәлләрнең күп тапкырлар кабатлануын хәбәр итә.

Тавыш күтәрелә, билгеле. Йокысыннан уянып Вахид та килеп чыга, хәбәр абзыйның хәләл җефетенә житкерелә, Казаннан баланың әнисе дә кайтып житә, полициягә хәбәр ителә. Фаш ителгән агай үзен тыныч тота, әйберләрен, эш коралларын җыештыра: «Рәхмәтегез шушы булдымы?» – дип нахак бәла ягу турында сөйләнә. Полиция хезмәткәрләре эшнең асылына тиз төшенә, Венерны эчке эшләр бүлегенә алып китәләр. Кечкенә оныклары белән Мәликә дә шунда юнәлә.

Бераздан анда яшүсмер Булат та килеп керә. Җәмилә белән булган хәлләрне ачыклау барган арада ПДН хезмәткәренә сөйләп булмый торган ярамаган хәлләр башлана.

Әлбәттә, без, вакыйганы иң беренче чиратта, В.Талипов һәм Б.Красин биргән күрсәтмәләргә таянып бәян итәбез. Мондый очракларда сирәк була торган хәл: гаепләнүче абзый һәм зарар күргән яшүсмер сөйләгәннәр, бөтенләй үк тәңгәл килмәсә дә, асылда бер төрле.

бер ел чамасы элек үзенә карата кылынган явызрак җенси бозыклык турында түкми-чәчми сөйләп бирә. Бу инде абзыйның хәле тагын да мөшкелләнүен белдерә.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Андрей Россиев икенче көнне үк җенси бозыклыклар буенча ике җинаять эше кузгата, В.Талипов суд карары буенча сак астына ябып куела. Урманга кергән саен утын күбәя дигәндәй, тикшерә торгач, аның ярамаган гамәлләре дә ишәя бара, ике ай дигәндә аларның саны унжидегә җитә. Ләкин тора-бара алар берләштерелә, ахырда В.Талиповка балигъ булмаган балаларга карата эшләнгән дүрт җинаятьтә гаепләү белдерелә.

Беренче очрак 2021 елның май аенда, Мәликә ханым малае, ике оныгы белән кунакка килгәч була. Авыл апалары эшсез утырмый, апалы-сеңелләр дә җирле фермер теплицасына эшкә китә. Эшлекле хуҗа йорт тирәсендә кайнаша, һәрвакыттагыча мунча ягып җибәрә, ике малай аңа ярдәм итә, мунча өлгергәч, ир затлары өчәүләп юынырга кереп китә. Малайларның кичерәге кызу мунчадан тиз чыгып шыла. Икегенә кеше калгач, барысын да Бары тик агай мунча галәмәтләрен шомартыбрак бәян итә, ләкин авырлар рәтендәге ошбу җинаятьне кылуын таный, бу хакта тәүбәле беркетмә дә яза.

Аның әйтүенчә, шәрә яшүсмерне күргәч дәрт-дәрманы кабынып китә дә, аны җенси якынлык кылырга өндәргә керешә, малай каршы килгәч, парлы кызу бүлмәдә ябып тоту белән куркыта. Кыскача гына әйткәндә, үзе дә кайбер бозыклыклар эшли, җенси рәвештәге көчләү гамәлләре генә түгел, ир затын көчләүгә дә ирешә, ягъни, җинаять эшендә күрсәтелгәнчә, «аңа рухи газаплар һәм физик авыртулар» китерә. Бу инде В.Талиповның 8 дән 15 елга чаклы иректән мәхрүм итү каралган җинаять кылуын белдерә.

Икенче җинаять шул ук көнне башлана. Эштән кайтырга өлгергән хатын-кызлар Булатның мунчадан кәефе кырылган килеш чыгуын сизәләр, әмма андый хәл булгандыр дип уйлап та карамыйлар һәм кечкенә кызны да ияртеп, юынырга-чабынырга кереп китәләр. Яшүсмер үзе дә бу хакта әйтергә батырчылык итми. Күрәсең, ояла, хурлана, яманаты чыгар дип курка һәм, әлбәттә, теге бәндәдән шикләнә. Венер исә аның янына үзе килеп керә һәм тагын җенси мөнәсәбәткә керергә үгетли, хәтта моның өчен 200 тәңкә акча да тәкъдим итеп карый, чын мәгънәсендә яшүсмергә рухи зыян китерүче гәп кора. Ниятенә ирешә алмагач, чыгып китә ул бүлмәдән. Тикшерү барышында аның өендә һәм малай фатирында тагын өч мәртәбә законда җенси бозыклык (разврат) дип йөртелүче шундый ук юньсезлекләр эшли. Монысы инде өч елга кадәр колониягә озатуны күз алдында тоткан икенче эпизод була.

Кечкенә кыз аның тозагына беренче мәртәбә 2021 елның җәендә эләгә. Мичкә ягарга дигән сылтау белән 7 яшьлек баланы мунчага алып керә дә, кулын эчке киемнәре астына кертеп, мәгълүм урыннарын сыйпый. Мондый хәлне күргәне булмаган кызчык чәбәләнә, әбигә әйтәм дип куркыта башлагач, әйтсәң үтерәм, дип өркетә.

Тикшерү барышында барлыгы унбер шушындый очрак калкып чыга. Бозык абзый аулак чакларны күбрәк үз өендә туры китерә, Мәликә ханым фатирында җай чыгарган чаклары да була, берсендә кызны алдап сарайга кертә хәтта. Ошбу унбер тәкатьсезлек очрагы, зарар күрүче кече яшьтә булганга, 12 дән 20 елга кадәр төрмәгә утырту каралган бер җинаять итеп туплана. Моннан кала, Җәмиләгә үтерү белән янаган өчен Венерга дүртенче гаепләү белдерелә.

В.Талипов үзен фаш иттергән 22 июльдә булган очракны да таный. Ошбу җинаятьләрен исерек баштан кылынган ахмаклык, хәтта шул мизгелдә шайтан коткысына бирелү, дип атый. Психиатрлар В.Талипов педофилия дигән тайпылышка ия, дигән нәтиҗәне аның кылган гамәлләрен, биргән күрсәтмәләрен исәпкә алып чыгарган, әлбәттә. Хатыны Халидә «Венерның ошбу бозыклыклары турында ишеткәч ышанмаган идем, соңрак, аның үз-үзен тотышын, холкын, тәртибен, күрәсең, җенси яктан сәерлекләрен дә исәпкә алгач, ул мондый җинаятьләр кыларга мөмкин» дигән фикергә килдем, дип сөйли. Мәликә ханым Венерның бу өлкәдә бик актив икәнен, үзенә дә тәкъдим ясавын искә ала.

Гомумән, шаһитлар, зарар күрүчеләр һәм аларның рәсми вәкилләре арасында Талиповның җенси тайпылышларын аклап сүз әйтүчеләр, аның хәленә керердәй кешеләр юк. Суд карары да катгый булды, В.Талиповка 16 еллык кырыс режимлы колония билгеләнде. Шулай ук рухи зыянны каплау йөзеннән яшүсмергә 600 мең, кыз балага 400 мең сум түләтергә дип игълан ителде. Соңгысының үтәләчәге икеле, билгеле. Абзый 60 яшен тутырган көннәрдә хөкем карары закон көченә алды.

Наил **ВАХИТОВ.**

Бөек якташыбыз Аркадий Пластов



Аркадий Пластов – гаҗәеп язмышлы рәссам. Ата-бабасы икона ясаучы чиркәү әһелләре, Аркадийны да семинариягә укырга бирәләр. Шуңа да карамастан, ул совет чорында миллионлаган бичаралар кебек эзәрлекләнми, киресенчә, югары үрләргә ирешә. Хатыны Наталья фон Вик – алман дворяннары нәселеннән. Земство башлыгы булып торган әтисен 1920 елларда эзәрлеклиләр. Әмма безнең бәхеткә, Пластов тагын исән-имин котыла. Коммунист булмаса да, аңа беренче дәрәҗә Сталин премиясен, Ленин орденын бирәләр. Соңрак ул СССР халык рәссамы исеменә, СССР Сәнгать Академиясенең хакыйкый әгъзасы дәрәҗәсенә ия була.

Дөрес, илдәге вәзгыять аның тормышында да чагыла. Әйтик, 1920 еллардагы ачлык вакытында Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы ачларга ярдәм комиссиясенең җирле бүлеген җитәкләгән Пластовны үз авылдашлары чак кына үтерми кала. 1929 елда исә атларны минут саен җимерелә торган тракторлар белән алмаштыруга каршы чыкканы өчен, колхоз төзелешенә аяк чалуда гаепләп, дүрт айга төрмәгә утырткач, аны үз авылдашлары яклап хатлар яза...

Аркадий Пластов Сембер губернасы Прислониха авылында дөньяга килгән. Мәскәүдә башта Строганов исемендәге сәнгать-сәнәгать училищесының скульптура бүлеген, аннары Рәсем, скульптура, архитектура училищесын тәмамлый. 1929 елда Казанда беренче тапкыр оештырылган шәхси күргәзмәсе рәсем сәнгате тарихына зур вакыйга буларак теркәлеп калган. Ә тагын ике елдан Прислонихадагы йортларында янгын чыгып, рәссамның бөтен картиналары диярлек көлгә әверелә. Шуннан соң ун еллап Пластов колхозга төрле заказлар эшләп, лозунглар язып, бик авыр көн күрә. Аннары исә тормышында күтәрелеш чоры башлана.

Рәссам Аркадий Пластовның бөеклеге шунда ки, беренче карaганда, авыл хезмәтчәннәрен, колхоз тормышын, социализм яулаган үрләрне сурәтли кебек тоелса да, аның иҗат өслүбе соцреализмнан аерыла. Импрессионизмга тартым иҗат өслүбе белән башкарылган картиналарына карыйсың да, рәссамның ирекле шәхес булганын күңелең белән тоясың. Дөрес, ул заманда Сталин портретларын да картинага кертергә кирәк булгандыр. Әмма аны ничек сурәтлисең бит... Сәнгатьтә кем ничек, ә безнең Аркадий Пластов һәрвакыт хакыйкать яклы булган, шуңа күрә самими иҗаты белән югары бәя ала да инде.

Авыл тормышын сурәтләп, ул Бөек Ватан сугышына кадәр үк Мәскәүдә дан ала. Сугыш елларында дистәләп зур картина язып тарихка керә. «Фашист очып үтте» исемле иң танылган картинасында фашист самолетының болында көтү көткән баланы атып үтерүе тасвирлана. Өшәнгән сарыклар кая барырга белми, бозаулар читкә кача. Малайның җансыз гәүдәсе янында тугры көчек кенә утырып калган. 1943 елда бу сурәтне Тәһранда СССР, АКШ, Англия башлыклары икенче фронт ачу турында сөйләшкән конференциядә күрсәтәләр. Шул ук елда Пластов бер төркем рәссамнар белән Сталинград фронтына командировкага бара. Сталинград сугышының иң кызган чагы...

Сугыштан соң «Печән чабу» һәм «Иген игү» картиналары өчен якташыбыз Сталин премиясенә ия була.

Пластов гомере буе авылга, табигатькә, авыл хезмәтчәннәре – крестьяннарга дан җырлый. Аның портретлар галереясе искиткеч бай һәм төрле. Анда җирдә нык басып торучы игенчеләр дә, хыялый көтүчеләр дә, сугыш вакытында нәфис иңнәренә бөтен авырлыкны күтәргән хатын-кызлар да, әле орчык кебек кенә булсалар да, тормыш сынауларыннан иртә олыгайган, аталарыннан калган бишмәтләр кигән балалар да бар. Авыл җырчысының һәр картинасында эчкерсезлек, тормышны яратуы, тоталитаризмга, сугышларга каршы торырлык рухи көче ярылып ята...

Пластов күбрәк авылда яшәгән, авыл тормышының чынлыгын, садәлеген зур дәрәҗәләргә дә алыштырмаган. Иген иккән, печән чапкан, көтү көткән. 1972 елда шунда үзенең картина геройлары арасында күмелгән...

Бүген Пристониха авылында да, Ульяновск шәһәрендә дә Аркадий Пластовның музейлары бар. Бу сәхифәбездә исә Казаныбызның «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә рәссамның 130 еллыгы уңаннан оештырылган күргәзмәдән кайбер картина репродукцияләрен тәкъдим итәбез.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012 ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань р/с 40702810600020010312 к/с 30101810000000000805 БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 08.09.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2540 данә

Заказ 2634

16+